ФӘРИТ ЯХИН

# *ӘДӘБИЯТ УКЫГАНДА*

«Сүз» нәшрияты
Казан
2014

УДК 821.0
ББК 83 (2 Рос=Тат)
Я 90

**Яхин Ф.З.**
Әдәбият укыганда: Фәнни тикшеренүләр.— Казан: «Сүз» нәшрияты, 2014.— 236 б. (10,72 а.т.)

**Я 90**

Татар әдәбиятының гасырлардан-гасырларга үсә һәм үстерелә килгән бай традицияләре, үзенчәлекләре бар. Алар әдәбият белеме тарафыннан туктаусыз өйрәнелә. Аның яңадан-яңа үзенчәлекләре ачыла. Бу хезмәт шул әдәби үзенчәлекләрне ачыклауга, дәлилле аңлатуга, закончалыкларын билгеләүгә багышланган.

© Яхин Ф.З.

**ISBN 978-5-98356-236-3**

# XIX ЙӨЗ ТАТАР КИТАБЫ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ: ЭЧТӘЛЕК ҺӘМ ТӘРТИПЛӘШТЕРҮ

Китапның “оформление”се дигәнне, татар теле сүзлекләрендәгечә “күренешкә кертү” тезмәсе белән күрсәтүгә караганда, “тәртип итү”, ягъни “тәртипләштерү” терминын кулланып тәрҗемә бирүне дөрескә санадык. Хикмәте шунда, монда сүз эчтәлек белән бәйле төзелеш хакында бара. Берникадәр форма, рәсемләү мәсьәләләренең кузгатылуын бу термин таләп итүгә карамастан, алар белән бергә наширларын, редакторларын, авторын, бүлекләрен, җаваплылык һәм шушындый мәсьәләләрнең куелуын да эченә ала кебек.

Китап коммуникатив яссылыкның киңәюендә һәм тирәнәюендә аерым төп рольләрнең берсен башкара. Аның барлыкка килүе һәм үсеше җәмгыятьнең мәдәни дәрәҗәсе хакында сөйли.

Татар кульъязма китапларының сакланып калган, бүгенге көнгә килеп җиткән төп күпчелеге XVIII һәм XIX гасырларга карый. XVIII йөзнең беренче яртысы, XVII йөзнең китаплары бик сирәк очрыйлар һәм хәтта юк дәрәҗәсендәләр. Бу хәл татар иҗтимагый мәдәни тормышында зур үзгәрешләр бары тик XVIII йөз ахырыннан XIX гасыр башларында гына кузгалганнар дигән фикергә этәрә. Әмма сәбәпнең язу материалына бәйле булганлыгын да истән чыгармаска тиешбез.

Рәсәйдә кәгазь эшләп, аны сатуга чыгару пергаменга [1] язудан арына баруга гына түгел, иҗтимагый активлашуга да китергән. Кытайда беренче гасырда кәгазь ясау технологиясе уйлап табылуга карамастан, Европада XII йөздә бу эшне

---

[1] Галим *Д.С.Лихачев,* «пергамен» һәм «пергамент» дип ике төрле язу очраклары булуга игътибар итеп, б.э.к. II гасырда Пергам шәһәрендә бу язу материалының камилләштерелүенә бәйле килеп чыккан термин икәнен исәпкә алып, аны «пергамен» рәвешендә куллану дөресрәк була дип бара.— *Карагыз:* История русской литературы X–XVII веков / *Под ред.* Лихачева Д.С.— М.: Просвещение, 1980.— С.14.

тәртипкә салсалар, бездә ул тагын да соңрак, XIV гасыр ахырында, XV йөз башларында гына күзәтелә.

Асылда XVIII йөзгәчә бездә «ефәк кәгазь» дип аталучы Урта Азия һәм Төркиядән кертелгән кәгазьләр файдаланылган. Ул кәгазьләрдә «су билгеләре» юклыгы җитештерелү датасын һәм урынын ачыклауда комачаулык итә. Кәгазь эшләү технологияләренең 1840 нчы елларгача һәр төбәктә дә бер төрле булганлыгы ясаган кәгазьләреннән күренеп тора.

Кәгазьнең Европада киң таралыш алуы XIV–XV гасырларга карый. Аны җитештерү өчен чүпрәк аламалары күпләп кирәк булган. Бу исә тукыма эшләп чыгаруның үсешенә, җитештерелгән товарның сатуда очсызлана баруына да бәйле. Сәнәгать революциясе генә мондый шартларны тудырган.

Рәсәйдә кәгазьнең киң массага файдалану өчен җитештерелә башлавы XVII йөзгә генә карый[1]. Татарларда тукыма җитештерү фабрикалары XVIII йөздә үсеш ала. Әмма чүпрәк аламаларыннан кәгазь ясау очрамый. Шулай да бу эш белән алар да таныш булганнар дип фараз кылырга урын бар.

Кытайда җитештерелгән ялтырап торучы тыгыз шома кәгазьгә каурый белән хәреф төшерү шактый авыр мәсьәлә, бу эштә камыш каләм дә кулай түгел. Моның өчен тимер каләмнәр ясарга кирәк. Язу эше өчен пергамен кулайрак булган. Дөрес, татарларда тире җитештерү шактый алга киткән. Юка тиреләрне дә Урта Азиядә “булгарый” дип атап йөрткәннәр һәм аларның Идел буйларыннан сәүдә юлы белән китерелүенә ишарә итәләр.

Прегаменны бозау тиресен юкартып кырып, пемзаны файдаланып шомартып һәм агартып ясыйлар. Әмма кәгазьнең пергаменнан өстенлекләре дә шактый. Аны китап төзүдә файдалану китапның күләмен кечерәйтүгә, язуны вагайтуга мөмкинлек биргән. Бу хәл коммуникатив яссылыкны киңәйтүгә хезмәт итми калмаган. Авырлыгы ягыннан китап шактый җиңеләйгән.

---

[1] История русской литературы X–XVII веков / *Под ред.* Лихачева Д.С..— С.14.

Татар китабының үзенчәлекләре башка халыкларныкыннан аерылып тормый. Шул ук форматлар кабатлана. Әсәрнең исемен еш кына китап башында күрсәтү белән чикләнелә. Авторы, әсәренең асыл аталышы һәм язылу еллары да әсәрнең колофон өлешендә бирелгәнчә калдырыла. Атрибуция эше күп көч сарыф ителүче фәнни-текстологик хезмәтне таләп итә.

Автор тарафыннан тексттан тыш күрсәтелеп калдырылган әсәренең язылу датасы да кайсыбер күчермәләрдә кабатлана. Мондый сирәк булса да очрый торган күренеш укучыда аптырау хисе дә уяткан. Китап күчерүчеләр кайбер авторларның кульязмаларына хас ул үзенчәлекне исәпкә алмый калдырган очраклар исә бездә ешрак күзәтелә.

Басма китапка күчү баштарак әсәрләрнең таралышын киңәйтү өчен генә хезмәт итә. Аның кульязма китап вариантын кабатлавы шул хакта сөйли. Китап бастыру сәнгатенең үсеше XIX йөзнең икенче яртысы өчен характерлы.

Татар китабының язма үзенчәлекләре хәрефләрнең кульязмаларда үзара тыгыз рамкаларда теземләнүеннән, аларны туры, авыштырмый язудан гыйбарәт. Бу үзенчәлек басмага күчерү өчен шактый уңайлыклар тудырган. Хәрефләрне туры бастырып язу типография ысулы гына түгел, татар кульязмаларына хас күренеш икәнлеген Казандагы Ш. һәм М.Яхиннар литографиясе исәпкә алып җиткермәгән һәм алар Урта Азия, бигрәк тә фарсы язмаларына тартым каллиграфик үзенчәлекләргә таянуны өстен куйганнар. Бу хәл татар кульязмасына күзе күнеккән укучыда берникадәр авырлыклар тудырган.

Хәрефләрнең «тырнакларын» язып тормау үзенчәлеге татар кульязмаларына хас түгел, фарсы йогынтысының күренеше. Хәрефнең өс һәм ас нокталарын төшереп калдырып язу исә мәмлүк язмаларының кагыйдәсе икәнлеге яхшы мәгълүм. Дөрес, әгәр дә тарихи документларга, хан ярлыкларына игътибар итсәк, аларда язу үзенчәлекләре шулай ук башкачарак. Хәрефләрнең койрыкларын дәвамлы итеп сузып язу яки уйнатып алу урта гасырларда рус һәм Европа патшалыкларындагы фәрманнарда, феодалларның аермалы карарларында, хәтта хатларында мәртәбәлек билгесе саналган.

Төрек солтаннары да ул рәвешне дәрәҗәлек дип күргән. Кульязма татар китабы өчен андый график стиль табигый күренеш түгел. Шигъри әсәрләрнең строфасын, хәтта дүрт юлдан гыйбарәт куплетын мөмкин кадәр бер юлда бирергә тырышканнар. Әмма юллар арасында бушлык калдырып, багана-багана итеп тезеп төшерү формасын файдалану тупланмаларның чәчмәме-тезмәме булуын беренче күз салуда ук ачыклау мөмкинлеген биргән. Тыныш билгеләрен бөтенләй кулланмау автордан җөмлә төзегәндә мәгънә бирүдә зур таләпчәнлек сораган. Бу хәл әдәби телнең грамматик формаларда калыплануына зур этәргеч биргән.

Мәгънәгә хилаф иткән текстлар борынгы китаплар өчен гайре табигый күренеш диярлек. Шул ук вакытта аларда кызыл юл бөтенләй юк, әмма бүлекләргә бүлү, язма юлны өзмичә кызыл кара белән бирү яки, кызыл кара булмаганда, җәя яисә җәяләр эчендә күрсәтү басма китапларга да күчкән. Шулай да татар басма китаплары, кызыл караны эшкә җикмичә, бүлек исемнәрен, кульязмадагы кызыл кара белән язылган урыннарны җәя эчендә төп текст төсендәге буяуда бирүне тәртип иткәннәр. Җәя эчендә бүлекләрнең исемен күрсәтү хәтта бүлекләрне бер-берсеннән аерып язу формасына күчкәч тә шактый вакытлар сакланып калган. Бу, әлбәттә, татар китабының үзенчәлеге буларак бәяләнә ала. Дөрес, юлларның төзеклеге һәммә кульязмаларда да күзәтелми, басмаларда исә технология бары тик төзек юллар белән генә эш итәргә мөмкинлек бирә.

Беренче басма китапларда текстны рамкаларга алу традициясенә нигез салына. Хикмәт шунда, рамкаларга алу төп текстны хашияләр белән бутамас өчен дә кирәк, басма китапның уңайлыгын, игътибарны җәлеп итү көчен арттыра. Кульязмалардан килгән бу татар китабы үзенчәлекләре башка мөселман төбәкләре мәдәнияте үсеше үрнәгендә туган күренеш. Басма китаплардагы текстлар калын һәм нечкә параллель сызыклар белән әйләндерелеп алыну традициясе XIX гасыр буена үзгәрешсез диярлек кала бирә. Бит номерларын җәя эченә алып, сәхифәнең өске ягына уртага урнаштыру һәм, текстны каймалаган рамкадан тышта,

сәхифәнең аскы ягында киләсе бит текстының нинди сүз белән башланып китүен күрсәтү шулай ук кулъязма китаплардан күчерелгән табигый күренеш буларак татар басма китабының форма күренеше рәвешен ала.

Әмма татар кулъязма китапларында сәхифәләрнең номерларын күрсәтү бөтенләй юк, диярлек. Басма китапларда бит номерын бирүнең яңалык булуын сиздерер өчен ул саннарны җәя эченә алганнар дип хаклы рәвештә билгели алабыз. Кулъязма китапларда алдагы сәхифәне башлап китүче сүзне кыеклап язып, күп очракларда аның астына сызык сызып куелган. Басма китапларда ул сүзләр сызыксыз, сәхифәдәге текст тигезлегендә бирелеп барыла. Бу хәл әлбәттә типография мөмкинлекләренә бәйле, хәрефләре җыелма булганда гына кулай. Литографик ысулда исә бу форма кулъязмалардагыча кала. Әмма аларда бит номерлары куелу тәртипкә керә.

Бу ысуллар укучыга да, китапны төпләүчегә дә битләрне бутамау мөмкинлеген биргән. Төшеп калган яки ертылып алынган сәхифәне җиңел билгелисең. Сәхифәнең аскы өлешендә киләсе битнең тексты нинди сүз белән башланып китүне күрсәтеп бару сәбәпле сәхифәнең номеры куелу кулъязма китапны төзүчеләрдә артык эшкә саналган. Ә басмаларда яңа форма белән бергә иске форманың да файдаланылуы китапка хөрмәтне арттыра. Алга таба сәхифәләрнең сан белән күрсәтелүенә татар укучысы да күнегеп җитеп, номерлар җәя эченнән чыгарылганнар, өске яктан аска да күчерелгәннәр, киләсе бит текстының беренче сүзен бирүнең дә кирәклеге калмаган. Бу яңалык әүвәле газета-журналларда барлыкка килеп, алга таба китапларга да күчкән.

Китапның титул битендә беренче басмаларда аның исемен күрсәтү белән генә чикләнгәннәр. Гадәттә ул урта җирдә, бернинди бизәксез, калын һәм эре шрифт белән бирелгән. Типографиясе һәм цензура рөхсәте, наширы хакында мәгълүмат соңгы биткә калдырылган. Алга таба цензура рөхсәте һәм наширы күрсәтелү алга чыгарылган. Текстларның рамкаларга алынмау очраклары да бар. Алар калын һәм

йомшак кәгазьләргә басылганнар. Типографияләрдә ул китапларны бер табак кәгазьгә сыйдырып бетерергә тырышу аркасында хәрефләр ваклана барганнар. Беренче китаплар бизәлешсез бастырылган, берничә табак бергә тегелгән, тышлыклары да юк. Китап ахырында басманың хаталары күрсәтелгән, аларның төзәтмәләре бирелгән. Бу факт татар китабының корректурасын тикшерү эше булганлыгын сөйли. Ул яктан башка халыкларның типография эшеннән татар басма эше аерылып тормаган. Хәтта литографияләр дә корректура эшен шушы формада оештырган очраклар бар. Корректура нигезендә текстны басмага киткәнче үк төзәтеп эшләү газета-журналлар үсеше дәверендә тулысынча хәл ителгән дияргә була.

Беренче фәнни югарылыктагы китап 1825 нче елда Казан университеты нәшриятында бастырылып чыгарылган. Ул — «Шәҗәрәи-төрек» китабы. И.Хәлфин аның тәнкыйди текстын, татар һәм башкортлар арасында сакланып калган ике нөсхәсен чагыштырып, гыйльми өйрәнү рәвешендә сыйфатлы итеп төзи. Ике нөсхәнең һәрбер аермаларына конкрет игътибар ителә, ас төшермәдә, номерлап, алар күрсәтелеп барыла. Әмма монда да корректура хаталары калган, алар китап ахырында бирелгәннәр.

Хива ханы Әбул-Гази Баһадурхан, «Шәҗәрәи-төрек» китабын язып бетергәч, 1609 нчы елларга аны унҗиде нөсхәдә күчертә һәм төрки төбәкләргә тараттыра. И.Хәлфингә шул күчермәләрнең икесе килеп ирешүендә шик юк. Соңрак та «Шәҗәрәи-төрек» берничә тапкыр басыла һәм алар «Татар-монгол тарихы» исеме белән чыгалар. Шунысы әһәмиятле, мәсәлән Х.Фәизханов аны «татарчага тәрҗемә»сендә бастыра, әмма ул вариантның теле гарәп-фарсы сүзләре белән авторныкына караганда күбрәк чуарланган. «Шәҗәрәи-төрек»нең үз теле хәзерге татар әдәби телебезгә шактый якын тора. Тагын шуны ассызыклап китәргә кирәк: И.Хәлфин басмасы бүгенге көндә дә үрнәк булып кала биргән фәнни югарылыктагы басма. Борынгы текстларны өйрәнүче һәм халыкка җиткерүче галимнәребез текстологик эшне әлегәчә

аның дәрәҗәсендә башкарып чыга алганнары юк, Төркия галимнәрен искә алмаганда.

Казанда һәм Рәсәйнең башка төбәкләрендә татар китабын бастырып чыгаруда, татарлардан тыш, төрле милләт вәкилләре катнаша. Бу факт исә татар китабының киң иҗтимагый функциясе булуы хакында сөйли. Шунысы әһәмиятле, татар китабы махсус белгечләр өчен әзерләнүдән бигрәк, киң катлам укучыларга аталган, Кавказга, Урта Азиягә, Төркиягә, гарәп илләренә, Һиндстанга барып ирешкән. Дөньякүләм әһәмияте югары булуы татар мәдәни тормышына башка халыкларның якынаюына китергән.

Татар китабы XIX гасырда хәрефләренең пөхтәлеге, хаталарының азлыгы, җыелу тәртибенең төгәллеге белән сокландыра. Уку өчен уңайлы, ачык итеп төзелүләре, эчтәлеккә муафыйк бизәлеш сайлаулары игътибарны җәлеп итә. Литография ысулында басылган китаплар төсләрне уңышлы файдалана башлыйлар, караңгы яшел, сыек кара төс, куертылган кара төс, хәтта кызыл һәм зәңгәр буяулар белән эшләү тәҗрибәләре, шул юлда укучыга тәкъдим ителгән китапларның сафлыгы һәм чисталыгы бу чорда татар басма китабының югары зәвык белән башкарылуы хакында сөйли. Монда укучыларның таләпчәнлеге белән бергә, эшне башкаручыларның югары культуралы булулары да төп рольне үтәгән.

XIX йөз татар китабының эчтәлеге төрле өлкәләргә карый, әдәби әсәрләрдән тыш, дини, дини-дөньяви, медицина, мистика, этнография, тарих, фәлсәфә, география, тел, ысул-методика, ветеринария һ.б. юнәлешләргә бәйле. Дөнья әдәбиятына, рус-европа әдипләре әсәрләренә игътибар көчәя бара. Тәрҗемә эше 1860 нчы елларга җайга салынып җитә. Моңа кадәр гарәп-фарсы әсәрләре актив тәрҗемәдә булсалар, инде рус, француз, немец, инглиз телләрендәге язмаларга мөрәҗәгать итү дә башлана. XIX йөзнең соңгы чиреге бу яктан татар китабының шактый алга барышы елларына туры килә.

Татар китабының бизәлеше XIX йөздә ике юнәлештә үсеш ала. Аның берсе үсемлек орнаменты ысулына бәйле булса, икенчесе — мөшарәбия стилен файдаланып, мозаика ысулын

кулланудан гыйбарәт. Бу төр бизәлеш типографияләр өчен кулай, аннары — мөшарәбия гарәп илләрендә киң таралган, архитектура-төзелештән алып, мебель ясауда, келәмнәр тукуда бик актив кулланылган һәм, иң мөһиме, шул формадагы бизәлешләр татарның басма китапларына күчерелеп, мөселман руханилары күңелендә дә һичбер төрле каршылыклы хисләр уятмаган. Иң күп бизәлештә «Мөхәммәдия» китабы басыла һәм ул мөшарәбия стилендә типографик юл белән рәсемнәр бирүдә татар китабының зур ачышы булып тора. Наширлар бу стильгә бар игътибарны юнәлтәләр. Һәммә китапларның диярлек титул битләре, унваннары мөшарәбия стилендә бизәкләнеп чыгарылу татар китабының XIX гасырда һичшиксез уникаль икәнлеген күрсәтә.

*2013.*

## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ТАРИХЫН ӨЙРӘНҮНЕҢ ТӨП МӘСЪӘЛӘЛӘРЕ

Татар әдәбияты тарихын өйрәнгәндә төп һәм ышанычлы фәнни принципларны ачык күз алдында тотып фикер йөртергә күнегергә кирәк. Аларны исәпкә алмау сәбәпле хакыйкатькә күп очракта хилафлык ителә.

Беренчедән, әдәбият тарихы халыкның тарихыннан аерылгысыз. Монда шуны истән чыгарырга ярамый: халыкта язмачылык барлыкка килми торып, аның әдәбияты да мәйданга чыкмаган. Шунлыктан әдәбиятның язмачылыкка, ягъни тарихка кадәрге дәверен халык иҗаты буларак тикшерәләр. Халыкның тарихи дәвере (ягъни мәдәни дәвере) башлану белән аның әдәби сәнгате дә шәхесләргә бәйле үсеш ала. Беренче шагыйрьләр һәм язучылар халык әдәбиятын өлге иткәннәр, аңа импровизация яки аның белән полемика рәвешендә үз әсәрләрен мәйданга чыгарганнар.

Икенчедән, әдәбият тарихы халыкның үзеннән аерылгысыз. Аның мәйданын аерым бер дәүләт чикләренә генә кертеп

карарга ярамый. Әгәр дә тарихыбызны үсеш-үзгәрештә күз алдына китерсәк, татар халкының һәр дәвердә төрледән-төрле һәм хәтта үзара дошман дәүләтләргә бүленеп яшәүләренә игътибар итсәк, әдәбиятны шул дәүләтләрнең аерым берсенә генә бәйле өйрәнү хата булуын аңларбыз. Бүгенге көн халәтеннән чыгып тарихны күзаллау ярамаган кебек, аерым милли дәүләтчелек кысалары белән татар әдәбияты таралышы чикләрен билгеләү бары тик ялгыш нәтиҗәләр ясауга гына китерә. Шулай итеп, милли әдәбиятның тарихын халыкның географик яшәү киңлекләре кысаларыннан тарайтып, бер генә төбәгенә нисбәтле тикшерү яки күзаллау дөрес эш түгел.

Өченчедән, әдәбият — сүз сәнгате ул. Әгәр шулай икән, татар әдәбияты дигәндә без аның татар телендә булуы төп шарт икәнлеген белергә тиешбез. Гарәп, фарсы, рус телләрендә тудырылган әдәби әсәрләрне татар әдәбияты ядкәре дип карап булмый. Әгәр чит телдә дә татар әдибе иҗат иткән икән, ул вакытта бу әсәре авторының иҗат киңлекләрен билгеләү өчен файдаланыла ала һәм тиеш. Милли әдәбият вәкиле булу өчен язучының үз-үзен шул милләттән икәнлеген тоюы гына түгел, бәлки шул милләтнең ана телендә иҗат итүен дә шарт итә.

Шулай итеп, сүз сәнгатенең төп кануны милли язучы дип шул милләтнең үз телендә язган әдипне генә таный. Әгәр дә инде әдәбият сүз сәнгате түгел икән, ул вакытта моның әһәмияте барлыгы-юклыгы бу кадәр игътибарга алынмас иде.

Дүртенчедән, әдәбият тарихын этапларга бүлеп өйрәнү аның төп үсеш тенденцияләрен ачыклау белән бәйле. XIX гасырның икенче яртысына кадәр татар әдәбияты Шәрык (Көнчыгыш) әдәбиятлары кысасында үсеш алган. 1860 нчы еллардан башлап ул европалаша башлый һәм бу процесс XX йөз башыннан тәмам кайтаргысызга әверелә. Шулай итеп татар әдәбияты тарихы ике зур этапка бүленә:

1) Шәрыкчәлек дәвере.
2) Европачалык дәвере.

*Аның беренчесен фәндә* ***кадим әдәбият****, икенчесен* ***җәдит әдәбият*** *дип билгеләү дә кабул ителгән.*

- Кадим әдәбият җәмгыятьтә феодаль идеологиянең өстенлек тотуы белән бәйле булса, җәдит әдәбият буржуазиянең мәйданга чыгуы аркасында барлыкка килгән.

- Кадим әдәбиятта дини-суфичыл карашлар өстенлек алып тора, җәдит әдәбият исә дөньяви карашлар белән бәйләнештә үсеш ала.

- Кадим әдәбият гомуми төрки тел кысаларында иҗат ителсә, җәдит әдәбият милли телгә өстенлек бирә.

- Кадим әдәбият хәрәм һәм хәләл мәсьәләләрен чишүгә йөз тотса, җәдит әдәбиятта кеше һәм җәмгыять каршылыгын хәл итү алга куела.

- Кадим әдәбиятта Ислам мәдәниятенә хас әдәби жанрлар киң кулланылышта булса, җәдит әдәбиятта Европа әдәбиятларына хас жанрларга өстенлек бирелә.

- Кадим әдәбиятта дини-мифологик һәм мистик образлар системасы кулланылса, җәдит әдәбият дөньяви күзаллауга хас образлар системасыннан файдалана.

- Кадим әдәбиятта рухи дөнья белән бәйле хис бөтенлегенә игътибар ителсә, җәдит әдәбиятта тормыш чынбарлыгына нисбәтле хис-тойгыларны сурәтләү үзәктә тора.

- Кадим әдәбиятта шигърият әдәбиятның нигезен хасил итсә, җәдит әдәбиятта проза һәм драматургия өстенлек ала.

Шушы берничә типик үзенчәлекләрен генә аерып күрсәтү дә бу ике әдәбиятның үзара шактый каршылыклы булуларын аңларга ярдәм итә.

*Сорау туа:* Борынгы әдәбият төрки телдә язылган, ни өчен аны татар әдәбияты дип карарга кирәк?

Моңа җавап бер генә төрле була ала: чөнки бу вакытта татар халкында мәдәни язма тел итеп төрки теле файдаланылган һәм татар халкының үз теле аның төп состав өлешләренең берсен тәшкил иткән.

Кадим әдәбиятны тулысы белән, ягъни борынгы һәм урта гасырлар чорын, төрки әдәбият дип тә карарга мөмкин. Ул вакытта бу дәвердәге әдәбиятны татар әдәбияты буларак кына түгел, бәлки бөтен төрки халыкларының әдәбиятының составында һәм төп өлешләренең берсе буларак өйрәнергә кирәк.

Димәк, XIX йөзнең икенче яртысына кадәрге татар әдәбиятын төрки әдәбияты тарихы кысаларында тикшерү таләп итеЛә. Шулай итеп, татар халкының әдипләре тарафыннан тудырылган борынгы, урта гасырлар һәм XVII–XIX йөзнең беренче яртысы әсәрләре уртак төрки әдәби мирас сыйфатында, аның составында тикшерелеп, уртак әдәби традицияләр нигезендә өйрәнелергә тиеш булып чыга. Һәрхәлдә бүгенге галимнәребез арасында нәкъ шул юл белән барырга кирәклеген аңлаучылар бар һәм бу яктан шактый алга китүләрен хезмәтләреннән күрергә һәм күтәргә кала.

Татар әдәбияты тарихын этапларга, дәверләргә, чорларга бүлүдә галимнәр тарихи-чагыштырма ысулга танып эш итәләр. Күп очракта тарихи-иҗтимагый методология белән дә чикләнәләр. Шул сәбәпле татар әдәбияты тарихы аерым ханлыклар, дәүләтләр кысаларында гына тикшерелеп, халык төшенчәсен географик дәүләт чикләренә бәйле күзаллау алыштыра, әдәбиятның тарихи дәверләргә хас үзенчәлекләре тәгаенләнелеп кенә калдырыла, ачылмый.

Шулай ук шәхес игътибары алга чыгарылып, язучының тормышына бәйле рәвештә әдәбият тарихын яктырту да фәндә уңышлы гына юл. Әлбәттә язучының биографиясен ачыклау, өйрәнү турыдан-туры әдәби процессның үзенчәлеген ачуда төп рольне башкара алмый. Әмма бу юл белән билгеле чорның әдәби торышына ачыклык кертелә. Язучының биографиясе аның иҗат индивидуальлеген, шәхсәни иҗат йөзен дөрес күзаллауга турыдан-туры катнаша. Әдәбият шәхесләрнең иҗатына, шәхес үзенчәлегенә бәйле. Шунлыктан әдәбият тарихы шәхескә игътибарсыз кала алмый һәм әдәбият тарихын да шәхес игътибары методологиясе ярдәмендә өйрәнүдән китәргә ярамый. Әмма бу юл әдәби процессның эчтәлеген ачып биреп бетерә дә алмый. Анысы да бар.

Борынгы һәм урта гасырлар татар әдәбияты асылда, һәммә төрки әдәбиятлар кебек үк, интерпретация, ягъни нәзыйрә ысулында әсәрләрне мәйданга чыгаруы белән аерылып тора. Бу исә Шәрык дөньясына татар мәдәниятенең кушылып китүе һәм аның бер состав өлешенә әверелә баруы белән генә аңлатыла ала. Әмма бу үзенчәлек татар әдәбиятының ул дәверләре-

нә хас тышкы сыйфаты гына һәм әдәби процессның эчтәлеген ачып бирми. Чөнки ул чорларда оригиналь әсәрләр дә мәйданга чыккан, шул ук вакытта әдипләрнең кулына кергән һәрбер фарсы яки гарәп әсәре дә нәзыйрә ысулында халыкка тәкъдим ителмәгән. Шулай итеп, татар әдәбияты үсеше һәм аның чорларга бүленеше фәндә хәл ителгән мәсьәлә дип санала алмый. Моны чишү өчен тип игътибарына мөрәҗәгать итәргә туры килә.

Типология методологиясенең асылында әдәби әсәрдәге конфликтны ачыклау ята. Әсәрнең эчтәлеге дә, идея юнәлеше дә, каһарманнар да әдәби әсәрдә конфликтка бәйле ачыла[1]. Ә шигъри әсәрләр хисне сурәтләүгә корыла.

Драматик әсәрләрнең сюжеты драматик ситуацияләр характерлы алышынуга бәйле төзелә. Әдәби әсәрләр күпчелек очракта драматик ситуация үзенчәлегенә бәйләнештә корылалар. Драматик ситуация булу-булмауга мөнәсәбәттә әдәби әсәр яки талантлы языла, яки әһәмиятен югалта.

Әдәби конфликт, драматик ситуация, хис тасвиры әдипнең яшәгән чоры үзенчәлекләренә турыдан-туры бәйле. Шулай итеп, монда заман игътибары, ягъни тарихи-чагыштырма методологияне фәнни тикшеренүләрдә файдалану үзен аклый башлый. Шәхес игътибары да һәм башка гыйльми метод һәм методологияләр дә аның ярдәмендә уңышлы нәтиҗәгә китерәләр һәм әдәби процессның асылын ачыклауда файда итәләр.

Борынгы һәм урта гасырлар татар әдәбиятында, билгеләп үтелгәнчә, хәрәм һәм хәләл мәсьәләсе үзәктә тора, дидек. Бу исә әсәрләрдәге төп конфликтны һәм асыл мәгънәне ачыкларга ярдәм итүче ачкыч булып та хезмәт итә. Әдипләр кеше язмышын сурәтләүне алга куюлары сәбәпле, иҗатларында язмыш мәсьәләсендә үз фәлсәфәләрен өстен чыгарырга омтылалар. Тәкъдиргә сукырларча буйсынумы, әллә ихтыярга ирек бирүме? Кайсы хәләл, кайсысы хәрәм?

Борынгы татар әдәбиятында, димәк, хәләл-хәрәм мәсьәләсе драматик ситуациянең, конфликтның, хис тасвирының эчтәле-

---

[1] *Карагыз:* Храпченко М.Б. Творческая индивидуальность писателя и развитие литературы.— Изд. четвертое.— М.: “Художественная литература”, 1977.— С.282-286.

генә ачыклык кертүдә ярдәм итә, әдәби процессны билгеләргә мөмкинлек тудыра. Моннан чыгып, борынгы әсәрләрдә сыйнфый яки иҗтимагый нигездә барган шәхесләр арасындагы каршылыклар түгел, бәлки хәләл-хәрәм мәсьәләсен чишү кирәклеге үзәктә торганлыгын билгелибез һәм шуның үзгәрешен тикшерү ярдәмендә әдәби процессны төшенә, этапларга бүлә, аларның асылын ачыклый алабыз.

XIX гасырның икенче яртысыннан үсеш алган яңача әдәбиятка килгәндә исә, аның типик үзенчәлекләрен билгеләү әдәбият белемендә электән уңышлы хәл ителгән. Монда иҗтимагый-сәяси мәсьәләләр алга чыгарыла, хәләл-хәрәм проблемалары читкә кагыла, үзгәрүчән, бозылучан, тотрыксыз идеологик принциплар үзәккә куела, беренчел төс ала.

*2005.*

# «ТОТСА МӘСКӘҮЛӘР ЯКАҢ»

1

Г.Тукайның шушы исемдәге шигъри фельетоны 1908 нче елда «Яшен» сатира журналының 1 нче (30 нчы август) санында басылып чыга[1]. Әсәрдә Мәскәү байларыннан ссудага акча алып, шуның хисабына кыяфәттә бай булып йөреп, шул байлыкларына мактанып, театрны сүгеп, монафикъ муллалар белән дуслык корып, яшьләр өстеннән донос язучылар төркемендә, кәферләр «җәннәтендә» яшәүче хаҗи абзый, надан татар агае тибы рәвешендә сурәтләнеп, төрле яклап көлкегә алына. Әгәр дә Мәскәү байлары якаңнан алсалар, ягъни ссуда акчаларын кайтарып бирүне таләп итсәләр, ул вакытта үзеңә «зиндан» булачак дип кисәтү ясала.

Р.Гайнанов, Г.Тукай томлыкларын төзүче һәм искәрмә-аңлатмаларын эшләгән галим: «Әсәр «Бакырган китабы»ның бер шигырен үрнәк итеп язылган һәм «Яшен»дә «Бакыргандин» дип куелган»,— дип, фельетонның исеме «Бакыргандин» икәнлеген дә белдерә һәм «Бакырган китабы»ннан шул шигырьнең ике куплетын укучыга танышу өчен мисалга китерә[2].

«Бакырган китабы» җыентыгында ул әсәр биш куплетлы. Г.Тукайда: «Ни кылырсың, хаҗи абзам, тотса мәскәүләр якаң?»— дип башланып китә һәм һәр шигъри куплетның, ягъни бәетнең рифмасын кабатланып килүче «тотса мәскәүләр якаң» рефрены хасил итә. Шагыйрь татар гадәтенчә «мәскәүчәләп» русча гыйбарәләр дә куллана: «как ты будешь отвечать там», «даже в тюрму сыярсың», «нет, князь, постой» кебек кисәтү сүзләре шигырьгә табигый төстә кертелеп, үзенә бер әдәби осталык белән кулланылалар, укучы күңелендә кызыксыну, мыскыллау, ятсыну хисләрен уятуга хезмәт

---

[1] *Карагыз:* Гайнанов Р. Искәрмә һәм аңлатмалар // Тукай Г. Әсәрләр: Биш томда.— Т.I. Шигырьләр һәм поэмалар (1901–1908).— Казан: Татар. кит. нәшр., 1985.— Б. 379.

[2] Гайнанов Р. Искәрмә һәм аңлатмалар // Тукай Г. Әсәрләр: Биш томда.— Т.I. Шигырьләр һәм поэмалар (1901–1908).— Б. 378.

итәләр. Борынгы шагыйрьләр Коръән сүзләре белән, «гарәпчәләп» укучыны ничек шомландырсалар, Г.Тукай, русчалап язып, мәскәүләрнең хаҗи абзадан өстенлеген сиздерер дәрәҗәдә тасвирлау өчен бу алымны оста файдалана.

«Бакырган китабы»ндагы шигырьдә исә үлем хәвефе алга чыгарыла. Ул «Ни кылырсың, мескен адәм, тотса Газраил якаң?» дип башланып китә, биш куплетында да «Тотса Газраил якаң» шигъри юлы кабатланып, әсәрне кафияләп килә. Г.Тукай: «Как ты будешь отвечать там?»— дисә, «Бакырган китабы»нда: «Ничек җавап бирерсең?»— дигән сүзләр килә. Аерма бу сүзләрне Г.Тукайның русчалатып бирүендә генә икәнлеген күрми мөмкин түгел.

Г.Тукай фельетонындагы икенче куплетның беренче строфасы белән «Бакырган китабы»ндагы шигырьнең өченче куплетының беренче строфасы үзара туры киләләр, бер үк сүзләрдән торалар:

*Г.Тукайда:*

> «Сыгмас ирдең киң җиһанга — малыңа мәгърур булып...»

*«Бакырган китабы»нда:*

> «Сыгмас ирдең дөньяга —
> Малыңа мәгърур улып...»

Бу фактлар Г.Тукайның чыннан да «Бакырган китабы» җыентыгындагы шигырь нигезендә *кайтарма әсәр* иҗат итүен, борынгы әсәрне, кадими шигырьне *җәдитләштерүен* раслап торалар. Калган өлешләрдәге аермалар замана сурәтләренә бәйле. «Тотса мәскәүләр якаң» фельетонында Г.Тукай үз иҗат манерасына тугыры кала, борынгы әдәби әсәр мотивларына таянып яңа әсәр иҗат итә. Бу аның әдәби иҗат слубы–методы да. Г.Тукай шушы ягы белән үз чоры әдипләреннән кискен аерылып торды, шушы ягы белән җәдитче-новатор, алгарыш шагыйре булуын күрсәтте. Ул чын мәгънәсендә җәдитче, ягъни модернист әдип иде.

«Бакырган китабы»ндагы «Тотса Газраил якаң» газәле (исемен шартлы рәвештә куйдык) җыентыкта 88 нче әсәр буларак урын алган һәм аның авторы Ходадат дип күрсәтелгән. Бу хакта Ходадат үзе болай дип белдерә:

«И Ходадат, Тәңредин
Куркып һәмишә тәүбә кыл,

Асыг имәс тәүбә соңра,
Тотса Газраил якаң!»

---

***Сүзлекчә:*** *Һәмишә — даими, һаман да; асыг имәс — файда итмәс, җиңелгә булмас.*

«Бакырган китабы»нда Ходадатның барысы биш шигъри әсәре урнаштырылган, шартлы рәвештә алар 85–89 нчы номерлар астында соңгы басмада аерымланганнар[1].

2

Ходадатның «Бакырган китабы»ндагы газәлләре Аллаһ гыйшкына багышланганнар һәм шагыйрьнең эчке рухи халәтен, хис-кичерешләрен чагылдыралар. Ә Аллаһы тәгаләгә аталган шигъри әсәрләр газәл дип, Мөхәммәд пәйгамбәребезгә адресланганнары исә касыйдә буларак йөртелүләре һичкемгә сер түгелдер?

Биш шигъри әсәреннән беренчесен (китапта ул 85 нче номер белән бирелгән) «Ничек сине тапгаймына?» исеме белән аерымларга мөмкин. Шушы мөрәҗәгать сүзләре аның алты куплетында да кабатланып киләләр. Әсәр Кол Галинең «Кыйссаи-Йосыф» үлчәмечә язылган, беренче өч шигъри юллары үзара рифмалашканнар, соңгы строфика аларны буеннан-буена кафияли, шул сәбәпле ул күләмле, дастани әсәрдән өзек буларак та аңлашыла. Әмма алтынчы куплетта шагыйрьнең үз исемен атавы әсәрнең традицион рәвештә тәмамлануын, бербөтен икәнлеген ачык күрсәтә. Шушы куплетта шагыйрь үз сүзләренә эшләре туры килмәүгә, лаеклы ураза һәм намазы юклыкка, соңгы юлга чыгар өчен Ходай каршына килерлек файдалы эше булмауга зарлана. Билгеле, моны суфичыл әдәп буларак кабул итми мөмкин түгел. Әмма әсәренең гомуми рухы, эчке мантыйгы бу тойгы-хисләрен

---

[1] Бакырган китабы: XIII–XVIII йөз төрки-татар шагыйрьләре әсәрләре / Текстларны әзерләүче, искәрмәләр язучы — *Фәрит Яхин*.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2000.— Б.105–107.

уяткан сәбәпләрнең чыннан да бар һәм тирәндәрәк икәнлеген дә сиземләүгә этәрә.

Ходадат Аллаһыдан аерылуына көне-төне хәйран итүен, шуның аркасында бәгыре көюен тасвирлаудан сүзен башлап китә, күзләреннән кайгылы күз яшьләре акканлыгын яза. Үзе, югыйсә, диндарлар кебек мәчеттә намаз да укый, муллалар сыман Китап та ача, суфилар рәвешендә җанын да фида кыла икән, әмма Аллаһы тәгаләне таба алмый. Монда «йа Илаһым!» дигәнендә, сер түгел, әлбәттә хаклыкны, хакыйкатьне эзләве хакында сүз барганлыгын да аңлавы авыр түгел.

Суфилар хакыйкатьне эзләүне, табуны, хаклыкка ирешүне Аллаһы тәгаләгә «кавышу» буларак аңлаганнар. Шәригатьтән тарикатькә, тарикатьтән мәгърифәткә, мәгърифәттән хакыйкатькә күтәрелү мантыйгына буйсынып яшәгәннәр. Алар өчен шәригать ул — үзләренә кадәрге ачылган, билгеле булган хакыйкатьләр, кануннар; тарикать исә — хакыйкатькә ирешүдә үз юлыңны, танып белү методыңны табу. Шуннан соң гына, тарикать аша гына син белемле, мәгърифәтле була аласың. Әмма хакыйкать ул инде ирешелгән танып-белү, белем дәрәҗәсе, мәгърифәт кенә түгел, ул — дөреслекне, хаклыкны аңлау, төшенү, тою мәртәбәсенә ирешү. Алар шушы юл белән генә Хакны — Аллаһыны «табып булганлыгын» белгәннәр.

Ходадатны да хакыйкать кызыксындыра, ул аңа омтыла, әмма таба алмавына зарланырга мәҗбүр. Кемне очратса да, аны Хозыр пәйгамбәргә санап, аңардан дога үтенергә дә, Аллаһыга кол булучылардан мәгънә сорарга да, аларга мөритлек итәргә дә, хаҗга барып, Кәгъбә туфрагын күзләренә сөрмә кылырга да әзер. Сугышчы ирләрдән ярдәм үтенеп, базарларда картларның-яшьләрнең кулын тотып, изге догачалардан гозерләнеп: «Йа Илаһым, ничек сине тапгаймына?»— ди.

Ходадат бу шигъри юлларда үзенең диндарлар дәрәҗәсенә ирешергә теләге барлыгын, әмма ул бәхеттән ерак торуын олы хәсрәте буларак сөйли. Әмма ни өчен болар бары тик аның теләге генә, ни өчен ул үзен шушыларны үтәүче итеп тасвирламый — болар әсәрендә җавапсыз калдырыла. Дөрес,

татар теленең көнбатыш диалектына хас «үтәй», «ачай», «кылай», «барай», «сорай» кебек сүзләрне куллануы Ходадатның изге гамәлләрне башкарганы кебек тә сыман хис уяталар, әмма әсәренең беренче һәм соңгы куплетларындагы вакыйгаларны тасвирлау рәвешләре ул эшләре әлегә теләктә генә калуын тоярга мөмкинлек бирә. Мондый алымда язу шигъри әсәрне әлбәттә киң планлы, тирән эчтәлекле итүдә аерым тәэсирле роль башкара, лирик геройның шушы хис-кичерешләрендә объектив сәбәпләр булырга тиешлеген дә сиздертә.

Алга таба 86 нчы әсәр буларак шул ук формадагы тагын бер шигъри әсәр килә. Ул биш куплеттан гыйбарәт. Монда шулай ук дүртенче шигъри юллар кабатланып баралар. Әсәрнең исемен дә шушы кабатланучы «Синдин үзгә максудым юк» сүзләренә нисбәтле рәвештә атарга мөмкин.

Монсында шагыйрь мөселманнарның иртән намаз укуларын, гашыйкларның үз сөйгәннәрен кочуларын, һәр бәндәнең шәхси теләге барлыгын яза. Ә минем, Илаһым, синнән башка «максудым юк» дип белдерә.

Икенче куплетта Нух пәйгамбәр гомере, Карун байныкыча байлыклар, ике җиһанның милке «булса миңа», ди, «синдин үзгә максудым юк, йа Илаһым», ди. Өченче куплетта җәннәтне үзенә теләве сурәтләнелә. Дүртенче куплетта егет чагы томаналыкта үтүен, картлыкның гаҗизләвен һәм түбәнлеккә төшерелүдән зар елавын сөйли, соңгы куплетта ахыргы сулышы Аллаһ исеме белән булуын теләвен әйтә.

Ходадатның бу әсәре дә суфичыл эчтәлеккә корылган һәм башка шагыйрьләрнең әсәрләреннән эчтәлектә башка юнәлеш алуы белән аерылып тормый кебек. Әмма бу беренче карашка гына шулай. Касыйдәдән аңлашылганча, Ходадат инде, беренчедән, картлык яшенә ирешкән, икенчедән, үз дәрәҗәсеннән, иҗтимагый мәртәбәсеннән төшерелгән, өченчедән, җәннәткә кертелүенә өмет итсә дә, үзенә Нух пәйгамбәр гомере, Карун байлыклары, ике җиһанның милке бирелсә дә, барыбер максаты Аллаһыга ирешү икәнлеген ачык белдерә. Дөньялыкта аның фәкыйрьләр юлында йөрмәгәнлеге дә аңлашыла. Әлбәттә лирик герой белән авторны тәмам

тәңгәл кую әсәрне аңлау-аңлату өчен дөрес алым түгел. Әмма шагыйрь лирик героен сурәтләгәндә дә үз хис-тойгыларына, рухи омтылышларына нигезләнеп иҗат итә, әсәре шунлыктан аның рухының көзгесе булмый калмый. Язмаларының уникальлеген шигъри иҗат материалында шул рухының кабатланмас үзенчәлекләре чагылышы тудыра. Ходадатның да, шәхес буларак, үз рухи дөньясы әсәрләрендә урын тапмый калмаган. Ә кешенең җаны тышкы факторларга һәрвакыт бәйлелектә була.

Җыентыкта бирелгән алдагы әсәрен «Ни кылай?» исеме белән атау урынлы булыр. Касыйдә формасында язылган, биш куплеттан тора. Әмма аны да газәл җанрына карый дип билгели алабыз. Монда Ходадат үзен, исеме белән атап: «Мәнҗәбе җаһ җиһандин, Ходадат, тотыбән, гыйззәтне таләп мин харь булдым»,— дип белдерә, ягъни: «Җиһанда, Ходадат, олы дәрәҗә тотып, хөрмәтне таләп итеп хур булдым»,— ди. Шушы бишенче куплеттан алдагы дүрт бәетендә ул йөз төрле гамәлләр башкаруын, Аллаһының «җамалын күрмәк өчен» тырышуларын яза.

Бу шигъри төркемгә кертелгән соңгы бишенче әсәре дә биш куплетлы газәл, ул да нечкә лирик хисләрне сурәтләүгә корылган, суфичыл эчтәлеккә ия. Ходадатның бу шигъри әсәре дә аның чын мәгънәсендә бөек шагыйрьләрдән берсе булуы хакында сөйли.

Әмма аның кемлеге, кайчан, кайда яшәгәнлеге әдәбият тарихы фәнендә ачылмыйча калдырылган. Хәтта, әйтер идек, бу юлда бер генә омтылыш та булмаган. Югыйсә аның әсәрләрен татар укучысы электән укыган. Г.Тукай кебек бөек шагыйрь, аның иҗатына таянган хәлдә, кайтармалы җәдиди иҗат методын файдаланып, телләргә күчкән шигъри фельетон тудырган. Мәсьәләнең актуальлеген аңлау өчен болар үзләре дә җитәрлек этәргеч бирәләр булыр.

## 3

Фәнни тикшеренү-эзләнүләр безгә Ходадатның шагыйрь буларак кына түгел, яугир сыйфатында да тарихка кереп калган шәхес икәнлеген ачарга ярдәм иттеләр. Аның исемен

рус, поляк, Шәрык елъязмачылары телгә алганнар. Дөрес, Ходадатны рус һәм поляк елъязмаларында «Кудадат» дип атыйлар. Аның Алтын Урда тәхете өчен Олугъ-Мөхәммәд хан белән сугышу вакыйгаларында да актив катнашып алганлыгы билгеле икән.

1421–1425 нче еллар арасында алты хан Алтын Урда тәхетенә утыру өчен тартыша. Бу хакта Ян Витовт, Польша һәм Литва короле, Ливония ордены магистрына 1426 нчы елның 1 январендә язган хатында хәбәр итә[1]. Шуларның берсе — Бәрке хан (аны тарихка багышланган кайбер китапларда Бату хан, Сартак ханнардан соң тәхеткә утырган, Бату ханның энесе Бәркә хан белән бутап язгалыйлар) мәмлүкләр Мисыры илчеләрен дә Алтын Урда ханы буларак кабул иткән, ике арадагы бәйләнешләрне ныгытырга тырышкан, Нугай Урдасы җирләрендә хан булуына карамастан, башка урдаларны да үзенә буйсындырырга омтылган шәхесләрнең берсе. Ул 1422 нче елның 21 нче августында Иделнең уң ягына һөҗүм белән чыга, шактый биләмәләр яулый. Мондагы җирләр Ходадат хан кулында була, Себердә исә Хаҗи-Мөхәммәд хан булып утыра. Алтын Урда тәхетен үзенеке итеп Олугъ-Мөхәммәд хан расларга омтыла. Алар арасында иң уңышлы хәрәкәт итүче Бәрке (яки Бәрәк) хан гаскәрләре 1422 нче елның август ае ахырында Ходадат хан гаскәрләре белән йөзгә-йөз очрашалар. Каты бәрелеш була. 31 нче августа соңгы тапкыр сугышалар һәм Ходадат хан гаскәрләре җиңелә[2].

Бәрке хан үзе Алтын Урда ханы Коерчакның улы булганга, төп тәхетне мирас нигезендә әлбәттә үзенеке булырга тиеш дип санаган. Ходадат да нәселенең башы Җүҗи һәм Бату ханнардан икәнлеген белгән. Әмма бу чорда Дәште-Кыпчакның ханы асылда Олугъ-Мөхәммәд саналган. Аны Польша короле дә олугъ хан буларак таныган. Акчалар Әстерханда, Сарайда, Болгарда аның исеме белән бастырылганнар.

---

[1] *Карагыз:* Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды // На стыке континентов и цивилизаций...: Из опыта образования и распада империй X–XVI вв.— М.: ИНСАН, 1996.— С.450.

[2] Шунда ук.— С.449.

1424 нче елда аның гаскәрләре Ходадат хан гаскәрләренә каршы сугыша. Әмма Олугъ-Мөхәммәд хан җиңелә һәм Польшага качарга мәҗбүр була[1]. Димәк, 1422 елның 31 нче августында Ходадатның Бәрке ханнан җиңелүе вакытлы күренеш булган. Шул сугыштан соң Бәрке хан үз гаскәрләрен Олугъ-Мөхәммәд белән сугышка алып барган.

Бу вакыйгаларны дөрес күз алдына китергәндә шулар аңлашыла: Бәрке хан, Иделне гаскәре белән кичеп, Көнбатышка таба яу чапкан һәм Ходадат хан, үз җирләрен саклау өчен, аңа каршы сугышырга мәҗбүр булган. Үзен олугъ хан сыйфатында таныган Олугъ-Мөхәммәд хан да гаскәрләрен күтәргән.

1423 нче елда Бәрке хан гаскәрләре рус җирләренә барып керәләр. Ука елгасы буендагы Одоев шәһәренә якынлашалар. Князь Юрий Романович Одоевский һәм воевода Мценский Григорий Иротасьевич аңа каршы гаскәр күтәреп, бәрелештә өстен чыгуга ирешәләр. Шуннан соң Бәрке хан, күп югалтуларга дучар булып җиңелү сәбәпле, үз ханлыгы чигенә, Иделнең сул ягына чыгып китә. Алтын Урдага сугыш белән башка килми. Олугъ-Мөхәммәд, Алтын Урда ханы буларак, илендә тәртип урнаштыруга алына һәм Ходадатны, ханлыкка омтылу нияте барлыгын уйлап, буйсындырырга ниятли.

Монгол-татарлар, билгеле булганча, яулап алынган илләренә тамга системасы кертәләр. «Урда» дигән сүз «йорт», «өй» төшенчәләрендә дә, шул ук вакытта «ил», «ил-йорт» мәгънәсенә дә ия булып киткән. Әмма асылда ул «тамга» дигән сүз. Хәзерге телебездә без аны «орды» дибез. «Тамга салды», «мөһер орды» дигән сүзләр шул заманнардан калган.

Тамга системасы нигезендә, Алтын Урдада йортлар, ихаталар сары төскә буялган булган, Күк Урдада исә — зәңгәр һәм яшел төсләргә. Шунысы кызыклы, зәңгәр һәм яшел төсләр күк төсе буларак кабул ителгәннәр. Шулай ук Ак Урда иле булган. Бүгенге көннәрдә дә татарларда үз төсләрен саклау хисе яшәп килә. Көнбатыш татарлары йорт-җирләрен,

---

[1] Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды // На стыке континентов и цивилизаций...: Из опыта образования и распада империй X–XVI вв. — Б. 450.

ихаталарын сары буяулар белән буяп куялар. Казан татарлары, ягъни Идел-Урал арасындагы татарлар яшел һәм зәңгәр төсләргә өстенлек бирәләр. Бу хакыйкатькә игътибар итми мөмкин түгел һәм аның нигезендә тарихи аң, хис-тойгылар ята дип белдерергә мәҗбүрбез. Күченеп, берсе икенчесенең арасына килгәннәрендә дә, алар үз төсләрен саклап калдырганнар. Себердә сары буяулы йортлар-ихаталар очрый икән (хәтта авыллары-авыллары белән), аларның мишәрләрдән булуларын абайларга, телләрендә дә мишәрчәлекнең саклануын күрергә мөмкин.

Ходадат ханга килгәндә, ул, гаскәрләре белән Одоевский җирләренә үтеп, русларны җиңүгә ирешә, хәтта Польшага якынлаша һәм чик буенда 8 көн тора. Әмма ахырда поляк һәм рус гаскәрләреннән җиңелә. «Худайдат после порожения в 1424 г. исчез с политического горизонта»,— дип яза М.Г.Сәфәргалиев аның хакында[1]. Алга таба тагын да мондый нәтиҗә чыгара тарихчы: «Войска Худайдата и Барака были разгромлены военными силами русских и литовских князей»[2].

Бу тарихи вакыйгаларда Ходадат ханның сәяси-хәрби эшчәнлеге, көнбатыш татарларының аның яклы булулары әлбәттә шул чордагы татар халкында кайнаган иҗтимагый хис-тойгыларга бәйле булган, болар, ахырда, Касыйм ханлыгын оештыруга этәргеч ролен башкарганнар. «Бакырган китабы»на әсәрләре кертелгән суфи шагыйрь Ходадат һәм яугир хан Ходадат (Ходайдат) арасында уртаклыклар юк кебек тоелырга мөмкин. Ә менә Алтын Урда ханнарында хорафилык, язмышка-тәкъдиргә өстенлек бирү хисе көчле булганлыгын исәптә тотсак, бу шигебезнең урынсыз икәнлеге дә ачылыр.

Ходадатның кайда, кайчан тууы, тормышының башка яклары әлегә безгә мәгълүм түгел. Әмма аның XV гасырның беренче яртысында яшәгән татар шагыйре, яугир, хан булуы фактлары әдәбият тарихыбызның әһәмиятле һәм кызыклы сәхифәләреннән берсе булып тора.

[1] Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды // На стыке континентов и цивилизаций...: Из опыта образования и распада империй X–XVI вв.— С.451.

[2] Шунда ук.

# XIX ЙӨЗ ТАТАР ШАГЫЙРЕ ҺИБАТУЛЛА САЛИХОВНЫҢ "ДӨРРЕЛ-КӘЛАМ" ПОЭМАСЫ ҺӘМ КӘЛАМ ГЫЙЛЬМЕ

Һибатулла Сәетбаттал улы Салихов (1794–1867) татар диндар-суфи шигъриятенең соңгы вәкилләреннән берсе булып тора. Ул элегия дәверенең иң олуг затлы әдипләреннән берсе, суфичылык романтизмы белән сугарылган шигърияте ялкынында тулы канлы һәм әдәби принципларны күз алдында тотып иҗат иткән шигъри мәктәбен барлыкка китергән, халык телендә әүлия-ишан исемен алган бөек шәхес. Аның шигъри мәктәбенә Оренбург һәм Эстәрле, Себер якларыннан шактый гына шагыйрьләр кергәннәр, шул исәптән аңа зур әдипләрдән Шәмсетдин Зәки, Гали Чокрый да тартылганнар. Хәтта Әбелманих Каргалыны да шушы суфичылык романтизмы белән сугарылган Һ.Салиховның шигъри мәктәбе вәкиле дип карарга мөмкин булыр иде.

1856 нчы елда Казанда дөнья күргән "Дөррел-Кәлам" шигъри җыентыгында шушы мәктәп вәкилләреннән, Һ.Салиховның әсәрләре белән бергә, Г.Чокрыйның да, инде фәнгә исемнәре генә калып, текстлары бөтенләй дә югалган дип исәпләнелгән әнисе Гөлбаһар хакындагы һәм Хәсән Башати, Фәттахетдин Болгари мәрсияләре урнаштырылган. Һ.Салиховның да Оренбург төбәге Түбән-Чебенле авылыннан Нигъмәтулла ишан хакындагы мәрсиясе урын алган.

Җыентык Һ.Салиховның күләмле поэмасы белән ачыла. Әсәрнең соңгы юлларында, ахыргы бәетнең алдыннан гына шагыйрь: "Фи китабин исмүһи — "Дөррүл-Кәлам"— дип белдерә, ягъни "Китапның исеме — Кәлам энҗесе", ди. Шулай итеп, авторның бу әсәрен аерым китап буларак язганлыгы ачыклана. Җыентыкка кертелүе сәбәпле тупланма да тулысынча "Дөррел-Кәлам" дип аталган.

1

“Дөррел-Кәлам” поэмасы Аллаһы тәгаләнең сыйфатларын бәян итү белән башланып китә. Автор: “Тәңрегә чиксез шөкер итәм”,— дип белдерә һәм Аның тугыз сыйфатын белдерә. Беренче урынга Аллаһының барчаларга ярдәм итүче булуын куя, аннан соң кадирлыгын, ягъни әмер итүче икәнлеген бәян итеп, өченче сыйфаты буларак: “Сонгычендә һәм йәнә камил торыр” (“Сәнгате эчендә һәм тагын да камиллек иясе”),— ди. Моннан соң кодрәт иясе икәнлеген белдерә һәм галәмне, бер уч туфрактан Адәмне бар кылуын язып уза. Адәм дигәндә шагыйрь Адәм пәйгамбәрне генә түгел, бәлки һәммә кешеләрнең дә бар кылынуын күз алдында тотып яза. Кайбер сыйфатларын бәян иткәндә бер шигъри юл белән генә чикләнсә, икенчеләренә аерым бәетләр багышлый. Бишенче сыйфаты итеп Аллаһының тиңдәше һәм арадашчысы юклыгын, алтынчы сыйфаты итеп электән бар булуын, ягъни беренчел (кадим) сыйфатын алга чыгара һәм шунда ук Аллаһының үлемсезлеге белән мәңгелеген атап үтә. Җиденче, галәм серләрен бар кылучы, сигезенче, гөнаһларны ярлыкаучы һәм гафу итүче, тугызынчы, мәңге бакый ризык бирүче. Ахырда шагыйрь: “Васфы аның — “кулһуаллаһы Әхәд” (“Сыйфаты аның — “Аллаһыны бердәнбер дип әйт”), — дип, поэмасының бу бүлеген Коръәннең “Ихлас сурәсе”ннән хәбәр белән тәмамлый.

Алга таба поэмада аерым-аерым дүрт бүлек бирелә. Автор аларны “әл-баб” дип атап, саннарын күрсәтеп, исемләп белдереп бара. Ә ул “баблар” шулай ук тематик бүлекчәләргә бүленеп бирелгән. Шагыйрь аларга да аерым исемнәр куйган.

Беренче бүлек — “Әл-бабул-әүвәлүн фит-тәрбиһи бил-мәүти” (“Беренче бүлек үлем куркыныч хакында”). Һ.Салихов барча җан ияләренә үлем насыйп ителүе хакында хикмәт әйтүдән сүзен башлап китә, Коръән аятьләрен искәртеп уза һәм Ләүхә белән Каләм, җәннәт белән тәмуг, Гарше-Көрси һәм Рухи, ягъни Аллаһы тәгаләнең генә мәңгелек булуын санап чыга, һәр кешегә “китү”, үлем вәгъдә ителүен белдереп: “Малы-мөлкен, җөмләсен тәрк идисәр”,— ди, барча байлыгын,

казанганын адәм баласы ятларга калдырып, кара җир куенына ихтыярсыз китәчәклек хакында искәртеп.

Кешегә әҗәлдән котылырга, үлем килгәч хәтта бер генә сулыш алырга да чара юк. Кичкә генә сау-сәламәт булган кешеләр дә таң атканчы тар кабергә керәләр, ди ул. Бу әҗәл илләрне җимерә, хатыннарны тол калдыра, балаларны ятим итә. Шушылар хакында шигъри бәяннәрен биргәч, шагыйрь бу урында фикерләрен хикмәт әйтү ысулында төенләп куя:

Бу әҗәл куймас кешене дөньяда,
Бу әҗәлнең дәрденә юктыр дәва.

Бәллү белгел, бивафадыр бу җиһан,
Тормады һич кемсә бонда бигөман.

(*Бу икенче бәетнең сүзгә-сүз тәрҗемәсе:*

Шикләнми бел, ышанычсыз бу җиһан,
Тормады һич кеше монда шикләнмичән.)

Аннары Һ.Салихов, бу сүзләренә дәлил буларак, аерым фактларга, шәхесләргә күчә. Сүз үтемлеге өчен укучыга ул бер-бер артлы конкрет сораулар белән мөрәҗәгать итә. Дусларың да анда киттеләр, Аллаһының сөеклесе Мөхәммәд пәйгамбәргә дә бу дөнья таяныч булмады, газилар да тар кабергә керделәр, тәхет иясе шаһзадәләр, мин-мин дип мактанучылар да юк, ата-аналарың, сөеклеләрең инде берсе дә калмады, аларга таяныч була алмаган дөнья синеме таяндыра, ди ул. Шушылар хакында язганнан соң тагын фикер йомгагына килә һәм:

Гыйбрәт алгыл сән болардан, и фәлән,
Сәңа һәм йитәр бу нәүбәт бигөман,—

дип хикмәткә хас шигъри нәтиҗә ясый да кабат теманы үстерүгә күчә. Бу юлы инде “караңгы гүр”гә керү вакыйгаларын сурәтли башлый һәм, сүзне озынга сузмыйча:

Ул караңгы гүрдә ялгыз каласын,
Кичәсен һәм көндезен белмәйәсен,—

ди.

Болардан соң шагыйрь *“Зикре дөнья мәккәрү-гаддарә”* (“Мәкер иясе һәм хәйләкәр дөнья хакында”) дигән бүлекчә ачып, дөнья малына кызыкмаска кирәклек хакында яза башлый. Дөнья малы кешене һәлакәт диңгезенә салучы икән. Ул һәммә кешеләрне җәфаландыра, әмма беркайчан терәге була алмый. Байлык тышкы яктан гына алтын кебек ялтырый, әмма аның эчке ягы агудан һәм агулы еланнан гыйбарәт. Шагыйрь дөньяны “сачы дүклек, дешләре дөшмеш” (“чәче коелган, тешләре төшкән”) карт хатын, ягъни карчык белән тиңли. Ул кына диеп кулларына каннар җыя, кара күмер белән күзенә сөрмә тарта, ак кирпеч белән йөзен агарта, шундый бизәкләргә бизәнә. Дөньяның мәкерен Һ.Салихов уйнашчы хатын сыйфатында сурәтләп, аннан мондый сүзләрне әйттерә:

Дир сәңа: — Бу көн бәнемлә уйнагыл,
Таңла эшләрсен ишең, ашыкмагыл.

Бармыдыр һич йирдә бәнем тик гүзәл?
Уш бәне куярма сән, и бигакыл?

Монда шагыйрь суфичылык шигъриятенә хас символиканы куллана. Билгеле булганча, “Таң” ул суфичылык шигъриятендә, “Ахирәт көне”н аңлата, ягъни автор дини йола буенча таләп ителгән гамәлләрне дөнья ташларга, аларны Ахирәт көненә калдырырга чакыра дип аңлата, үзе кебек гүзәлне, акылсызлыкка бирелеп, югалта күрмә диярәк котыртуына туктала. Һәр көн саен дөнья кешене шулай алдый-алдый да, ахырда сине китәргә кушып куалый, ди. Бу рәвешле фикер йөртү суфи шагыйрьләрнең һәммәсенә дә хас. Аларның һәркайсыннан моңа охшашлы шигъри юлларны күпләп табарга була.

Шушы фикри кисәктән соң шагыйрь тагын мәкаль формуласына корылган хикмәтле сүз нәтиҗәсен ясый һәм:

Адәм угылы гаҗәеп ахмактыр —
Бер яман карый хатынга алданыр,—

дип белдерә. Дөньяның барлык ләззәте вакытлы гына булуын, барча рәхәтләренең дә буш икәнлеген ассызыклый. Шуннан соң үгет-нәсыйхәткә күчеп:

Бәс сәңа лазем бу ирер, и ага,
Булмагыл маил бу мәккәр дөньяга,—

ди.

Шуның белән поэманың беренче бүлеге тәмамлана, аннары *“Әл-бабус-санийун фит-тәнбиһи иләл тәүбәти”* (“Икенче бүлек (Ахирәттә) уянганчы тәүбәләнү хакында”) бүлеге килә, аны автор *“Бәйәнүл йәүмүл-Хәшр”* (“Мәхшәр көне хакында”) һәм *“Фи бәйәнит-тәүбәтин”* (“Тәүбә итү хакында”) дип аталган аерым бүлекчәләргә бүлә.

Бүлекне шагыйрь үгет-нәсыйхәт белән башлап китә, күзне ачарга, җирдәге гыйбрәтләрне күрергә чакыра. Наданлык йокысы күзеңне баскан, йокы йөзеңне саргайткан, ди. Гафләт йокысы дигәндә мистиклар летаргик халәтне күздә тоталар. Дөнья малына кызыгу да аларда летаргик йокы халәте буларак аңлатыла. Укучыга мөрәҗәгать итеп, Һ.Салихов “күзләреӊ бер бөртек чүпне һәм пакьлектән нәҗесне аермас булды”, ди, “юл ярагын алырга” чакыра. Боларның мәгънәсе аңлашылып тора, ул укучысын диндарлыкка дәшә. Динсезлек, шагыйрь фикеренчә, “күзгә наданлык карасын сөртү” һәм тормыш “юлында үзеңә мәшәкать йөкләү”дән гыйбарәт.

Шушы фикерләрен бәян иткәч, “юлыңда бер караңгы өй” бар, анда ихтыярсыз керәчәклек хакында бәет китереп, берничә шигъри юлларда кабердә җисемнең хур булып, тешләрнең коелуы, кабер кырмыскалары һәм чаяннарының үле тәнне ашавы, бу хәшәрәтләрне куарга дәрманның калмавы хакында яза да, бары тик дөрес гамәлләрнең генә яхшы юлдаш икәнлеген белдереп фикерен йомгаклап куя.

Дәвамдагы Мәхшәр көне хакындагы бүлекчәдә шагыйрь кабердән барча кешенең кубарылуын һәм бәндәләрнең “бәдәннәре куркудан тетрәшәчәген” яза, һәркемнең яхшы-яманнан Аллаһы каршында җавап тотачаклыгына туктала, савапсыз гамәлләр кылмаган икәнсең, ни эшләрсең диярәк укучысына мөрәҗәгать итә, “Хак сәңа идә хисап” дип, Һ.Салихов Аллаһының бәндәләреннән ничек сорау алуын сөйләп уза. Ә җавапта кешенең дөньяда сансыз гөнаһлар кылуын, бәндәнең үлемнән курыкмыйча саташып йөрүен, “гыйбадәткә буй куймавын”, “туры юлны ташлавын” яза,

тормышта яшәвен тигәнәккә бату белән тиңли, соңга калмыйча тәүбә итәргә һәм “барлык кылган эшләренә борчылырга” чакыра. Шуннан соң тәүбә хакындагы бүлекчәгә күчә.

Һ.Салихов туры юлга тәүбә ярдәмендә керергә мөмкин, башка чарасы юк дип белдерә. Картлыкта тәүбә итүне “үлгәнчегә кадәр үлү” дип аңлата, моны галимнәр сүзеннән алганлыгын яза.

Һәр кеше кем, яшәсә иллек яше,
Булса гыйсьян даимән аның эше,

Һәрнәчә кем тәүбә кылса — булмагай,
Әүвәле гадәтне ул куймагай,—

дип төшендерә.

Шулай да әҗәл килгәнче тәүбә итәргә тиешлекне укучысына “ахи” (“агай-эне”) дип мөрәҗәгать итеп, яшьлеккә таянмаска, “гүр казылудан алда тырышлык кылырга” чакыра, әҗәлнең яшьлектән дә, картлыктан да курыкмавына игътибар итәргә кушып, үлемнән куркырга кирәклекне белдерә. Аллаһыны “барлык гөнаһларны гафу итүче”, “гафу итеп ярлыкаучы шәфкать иясе”, “гыйбадәт тәүбәсен кабул итеп гафу итүче” дип атый. Әмма, бүлекчәдән аңлашылганча, тәүбә ул кабергә кергәнчегә кадәр, дөньяда яшәгән вакытта ук булырга тиеш.

Моннан соң шагыйрь тәүбәнең һәркемне “юлга күндерүе”, “максатка ирештерүе”, “уттан коткаруы”, ягъни тәмугтан котылуга, җәннәткә керүгә сәбәп икәнлеген аңлатып үтә һәм тәүбәне “барча гыйбадәтләрнең башы”, “барча олугларның эше” дип атый. Шуннан соң Мөхәммәд пәйгамбәрнең әйткән сүзләрен искәртә.

Диде Аллаһның Рәсүле: — Бел йакыйн,
Көн дә йөз тәүбә кылырмын куркудин.

Һ.Салихов монда пәйгамбәрләр хакында да яза, аларның “кабахәт, гөнаһ-бозыклыклардан пакь” икәнлекләрен, ә Мөхәммәд пәйгамбәрнең барча нәби-рәсүлләргә имам булуын, шулай да “көн дә йөз тапкыр тәүбә итүен” кабатлап әйтеп уза. Шуннан соң кабат укучысына “гомерең фәскы-гыйсйан белән

үтте” дип ачуланып мөрәҗәгать итә, Тәңре кушмаган эшләрне кылырга өметләнмәскә чакыра. Шушының белән әсәрнең икенче бүлеге тәмамлана.

Поэманың алга таба бүлеге *“Әл-бабус-салисун фи бәйәнин фаидәтис-салати”* (“Өченче бүлек гыйбадәт-намазларның файдасы хакында”) дип аталган. Шагыйрь намаз-доганың бәндәләрне тәмугтан котылдырачагы хакында язудан сүзне башлап китә. Намаз кылуның савaплары, аларны калдыру, бинамаз бәндәнең хәле яманлыгы хакында аңлатканнан соң шагыйрь, Мөхәммәд пәйгамбәрдән намазны ташлау хакында сорагач, ничек дип җавап бирүенә бәйле хәбәрне вакыйга итеп сурәтли. Рәсүлнең Мигъраҗда Гайа дип аталган җәһәннәми ут диңгезен күрүен, аның куркынычлары хакында хикәят итеп сөйләп биргәч, автор кабат намазның, бигрәк тә үз вакытында укылган бишвакыт намазны калдырмаучылык, аларның җәмәгать белән укылуының өстенлекләре хакында аңлатып узганнан соң, яшьлектә үк гыйбадәтле булырга үгетли.

Билгеле булганча, бишвакыт намаз — мөселманлык билгесе, автор бу бүлектә шушы мәсьәләне хикмәт дәрәҗәсенә күтәреп яза, әйткән сүзләренең нәсыйхәт-үгет икәнлеген дә искәртә. Шуннан соң дүртенче бүлеккә күчә. Аны *“Әл-бабур-рабигун фи бәйәнин әл-әмсал”*, ягъни “Дүртенче бүлек мәсьәләләр бәяне” дип атый, анда да нәсыйхәтләрен бирә. Шагыйрь шушы әсәренең һәр бүлеген нинди мәсьәләне күтәргән строфа белән бетерсә, аның артыннан килгән бүлекне шул мәсьәләгә киңрәк тукталуга багышлау белән башлый.

Һ.Салихов нәсыйхәтне сабак, дәрес бирү белән тиңли, Аллаһының белемне әмер итүен, белем ярдәмендә хатадан тыелу юлы табылуын белдереп уза. Кылмаска диелгән гамәлне башкаручыны Аллаһы тәмугка дучар итәчәген аңлаткач, тыелганнан качкан кешеләр җәннәтле булачагын язып, автор алга таба җәннәт һәм тәмуг хакында бүлекчә урнаштыра. Әүвәле җәннәтнең сыйфатлары, рәхмәт нурыннан барлыкка китерелүе, туфрагының зәгъфран, ташларының энҗе-мәрҗән икәнлеге, ризыкларның муллыгы бәян ителә. Аллаһы җәннәттә “һәрбер колына бер шәһәр бирә”, “һәр шәһәр эчендә җитмеш мең сарай була”, “һәр сарай эчендә бер нурлы тәхет бар” дип

белдерә шагыйрь. Ә “һәр тәхеттә бур нурлы хури утыра”, ди. Моны раслап Коръәннән Аллаһының сүзләрен китерә. Шуннан соң җәннәткә кергән бәндәләрнең хәлләрен сурәтләүгә күчә, Коръәндәге болар хактагы хәбәрләрдән шигъри тәрҗемәләрне текст эчендә “диде Коръәндә бу илә” дип бәян итеп уза:

— Булмагай әһле аның һәргиз фәна,
Һич дөкәнмәз андагы шәйләренә.

Һәрбере бер шаһ улә үз мөлкенә,
“Иннәһү даруль-бәкаи вәл гана”.

Шуннан соң Һ.Салихов җәһәннәм хакындагы бәяннәргә күчә. Җәннәт нурдан бар кылынган булса, Аллаһы тәгалә җәһәннәмне “катрә уттан” бар итте, ди шагыйрь. Шуннан автор тәмугка керүчеләрне, анда күргән газапларына туктала, Аллаһыдан гафу итүен үтенүләрен, түзәрлек хәлләре калмавын белдерүләрен яза. Әмма Аллаһы тәгалә аларның теләкләрен кире кага, сәбәбе — берсе дә дөньялыкта яхшы гамәлләр кылмаганнар, пәйгамбәрләрнең сүзен тотмаганнар.

Монда газапланучылар инде үлем үтенәләр. Аллаһы тәгалә аларга тыныч яшәү дә, үлем дә, котылу да юклыгын җавабында белдерә. Шуннан соң шагыйрь кабат үгет-нәсыйхәтләргә күчә, дөньялыкта яшәгәндә бары тик яхшылыклар кылырга, бозыклыкка бармаска, “дөньяны биреп, җәннәтне ал сатып”, ди. Гыйсьянны Шайтан белән тиңли, бәддогага таручының “Тәңрегә дошман” икәнлеген аңлата, “ялган һәм гайбәттән телеңне пакь кыл”, ди. Шуннан соң “*Фи бәянин әл-хәсәдаһ*” (“Көнчеләр хакында”) бүлекчәсен урнаштыра.

Монда кешеләрнең байлыгына көнчелек итмәскә, Аллаһыдан куркып еларга, шуның белән савапка ирешергә, усал сүз әйтеп кешеләрнең күңелләрен бозмаска, яхшылык кылып сөендерергә, изгелегең ярдәмендә хәтерләрендә калырга, инде дә изгелеккә көчең җитмәсә, яманлык-золым эшләмәскә, кайгы җыймаска, күп ашап нәфсене симертмәскә, белгәннәреңне башкалардан яшермәскә, иртән үк торып намаз укырга, хәвефләнеп Аллаһыдан тәүбә үтенергә нәсыйхәтләр

бирә, шул вакытта теләкләрең кабул буласын аңлата. Ата-ана рухына атап догалар укырга, гыйффәттә-сафлыкта күңел-кальбене сафландырырга, яхшыларга иярергә, һәр эшне әдәпкә таянып башкарырга үгетли, болар исә шулай ук максатыңа җиткерер, ди.

Әдәпнең асылын ул бары тик чиксез юмартлыкта гына күрә. Әдәпсезләрнең, һичшиксез, Аллаһының шәфкатеннән мәхрүм калачагын белдерә. Иблиснең әдәпсез булганлыгын искәртеп, бар кайгылар да әдәпсезлектән килә, ди шагыйрь. Әдәпсезлек аркасында кояшка ай тотыла (“шәмсе хосуф”), ягъни хәвеф килә, “бәдрә кәсуф була” (“айның тулган чагы (ундүртенче көнендәгечә) була”), ягъни “әллә кемлек, оялмаучылык” була, әдәпсез кеше ике дөньяда да бәхетсез, “акыллы икәнсең, әдәпсезлеккә барма” дип сүзен бетерә.

Шулай итеп Һ.Салихов үзенең шушы “Дөррел-Кәлам” поэмасын үгет-нәсыйхәт бирү белән сугарылган хикмәт әйтү формасына кора. Аның фикерләре суфичылыкка нигезләнгән һәм ул Кәлам мәсьәләсен дә суфичылык ярдәмендә ачыклап бирә. Билгеле булганча, суфичылык асылда өч өйрәтмәгә корыла: 1) Аллаһыга катгый инануга, 2) Изгеләргә ышануга, 3) Мөхәммәд пәйгамбәрне хөрмәтләүгә[1]. Әмма Һ.Салиховның бу әсәре асылда шушы өч өйрәтмәнең беренчесенә генә корылган, калган икесе хакында анда бөтенләй дә искә алмый диярлек. Вакыйгаларны исә, нәкъ суфиларча, үлем белән, ягъни Аллаһыга ирешүгә бәйләп барганлыгы аңлашылып тора. Әмма бу поэманың Кәлам гыйльменә мөнәсәбәте барлыгы, эчтәлегенә төшенгәч, кайбер укучыларда берникадәр шик тә тудырырга мөмкин. Шунлыктан Кәлам гыйльменең үзен ачыклап, үзенчәлекләрен билгеләп, Һ.Салихов әсәре белән берникадәр чагыштырма планда тикшереп узу сорала.

## 2

Каләм гыйльме, ягъни “Гыйльме-Кәлам”, иман шартын өйрәнүче һәм өйрәтүче фән буларак, игътакадат, бәхәссез

---

[1] *Карагыз:* Мец А. Мусульманский Ренесанс. — Изд. 2-е. / Перевод с нем. Бертельса Д.Е.— М.: Наука, 1973.— С.163.

хакыйкатьне нигезли һәм дин ысулының асылын тәшкил итә[1]. Албания татарларыннан булган XIX гасыр төрек галиме Ш.Сәми сүзлегендә Кәлам гыйльменә “Олуһият вә вәхдәнияттән (гыйбадәт ителүче зат Хак тәгаләнең берлеге һәм барлыгыннан) бәхәс иткән һәм боларны акыл, мантыйк һәм хикмәт кагыйдәләре белән исбатлаган гыйлем, гакаид гыйлеме дип аңлатыла”[2] дигән аңлатма бирелгән. Шулай итеп, Кәлам гыйлеме икенче төрле “Гыйльме-гакаид” дип тә атала икән.

1041 нче елда Багдадта хәлифнең “Шәраитүл-иман”ны чыкканнан соң[3], халык телендә бу гыйлем “Иман шарты” исеме белән йөртелә башлый. Аны мөселман мәктәпләренең тәүге сыйныфларында яттан да, моназаралап та өйрәнгәннәр. Әмма “Иман шарты” асылда гади халык өчен аталган фән булса, Кәлам гыйльме фәлсәфәче галимнәрнең гыйльми эшчәнлеге белән бәйле туган терминнардан санала ала.

Кәлам гыйльменең нигезендә биш төргә бүленгән кагыйдәләр җыелмасы ята. Аларның беренчесе — “Тәүхид кагыйдәләре” дип атала, ул “Лә Иләһе Илләллаһ” сүзләрен әйтүгә корылган булса да, асылын һәртөрле потларга-курчакларга табынуны, христианнардагы “Изге Өчлек”не (“святая Троица”) инкарь итү, Аллаһының бердәнбер булуын, мәңгелек икәнлеген, һичкемнән тумаганлыгын һәм һичкемне тудырмаганлыгын, аңа тиң һичкемнең һәм һичнәрсәнең юклыгын тану тәшкил итә. Шуны да искәртергә кирәк, Аллаһының сыйфатлары тикшерелә торган “Мәгърифәте Аллаһ” фәне “Дин ысулы”ның аерым өлкәсенә карый һәм Кәлам гыйльменә керми. Әмма моны белүче һәм аңлаучы галимнәрне бик сирәк очратабыз.

Кәламнең икенче тикшеренү өлкәсе “Гадәләт” дип атала, ул Аллаһының хөкеме мәсьәләсен тикшерә һәм тәкъдир хакындагы фәлсәфәгә корылган. Кәламнең “Тәүхид” өлешендә

---

[1] *Карагыз:* Торнау Н. Изложение начал мусульманского законоведения.—Санкт-Петербург, 1850 // Репринтное издание.— М. 1991.— С.36-47.

[2] Сами Ш. Камусы-төрки.— Беренче җильд.— Дәрсәгадәт, 1318/1900.— Б. 1174.

[3] Мец А. Мусульманский Ренесанс. — Изд. 2-е.— Б.176.

фәнни бәхәсләрдә катгый аермалыклар булмаса да, “Гадәләт” белән бәйле өлкәсендә сөнниләр шыгыйлардан, гаширыйлар әшгарыйлардан шактый аерылып та торалар. Мәсәлән, сөнниләр һәркемнең тәкъдире Аллаһыдан, ул ни боерган, шул була дип баралар, бу мәсьәләдә ныклы фикердә торалар, фәлсәфәне сәбәп-нәтиҗә бәйләнешенә коралар[1], язмышның Аллаһыдан алынган төгәл күрсәтмә белән баруын белдерәләр. Асылда ул яхшылыкның нәтиҗәсе дә яхшылыкка китерә дигән формулага корыла. Һ.Салиховның поэмасында бу мәсьәлә нәкъ шулай яктыртыла да. Бу дөньяда кылынган һәммә төрле яхшылыкларның ахыры Ахирәт көнендә җәннәткә ирешүгә сәбәп икәнлеген язуына инде тукталып киткән идек. Әмма мәсьәлә аның белән чикләнми, нәкъ шушы сәбәп-нәтиҗә бәйләнешендә шагыйрь башка төрле фикерләрне дә кузгата.

Шыгыйлар да тәкъдир мәсьәләсендә Аллаһы һәркемнең язмышын алдан ук, хәтта кешелек барлыкка килгәнгәчә кадимнән белеп торуына ышаналар, әмма, сөнниләрдән тыш, алар һәркемнең эш-гамәлендә белгесезлек ята, ул ихтыярдан килә һәм менә шуның хаталы нәтиҗәсе өчен кешеләр Аллаһ алдында җавапка тартылалар дип баралар. Шулай итеп, шыгыйлар кеше язмышын хаос эчендә дип игълан итәләр. Кешенең ихтыяры, сайлап алу иреге булуы ике мәзһәбтә дә кире кагылмый әлбәттә. Шунысы да бар, әгәр дә Ислам дөньясында фанатизмны ныгытырга кирәк була калса, язмышның Аллаһы тарафыннан алдан билгеләнгән булуы идеясе халык арасында һәртөрле җитәкчелек тарафыннан махсус рәвештә киң җәелдерелгәнлеге тарихлардан яхшы мәгълүм.

Коръәндә исә, асылда, язмыш мәсьәләсенә килгәндә, бу дөньяда кылган гамәлләр өчен теге дөньяда һичшиксез җавап бирәчәклек, Аллаһының бары тик гадел һәм үз сыйфатына хас хөкем итәчәге хакында сүз бара. Яхшылыкның ахыры һичшиксез яхшылык булачагы, начарлыкка яман хөкем биреләчәге язмышның алдан билгеләнүенең, ягъни тәкъдир фәлсәфәсенең асылын тәшкил итә. Бу яктан Һ.Салиховның

[1] *Карагыз:* Абу-Ханифа Нуман ибн Сабит. Трактаты.— М.:Муравей, 2001.— С.22.

поэмасы Коръән белән тулы яңгыраш тапкан дияргә кирәк. Үлемнең һәркемгә дә һичшиксез килүе, аның һәркайсы кешегә Аллаһы тәгалә белгән вакытта кына ирешүе — язмыш фәлсәфәсенең асыл эчтәлеген тәшкил итә, яхшы яки яман гамәл кылу кешенең ихтыярына калдырыла, хөкем исә Аллаһ кулында.

Каләм гыйльменең өченче тикшеренү өлкәсе — "Нәбүввәт", ягъни пәйгамбәрлек мәсьәләсе. Адәмнән һәм Мөхәммәд пәйгамбәргәчә 124 000 пәйгамбәрнең килгәнлеге, Адәм, Нух, Ибраһим, Муса, Гайсә һәм Мөхәммәднең рәсүл булулары, халыкка дин китерүләре, Мөхәммәлнең соңгы пәйгамбәр булуы, аңа шикләнми иман китерү, барча пәйгамбәрләрнең һичшиксез булганлыгына ышану хакындагы фикерләмәләр "Нәбүввәт"нең асылын тәшкил итә.

Шыгыйлар һәммә пәйгамбәрләрне һичшиксез гөнаһсыз, саф һәм пакь дип баралар. Сөнниләр моны инкарь итмиләр, әмма пәйгамбәрләрнең дә фәрештә түгел, кеше затыннан буларак, хаталануларын таныйлар һәм андый очракларын "аяклары таеп китте" дип белдерәләр. Менә шуңа күрә дә, никадәр пакь булмасын, Мөхәммәд пәйгамбәребез дә һәркөнне биш тапкыр намаз укып тәүбәләнергә Аллаһ тарафыннан хөкем ителгән дип баралар. Бу хакта Һ.Салихов та поэмасында язып уза, бу аның чын мәгънәсендә сөнниләр мәзһәбенә бирелгәнлеген төшенергә ярдәм итә.

Кәлам гыйльменең дүртенче өлкәсе — "Мигад", ягъни кабердән кубарылу һәм Ахирәт тормышы мәсьәләләрен яктырту. Җан, рух үлемсез дип таныла. Монда җәннәт һәм тәмуг хакында Коръәнгә, хәдис һәм риваятьләргә таянып фәлсәфә кору дөрес санала. Кыямәт көне, аның һичшиксез булачагы, җаннарның тәннәр белән кушылачагы, Мәхшәргә сөрелү, игелекле һәм яман рухлар, җеннәр һәм башкалар, галәмнең Аллаһ тарафыннан ничек һәм ни рәвешле яратылуы, күкләрнең катлары, Гарше-Көрси, фәрештәләр, изгеләр һәм башка шундый мәсьәләләр Каләм гыйльменең бу өлешен алып тора. Бу өлкәдә Ислам диненең бер генә мәзһәбендә дә чикләүләр юк. Бары тик Коръәндәге ул мәсьәләләр белән бәйле аятьләр генә инкарь ителергә тиеш түгел. Бу яктан

Һ.Салихов шигъри фантазиягә артык бирелмичә, асылда Коръән аятьләре нигезендә генә фәлсәфә кора.

Кәлам гыйльменең бишенче өлкәсе — “Имамәт”, ягъни Ислам динендә имамлыкның нәселдән-нәселгә күчүе мәсьәләсе. Бу өлкә сөнниләрдә бөтенләй юк, шыгыйлар мәзһәбендә генә бар. Шыгыйлар имамлыкны Гали сәхабә һәм Мөхәммәд пәйгамбәрнең кызы Фатыйма гаиләсеннән мирас буларак килергә тиеш дип баралар. Шушы нәселдән туучылар гына дини һәм дөньяви тормышта мөселман халыкларының хокукый хөкемдарлары мәртәбәсен тотарга тиеш, диләр алар.

Шыгыйлар унике имамны таныйлар, Хәсән белән Хөсәенне хәлифлектән мәхрүм иткәннәре өчен агалары өммияһларны (алар Мәгърип, ягъни Әндәлузия хәлифәтен оештырганнар һәм яшәткәннәр) һәм габбасиларны (болары Шәрык, ягъни Багдад хәлифлеге тәхетенә утырганнар) инкарь итәләр, уникенче имам булырга тиешле Мөхәммәд-Мәһдине җир йөзендә могҗиза белән күренми йөри дип, аны “Сахибе заман” (“Замана хуҗасы”) исеме белән атыйлар. Ул һичшиксез Кыямәт көнендә күренәчәк икән. Шыгыйларның һәр җыеннарында ул күренмичә катнаша дип исәпләнелә.

Сөнниләр, билгеләп үткәнебезчә, “Имамәт”не танымыйлар, әмма Гали сәхабәне һәм аның нәселен изгеләрдән саныйлар. Имам, һәр дин һәм һәртөрле башлыклар җәмәгать тарафыннан сайланып куелырга тиеш дип баралар. Бу сайлау мәсьәләләре сөнниләрдә шәригатьнең аерым өлкәсе санала.

Кәлам гыйльменең аерым өлкәләре белән чагыштыра барганда Һ.Салиховның “Дөррел-Кәлам” поэмасының эчтәлеген һәм формасын тулысынча күз алдына китерүе җиңелләшә, Кәлам гыйльменең һәр өлкәсенә бәйле төп мәсьәләләр әсәрдә конкрет ачыкланганлыгы аңлашылып тора.

Әдәбиятыбыз тарихы фәнендә моңа кадәр бу әсәр бөтенләй диярлек тикшерелмәде, аның эчтәлеге халыкка төшендереп аңлатылмады. Моның тарихы сәбәпләрен искәрү булган кебек, фәлсәфә, дин, әдәбият һәм тарих өлкәләрендә әзерлекле галимнәребезнең юк дәрәҗәсендә азлыгы да исәпкә алынырга тиешле.

## “ДӨРРЕЛ-КӘЛАМ” КИТАБЫ ҺӘМ АНЫҢ АВТОРЛЫГЫ МӘСЬӘЛӘСЕ

Беренчедән, татар әдәбияты тарихы фәнендә “Дөррел-Кәлам” (*игътибар итегез:* ***әсәренең тугел!***) китабының авторы Һибатулла Салихов (1794-1867) буларак күрсәтелү гадәткә кергән. “Татар әдәбияты тарихы” хезмәтендә аның бары тик бер генә авторныкы икәнлеге, беренче тапкыр Һ.Салиховның үзе исән вакытында ук 1856 нчы елда дөнья күргәнлеге белдерелә[1].

“Дөррел-Кәлам” аннан соң да, 1917 нче елгы революциягә кадәр еш чыккан китапларның берсе булып тора. Аларны (1901, 1912 нче елгыларын да) Казан өязе Түбән Курса авылыннан хаҗи Шәмсетдин бине Хөсәен варислары һәм ширкәте нашир итә, сабын заводлары хуҗалары Мусиннар хираҗаты (спонсорлыгы) белән бастырып чыгаралар.

Әмма 1883 нче елда Казанда дөнья күргән “Тәварихы-Болгария” китабында язучы Ф.Әмирхановның бабасы Хөсәен Әмирханов бу китапның авторы итеп Уфа губернасы Әхмәт авылы (хәзерге Татарстанның Сарман районына карый) мулласына, шулай ук Һибатулла исемле кешегә, нисбәт итә, аның Нигъмәтулла мулланың улы икәнлеген белдереп, тагын да ул боларны яза: “Уфа өязендә Әхмәт авылында галим фазыл вә мөршиде камил[2] Дәүләтшаһ ишан хәзрәтләренең хәлифәседән[3] Һибатулла бине Нигъмәтулла күп еллар гыйлем заһир вә гыйлем батыйннан тәгълим биреп[4], күп адәмнәр кәмалаткә йиткәннәр[5]. “Дөррел-Кәлам” исемендә вә һәм хуп мөнәҗәте[6] бар”[1].

---

[1] Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. – Т.2. - XIX йөз татар әдәбияты. - Казан: Татар. кит. нәшр., 1985.— Б.150.

[2] Галим фазыл вә мөршиде камил — олы дин галиме һәм суфи ишан.

[3] Хәлифәседән — олырак ишанга буйсынып, үзе дә мөритләр туплап ишан булган, шәкертләрен булдырган суфилардан.

[4] Гыйлем заһир вә гыйлем батыйннан тәгълим биреп — дөньяви һәм дини гыйлемнәрне өйрәтеп.

[5] Кәмаләткә йиткәннәр — камиллеккә ирешкәннәр.

[6] Вә һәм хуп мөнәҗәте — шулай ук яхшы һәм күркәм шигъри догасы.

Х.Әмирхановның бу сүзләрен инкарь итү урынсыз, чөнки шул заманнарда яшәгән зур галимнәребезнең берсе ул. Әмма Һ.Салихов белән Һ.Нигъмәтуллинны бутауларын да искәртми мөмкин түгел.

Икенчедән, бу китапка "Дөррел-Кәлам" дип исем бирелү факты кызыклы. Тәрҗемә итсәк, ул "Кәлам энҗесе" дигән мәгънәгә туры килә, димәк, "Гакаид гыйлеме"нә, ягъни "Иман шартына" багышланган әсәр икәнлеге беленә.

Тышлыкта, "Дөррел-Кәлам" дигәннән соң, "Һәм нәзмы сарсази ләкабиһи Фәйзелбари, фи мәрсиятин мулла Фәттахетдин әл-Болгари хәлифәтиш-шәихит-Төрекмани әл-Бохари һәм мәрсия-и әл-хаҗи мулла Хәсән Пашати" ("Һәм Фәйзелбари (Аллаһының Изгесе) кушаматын йөртүченең шигъри тезмәләре, хәлфә шәех әт-Төрекмани әл-Бохариның мөриде мулла Фәттахетдин әл-Болгари мәрсиясе һәм Хаҗи Хәсән Пашати мәрсиясе") дип, китапка кертелгән әсәрләрнең эчтәлекләренә бәйле исемлеге бирелгән.

Димәк, бу китапта, тышлыгындагы мәгълүматыннан аңлашылганча гына исәпләсәк тә өч әсәр урнаштырылган. Алар 1) "Дөррел-Кәлам", 2) Фәйзелбариның шигъри тезмәсе, 3)"Фәттахетдин Болгари мәрсиясе", 4) "Хәсән Пашати мәрсиясе" дип аталганнар.

Әмма "назмы сарсази" тезмәсен "шигъри тезмә" дип түгел, бәлки "шагыйрь Сарсази" дип тә тәрҗемә итеп булыр иде. Тик ул вакытта аның "Фәйзелбари" кушаматлы булуын искәртүләре кирәк табылмас иде. Димәк, "назмы сарсази" сүзләре имза түгел, бәлки "шигъри тезмә" дигән термин булып чыга. Без "Фәйзелбари" кушаматын һәм "Сарсази"ны шагыйрь Гали Чокрыйга нисбәт итәргә тырышып карадык, әмма хаталануыбызны аңладык.

Шулай итеп, китапның авторы буларак бүтәнне, башка берәүне — Фәйзелбари кушаматлы шагыйрьне дә атарга тиешбез икән. Шунысы әһәмиятле, китапның тышлыгында бер автор күрсәтелгән, әмма фәндә исә аны икенче кешегә нисбәт

---

[1] Әмирханов Х. Тәварихы-Болгария.— Казан: Университет табигъханәсе, 1883.— Б.45.

итәләр түгелме? Димәк, бу мәсьәләне ачыклап, тәмам чишеп бетерү соралып тора.

Өченчедән, бу китап “Дөррел-Кәлам” дип исемләнгән дини поэма (мөнәҗәт // мөнажат) белән ачыла. Алдагы мәкаләбездә белдерелгәнчә, ул дүрт “баб”-бүлектән гыйбарәт, һәр бүлек тагын да аерым тематик бүлекчәләргә бүленгән. Урыны-урыны белән сүз дәлиленә Коръән аятьләре мисал итеп китерелә һәм шуларга шәрех буларак тагын да авторның фикерләре бәян ителә. Бу стильдә Һ.Салиховның “Мәҗмәгыль-әдәп” (“Әдәп мәҗмугасы”, 1839) китабы да язылган.

“Дөррел-Кәлам” әсәре ахырында шундый мәгълүматы бар: “Мин таәлифин әл-галимил-гамәл вә мөршидил-кәмил фи гасриһин мулла Һибәтулла мин хәлифәи ишан Дәүлатшаһ рәхмаһүм Аллаһү тәгалә” (“Хәлфә ишан Дәүләтшаһның, аңа Аллаһы тәгаләнең рәхмәте булсын, гамәлендә галим һәм камил суфи-мөрид гасырында мулла Һибәтулланың язганнынннан”) дигән мәгълүмат бирелгән. Дәүләтшаһ ишан дигәнендә тарихи-легендар шәхес Түбән Чебенле авылыннан, заманында мәшһүр булган Дәүләтшаһ бине Гаделшаһ әүлия хакында сүз бара. Ул зур мәдрәсә тоткан.

Шул Түбән Чебенле авылында Һибатулла Салихов та туа, ул вакытта аның әтисе Сәетбаттал Салихов монда мулла булып тора. Һибатулла әүвәле Дәүлатшаһ ишан мәдрәсәсен тәмамлый, аннары Оренбург Каргалысында Вәлидетдин Багдадыйда укый. Соңыннан Түбән Чебенлегә мулла булып кайта.

Басмаларда әсәрнең авторы хакындагы шушы мәгълүмат алга таба урнаштырылган поэма алдыннан куелган, әмма аерымлап, махсус рәвештә рамкага алынган. Мөгаен шушы сәбәп аркасындадыр галимнәр китаптагы башка әсәрләрне дә “Дөррел-Кәлам”нең состав өлеше буларак күзаллаганнар.

Шулай да, “Дөррел-Кәлам” әсәренә килсәк, эчтәлегеннән һәм колофоныннан чыгып караганда да, аның авторы Һ.Салихов икәнлеге бәхәссез факт икәнлеген онытмыйк.

Дүртенчедән, “Дөррел-Кәлам”нән соң, икенче булып затлы бер ишанга багышланган мәрсия килә. Автор аны “Исемең

сәнең һәбең” дип күрсәтә (ягъни исемең синең бүләгең). Бу Һ.Салиховның шигырьләрендә үзенең авторлыгын белдергәнендә еш кулланыла торган “Исемем Аллаһ һибәсе” (исемем Аллаһы бүләге) дигән формулага тартым. Әмма авторының кемлеге әсәр ахырындагы: “... би каләмил-габдел-зәгыйфь ибне Нигъмәтулла гаффаруллаһ ләһүмма...” (“Аллаһының зәгыйфь колы Нигъмәтулла улының, Аллаһы аларны гафу кылсын, каләменнән”) дигән аерым хәбәр бирелә. Димәк, бу поэманың автор Нигъмәтулла улы икәнлеге аңлашылып тора. Ә ул шулай ук данлыклы шәхес, шагыйрьлеге хакында да тарихи хәбәрләр бар.

Аның әтисе Нигъмәтулла ишан Эстәрлебашның мәшһүр ишаны Нигъмәтулла бине Биктимер (Акмулланың әтисе шушы Нигъмәтулла ишан Биктимеровның мөриде булган) бине Тукай бине Үткән әс-Салаучи (1844 нче елда вафат) дигән кеше[1]. Бу кешенең ике улы булган, берсе — Харис, икенчесе — Харрас.

Нигъмәтулла ишанның җеназасында бик күп мәрсияләр укыла. Шуларның берсенең авторы улы Харисныкы икәнлеге “Асар”дагы текстыннан күренә. Бу кешенең шулай ук ишан булганлыгы, зур галим һәм шагыйрь буларак танылуы “Асар”дан билгеле, Һ.Салиховның чордашы һәм фикердәше икәнлеге әсәреннән дә аңлашылып тора.

Бишенчедән, бу китапта алга таба тагын да өч мәрсия урнаштырылган:1) “Мулла Фәттахетдин Болгари хакында”, 2) “Фи мәрсиятин вәлидәтил-җәлләяти” (“Үз әниемнең мәрсиясеннән”), 3) “Мулла Хәсән Башати мәрсиясе”. Боларның авторлары “Гали Гари вә Болгари”, “Вади Болгари” дип күрсәтелгән. Ул имзаларның Гали Чокрыйныкы икәнлеге фәнгә яхшы мәгълүм. Аларның икенчесе Г.Чокрыйның үз әнисе Гөлбаһарга багышлап 17 яшендә Пермь губернасы, Осы өязе, Танып авылы Хәйрелзаман бине Габди мәдрәсәсендә укыган чагында язылган, фәндә югалган исәпләнелгән мәрсиясе.

[1] Фәхретдинов Р. Асар. — Т.2.— 9 нчы җөзьә.— Оренбург: Кәримия, 1904.— Б.77-93.

Чынлыкта ул басма рәвештә халыкта киң таралыш алган әсәр икән, югыйсә. Әмма галимнәр аның хакында дәреслектән-дәреслеккә һаман да “югалган” дип яза килделәр, фәнни хезмәтләрендә лаф ордылар.

Алтынчыдан, шушы өч автор да үз заманнарында бөек ишан һәм шагыйрь булып танылган шәхесләр. Г.Чокрый Эстәрлебаш мәдрәсәсендә укыткан. Һ.Салиховның Эстәрлебаш белән тыгыз элемтәдә торганлыгы хакында мәгълүматлар шактый күп сакланган.

Х1Х йөзнең беренче яртысы элигик татар шигърияте (ягъни мәрсияләр һәм мәдхияләр язу дәвере татар шигърияте) Һ.Салихов йогынтысында мәйданга чыга. Г.Утыз Имәни традицияләрендә, шулай итеп, үзенә бер әдәби мәктәп барлыкка китерә ул. Һ.Салихов иҗаты йогынтысында Шәмсетдин Зәки дә була. Ә “Дөррел-Кәлам” китабына килгәндә, аны шушы әдәби мәктәпнең көчен дәлилләүче бер мәҗмуга дип тә билгеләргә кирәк.

*1999.*

# КАЮМ НАСЫЙРИ
# ҺӘМ
# ТАТАР ФОЛЬКЛОРИСТИКАСЫ НИГЕЗЛӘРЕ

2002 нче елда “Мәгариф” китап нәшриятында күренекле галим-фольклорчы Фатих Ибраһимович Урманченың “Татар халык иҗаты” дип аталган монографик хезмәте басылып чыкты[1]. Анда татар фольклористикасында беренче тапкыр буларак дип әйтергә мөмкин, татар халык авыз иҗатын җыю һәм өйрәнү тарихы тәфсилле итеп яктыртыла, татар фольклоры төрләр һәм жанрлар буенча системага салына, катлаулы мәсьәләләре аерып алып күрсәтелә. Билгеле, моңа кадәр 1967 нче елда галим-фольклорчы Хәмит Ярми “Татар халкының поэтик иҗаты” дип аталган күләмле генә монографиясен бастырып чыгарган иде[2]. Анда татар фольклористикасы фәне үсешенә берникадәр йомгак та ясалды. Ә менә Ф.И.Урманченың хезмәте белән яхшылап танышу татар фольклорын җыю һәм өйрәнү юнәлешендә XX нче гасыр татар фольклористикасы үсешенә бәя бирү, аңарга йомгак ясау һәм алдагы үсеш перспективаларын күрсәтү өчен дә язылган дигән фикер уята. Бу монографиянең 6–29 нчы битләрендә “Татар халык иҗатын өйрәнү тарихы” кыскача гына яктыртыла. Монда татар милли фольклористикасы формалашу турында да кызыклы фикерләр әйтелә[3]. Төп игътибар XIX гасырда татар халык иҗатын өйрәнүгә юнәлтелә. Ул: “XIX йөз — Россия тарихында, шул исәптән татар халкы тарихында да катлаулы һәм каршылыклы чорларның берсе. Безнең өчен бу очракта иң мөһиме — гуманитар фәннәрнең бер тармагы буларак татар фольклористикасының барлыкка килүе һәм формалашуы”[4],— дип билгеләп тә үтә. Мисал буларак К.Фукс, К.Насыйри,

---

[1] Урманче Ф.И. Татар халык иҗаты.— Казан: Мәгариф, 2002.— 335 б.

[2] Ярми Х. Татар халкының поэтик иҗаты.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1967.— 308 б.

[3] *Карагыз:* Урманче Ф.И. Татар халык иҗаты.— Б.18–21.

[4] Шунда ук.— Б.19.

В.В.Радлов, Г.Н.Потанин һәм Н.Ф.Катанов, С.Г.Рыбаков кебек галимнәрнең бу юнәлештә керткән өлешләренә фәнни югарылыкта бәяләмәләр бирелә, аларның галим буларак эшчәнлекләре яктыртылып узыла[1]. Шулай итеп, бу хезмәттән XIX йөздә татар фольклористикасы нинди булганлыгы безнең күз алдыбызга килеп баса. Әмма мәсьәләнең барлык яклары да ачылып беткәнме дигән урынлы сорау да туа. Дөрес, Ф.И.Урманче бу хезмәтендә андый, без искәрткән максатны куеп эш итми, чөнки аның ул монографиясе асылда югары уку йортлары һәм колледжлар өчен дәреслек сыйфатында язылган. Димәк, "XIX йөздә татар халкы иҗатын өйрәнү юнәлешләре" дигән тема әлегә фольклористика фәнендә көн тәртибенә куелган һәм тикшерелгән мәсьәләләрдән санала алмый. Әмма татар халык авыз иҗатын өйрәнү барышы безне һаман да татар фольклористикасының "чишмә башына" әйләнеп кайтырга мәҗбүр итә.

Татар фольклористикасы үсешенә зур хезмәт куйган дистәләрчә галимнәребезнең исемнәрен һәм хезмәтләрен санап китә алабыз. Әмма ул безнең максатыбызга керми. Язмабызның дәвер чикләрен XIX гасыр кысаларыннан ары җәелдермәскә, өйрәнелгәнне кабатланмаска булдык.

Билгеле булганча, 1878 нче елда Казан университеты каршында "Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте" төзелә [2]. Анда А.Соловьев, И.Ф.Готвальд, Н.Ф.Катанов, К.Насыйри, Ш.Мәрҗани, Г.Ильяси, Ш.Әхмәров һәм башка галимнәр зур эшчәнлек күрсәтәләр [3]. Бу җәмгыятьнең төп максатларыннан берсе буларак татар халык иҗатын барлау, җыйнау һәм тикшерү эше тора. Алар аны этнография гыйлеме белән бәйләнештә алып барганнар, халыкның аңын, дөньяга карашын аңларга-аңлатырга һәм фольклоры аша бәяләргә омтылганнар. Бу юнәлештә фәнни системалар барлыкка китереп, татар рухи дөньясын гыйльми югарылыкта тикшерүдә һәм бәяләүдә аерым уңышларга да ирешкәннәр. Бу

---

[1] Урманче Ф.И. Татар халык иҗаты.— Б.19–20.

[2] Гайнуллин М.Х. Татарская литература XIX века.— Казань: Татар. кн. изд-во, 1975.— С.34.

[3] Татар әдәбияты тарихы: Алты томда.— Т.2.— Б. 556.

мәсьәләләр бүгенге көнебездә дә әһәмиятле булып кала бирәләр.

Казан университеты каршындагы “Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте”нең эшчәнлеге турында тулы, махсус бер монографик хезмәт юк, бигрәк тә аның фольклористика өлкәсендәге эшчәнлеге бөтенләй диярлек яктыртылмаган. Дөрес, аерым галимнәребезнең хезмәтләрендә бу хакта берникадәр мәгълүматларны табарга мөмкинбез, әмма алар да, мәсьләне үзәккә алып, киң планда гыйльми тикшеренүләр уздырмаганнар.

XIX гасырда татар фольклористикасы гыйлемен XVIII йөз европа мәгърифәтчеләре куйган нигездә өйрәнүче һәм үстерүче төп галимнәребездән берсе Каюм Насыйри булды[1]. Аның эшчәнлеге татар фольклористика фәнендә XX йөз башыннан бирле өйрәнелеп һәм бәяләнелеп килде, әмма төп хезмәтләрнең берсен галим Хуҗиәхмәт Мәхмүтов башкарды. Ул “Каюм Насыйри һәм татар фольклористикасы” мәкаләсе белән К.Насыйриның татар халык иҗатын җыеп эшкәртүенә бәйле аерым томлык бастырып чыгарды[2]. Болар барысы да безнең фәнни эзләнүләребезнең нигезләрен тәшкил иттеләр.

Билгеләп узганыбызча, бүгенге татар фольклористика гыйлеме шактый югары үсешкә ия, һаман да халык авыз иҗатын өйрәнү, барлау һәм туплау эше белән бергә, ул ядкәрләрне фәнни нигездә анализлау һәм системага салу да дәвам итә. Татар фольклористикасы тарихын галимнәр хаклы рәвештә Мәхмүд Кашгариның “Диване лөгатет-төрек” сүзлегеннән башлап китәләр. Аңа да багышланган шул ук галим Х.Мәхмүтовның аерым хезмәте дә бар[3].

---

[1] Ярми Х. Татар фольклорын җыйнау һәм аны бастырып чыгару өлкәсендә Каюм Насыйри эшчәнлеге // Каюм Насыйри: 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары).— Казан: Таттосиздат, 1948.— Б.97–106.

[2] Насыйри К. Сайланма әсәрләр: 4 томда.— Т.III / Төзүчесе, гарәп графикасындагы аерым текстларны гамәлдәге язуга күчерүче һәм кереш мәкалә авторы *Хуҗиәхмәт Мәхмүтов*.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.— 384 б.

[3] Мәхмүтов Х.Ш. Мәңгелек ядкәр.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2002 .— 127 б.

Халкыбызның иҗаты бик борынгы заманнардан бирле яшәп һәм үстерелеп киленгән, ашуг, акын, чәчән кебек импровизаторлар, әкиятче бабайлар һәм әбиләр аларны бүгенге көннәргә кадәр китереп җиткергәннәр. Халык авыз иҗаты халыкның ышанулары, дине һәм дөньяга карашы үзгәрү белән бергә берникадәр трансформацияләнгән, әмма аның нигезе шул килеш кала килгән. Кайбер борынгырак фольклор иҗаты жанрлары кулланылыштан төшеп калганнар, әмма алар бүгенге көнгә кадәр сакланып калынган күп кенә әдәби һәм язма истәлекләрнең протографлары буларак хезмәт иткәннәр. Алар безнең үткәнебезне, бүгенгебезне һәм дә киләчәгебезне дөрес күзаллауга, хәтеребезне яңартуга, фикер офыкларыбызны киңәйтүгә, холкыбызны аңларга һәм бу дөньяда нәрсә өчен, нигә яшибез дигән сорауларга ачык кына җавап бирергә, шушы сорауларга җавапларны төшенергә турыдан-туры ярдәм итәләр. Шунлыктан бүгенге көндә дә халык иҗаты әсәрләрен җыю һәм аларны саклау, өйрәнү, фән өчен генә түгел, гомумән дә җәмгыятебез өчен бәяләп бетергесез иҗтимагый-тарихи әһәмияткә ия.

Тагын да шунысы бар: төрки халыкларның ышанулары буенча, әгәр дә халык иҗат иткән дастанны, бәетне һәм гомумән дә һәртөрле әсәрне кыскартсаң — гомерең дә кыскара, имеш. Фольклор әсәрләренең борынгыдан сакланып килүендә бу ырымның да роле булгандыр мөгаен?

Татар фольклористикасы катлаулы үсеш юлы кичергән. Ул XIX йөзнең икенче яртысына кадәр Шәрык мәдәниятенә хас фәнни классификацияләү кысаларында яшәгән, аерым алганда сүзлекләр һәм шәрех китапларында фольклористикага кагылышлы шактый кызыклы мәгълүматлар бар. Таҗетдин Ялчыголның “Рисаләи-Газизә” китабында да фольклористика гыйлеменә бәйле материалларны таба алабыз[1]. Аларны без аерым өйрәнү объекты дип саныйбыз.

---

[1] *Карагыз:* Ялчыгол Т. Рисаләи-Газизә / Әсәрне басмага әзерләүче (гарәп графикасындагы текстларны укып, басмалар арасындагы аермалыкларны күрсәтеп, гамәлдәге язуга күчерүче, аңлашылмаган сүз-гыйбарәләрне һәм юлларны тәрҗемә итүче, тиешле шәрехләр бирүче) һәм кереш мәкалә авторы Миңнегулов Х.Й.— Казан: Иман, 2001.— 480 б.

XIX гасырның икенче яртысыннан татар фольклоры европачалык позицияләреннән торып өйрәнелә башлый. Фольклористика фәне ул чорда үз гыйльми тикшеренү системаларын булдыра һәм шул юнәлешне үстерү юлына баса. Әмма бу процессның үз каршылыклы якларын исәпкә алмыйча мөмкин түгел. Фольклористика гыйлеме әле XIX гасырда да этнография фәне кысаларында берникадәр кала бирә, ягъни ул этнография фәненең бер өлеше буларак билгеләнә килә. Моның шулай булганлыгын Казан университеты каршындагы “Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте” бастырып чыгарган гыйльми язмалар да раслап торалар.

Фольклористика гыйлеме белән география җәмгыятьләре дә кызыксынганнар. Алар аны география гыйлеме белән бәйләп караганнар. Мисалга Санкт-Петербург университеты каршындагы География җәмгыятенең XIX йөзнең беренче яртысыннан ук җәелдергән эшчәнлеген һәм бастырып чыгарган гыйльми хезмәтләрен китерергә булыр иде.

Фольклор гыйлеме белән дин белгечләре дә кызыксынганнар. Алар халык әкиятләре, риваятьләре ярдәмендә дөньяны милли күзаллау үзенчәлекләрен, дини йола һәм гадәтләрне өйрәнгәннәр һәм өйрәткәннәр. Асылда рус елъязмачыларын да моңа мисал буларак китерә алыр идек. Безнең татар галимнәре арасында, Т.Ялчыгол кебек үк, бу өлкәдә Гали Чокрый шактый зур эшчәнлек алып барганлыгын искә алырга мөмкин[1].

Халык иҗатын өйрәнү һәм халык иҗаты әсәрләре тәэсирендә әдәби иҗат белән язучылар һәм шагыйрьләрнең шөгыльләнүен дә искәртеп үтәргә тиешбез. Ул алар өчен бетмәс-төкәнмәс рухи чыганак булып тора. Һәр дәвердәге әдипләр дә халык иҗатына азмы-күпме мөрәҗәгать иткәннәр һәм аның үрнәкләрен үз иҗатларында файдаланганнар.

---

[1] *Карагыз:* Чокрый Г. Дастан хаҗнамә / Әсәрне басмага әзерләүче — Гайнетдин Мәсгут.— Казан: Иман, 2002.— 112 б.

1

К.Насыйриның фәнни эшчәнлеге 1855 нче елдан башланып китә. Бу елда аны “Духовное училищега татар теле укытучысы итеп чакыралар”[1]. Алдында торган төп бурычларның берсе буларак, ул татар телен укучыларына мөмкин кадәр яхшырак өйрәтү тиешлеген аңлап эш иткән. Аңа кадәр дә татар теле төрле уку йортларында укытылган, Казан университетында да татар теле предмет рәвешендә өйрәнелгән. К.Насыйри аларда булган тәҗрибәләрне үзләштерми калмагандыр? Аның Казан университетына ирекле тыңлаучы сыйфатында йөрүе дә[2] шуның белән бәйләнгән булырга тиеш. Рус телен өйрәнә башлавы да татар телен өйрәтү практикасын көчәйтү өчен файдаланылган дия алабыз. Шунысы әһәмиятле һәм безнең өчен кызыклы: К.Насыйри “китап теле”н түгел, бәлки татар җанлы сөйләм телен өйрәнүгә зур игътибар бирә. Бу аның шушы чорда тел гыйлеменә бәйле хезмәтләреннән дә аңлашылып тора. Дөрес, ул “китап теле”н, ягъни иске татар әдәби теле — төрки телне инкарь итмәгән, әмма җанлы сөйләм теле һәм аның милли элементлары аны күбрәк кызыксындырган. Ә җанлы сөйләм теле исә халык авыз иҗатының төп нигезен чын мәгънәдә тәшкил итә.

Шушы чорда К.Насыйриның фәнни карашлары барлыкка киләләр һәм, формалашып, үсеш ала баралар. Ул Шәрык филология гыйлеме кысаларында һәм өйрәтмәләре нигезендә фикер йөртүдән берникадәр ерагая, европа мәгърифәтче галимнәре тарафыннан барлыкка китерелгән һәм үстерелгән европача методларга һәм методологияләргә күчеш этабын кыю уза. Шушы вакыттан башлап халык сөйләмен өйрәнү максатларында халык иҗаты әсәрләре, фольклористика гыйлеме белән кызыксынып китүе ачык сиземләнеп тора. Безнең белүебезчә, К.Насыйри татар гыйлем дөньясында этнография фәнен яңача нигезләп, үстереп җибәргән галим дә. Әлбәттә аның ул хезмәтләре XVIII һәм аңа кадәрге булган татар сәяхәтче галимнәренең этнографик күзәтүләреннән фәнни гомумиләштерү югарылыгы белән, мәсьәләгә әтрафлы

---

[1] Татар әдәбияты тарихы: Алты томда.— Т.2.— Б.259.
[2] Шунда ук.

аңлатма бирергә омтылыш ягыннан аерылып торалар. К.Насыйри фольклор гыйлеменә этнография фәненең бер тармагы буларак карый гына түгел, ул аны аерым фәнни өлкә рәвешендә аерып чыгару дәрәҗәсенә кадәр җитлеккән галим дә. Моның дәлиле баларак фән кешеләре “Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият” (“Әдәбият турында мәҗлесләрнең җимешләре”) хезмәтен атыйлар[1]. Бу чыннан да шулай. “Фәвакиһел-җөләса” хезмәте К.Насыйриның фикерләве, дөньяга карашы, әдәбиятны аңлавы чын мәгънәсендә фольклорчы галимнәргә хас икәнлеген бөтен тулылыгы белән диярлек күрсәтеп тора. Шушы хезмәтендә ул хәтта, аерым алганда, дини мәсьәләләрдә дә киң белемле, халык рухын һәм әдәп-әхлак кануннарын яхшы тоеп эш итүче галим сыйфатында чыгыш ясый. Моңа исә “Мәҗмәгыль-әхбар” (“Хәбәрләр җыентыгы”) китабы белән 1859 нчы елда юл сала.

К.Насыйриның һәр мәсьәләдә халыкчан әдип һәм галим төсен алуының төп сәбәбе әлбәттә фольклорчы булуына барып тоташа. Ул безнең әдәбиятыбызны нәкъ менә шуның белән бәйле рәвештә, ягъни халыкчанлыгы аркасында, мөмкин кадәр гавам рухына таба, халыкка, аның тормыш-көнкүреше мәсьәләләрен яктыртуына йөз белән бора алды. Әмма үзе, әсәрләреннән күренгәнчә, һаман да урта гасырлардан килгән язма әдәбиятка хас кыйсса һәм хикәят кысаларыннан котылып җитмәде. Бу яктан ул берникадәр каршылыклы да булды. Хәер, Европада Яңарышны башлаган әдипләрдән итальян гуманисты Җиованни Боккаччио (Giovanni Boccaccio, 1313 – 1375) // Джованни Бокаччо нәкъ шундый әдипләрдән түгел идемени? Аның да данлыклы әсәрләре, мәсәлән “Декамерон”ын гына алыгыз, урта гасыр әдәбиятларыннан килгән мотивларга һәм сюжетларга корылган. Язучы аларны шулай итеп үзгәртеп эшләгән ки, ул новеллалар гуманистик идеалларга хезмәт итә башлаганнар[2]. Тагын да шунысы бар,

---

[1] *Карагыз:* Ярми Х. Татар фольклорын җыйнау һәм аны бастырып чыгару өлкәсендә Каюм Насыйриның эшчәнлеге.— Б.100–101.

[2] *Карагыз:* Алексеев М.П., Жирмунский В.М., Мокульский С.С., Смирнова А.А. История зарубежной литературы = Средние века и Возрождение: Учебн. пособие для филол. спец. ун-тов и пед. ин-тов.— 3-е изд.— М.: Высш. школа, 1978.— С.228–247.

XX гасыр ахырында безнең татар галимнәре XIII йөздән башланган Европага хас Яңарыш хәрәкәте үзенчәлекләрен, механик рәвештә аңлап һәм кабул итеп әлбәттә, татар әдәбиятының К.Насыйри һәм Г.Искакый чорларына күчереп куйдылар. Тарихи үсеш мотивларындагы охшашлык ул тарихның кабатлануы кебек тоела гына икәнлеген исәпкә дә алмадылар. Татар җәдиди хәрәкәте белән Европа Яңарышы охшаш кебекләр, икесе мәгънәдәш тә сыманнар. Тик татар җәдитчелеге ул — модернистик хәрәкәт, модернизм, европача модернизмның бер күренеше. Моны кайбер галимнәребез әле шушы XXI гасыр башында да аңлый алмыйча аптырыйлар.

К.Насыйрига килгәндә, инде билгеләп үткәнебезчә, татар халык иҗаты белән кызыксынуы аның татар телен фәнни нигездә өйрәтү өчен гыйльми эзләнүләргә тотынуы белән дә бәйле иде. Духовное училищеда укытканда ул татар теленең язма һәм сөйләм кагыйдәләренең үз чорына хас фәнни казанышлары һәм таләпләре югарылыгында эшләнелмәгән булуына игътибар итә. Аның физика, биология фәннәре белән кызыксынуы да иң беренче чиратта мөгаен да шушыларга бәйле булгандыр? Чөнки татар телендә сүзләрнең дөрес яңгырашын тәэмин итү өчен фонетика гыйлемен яхшы белергә, шул фәнни өлкә таләпләрендә авазлар системасын һәм үзенчәлекләрен тикшереп чыгарга кирәк. Кайсы авазны әйткәндә авыз куышлыгында нинди әгъзаларның катнашы барлыгын ачыклау эше генә дә җиңел башкарылмый. Моны дәлилләп төшендереп бирергә кирәк. Әүвәл башлап шушы эшкә тотынуы аркасында К.Насыйри татар тел гыйлемен яңа фәнни баскычларга күтәрә алды. Аның ул өлкәдәге уңышлары, мәсәлән, "Краткая татарская грамматика, яки Нәхү китабы"нда 1860 нчы елда басылып та чыга[1]. Бу 79 сәхифәдән гыйбарәт булган дәреслек-кулланмасы русчаны өйрәнүче татарларга һәм татарчаны өйрәнүче урысларга тәкъдим ителә, үзенең универсальлеге белән аерылып тора. Хезмәт К.Насыйриның тел гыйлеме белән никадәр җитди һәм фәнни-гамәли нигезләрдә шөгыльләнгән булуын күрсәтеп тора. Бүгенге

[1] Каюм Насыйри: 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары).— Б.142.

көнебездә тел гыйлеме үсеше асылда ул башлаган юл белән дәвам итә дия алабыз.

Бу мәсьәләдә тел галиме Ш.Рамазанов болай дип язып чыккан иде: “... XIX нчы йөзнең соңгы яртысына чаклы татар әдәби теленең теоретик нигезләре, сөйләм һәм язу нормалары, стилистик алымнары билгеләнмичә килде. Бу мәсьәләләрне һәм бу идеяләрне беренче буларак К.Насыйри күтәреп чыкты. Татар милли әдәби телен нигезләү, аның потенциаль мөмкинлекләрен һәм бик нечкә хасиятләрен ачып бирү, грамматик, орфографик һәм орфоэпик нормаларын кагыйдәләштерү бурычларын тарих Насыйрига йөкләгән”[1]. Әмма телне сөйләмнең үзеннән, аның үзенчәлекләрен барлау эшеннән башка тикшереп булмый дип беләбез, ягъни, телнең үзенчәлекләре сакланган “тормыш материалы”н барлау һәм өйрәнүдән гайре генә К.Насыйри да уңышка ирешә алмаган булыр иде. Ул моны яхшы аңлап эш иткән. Шунлыктан К.Насыйри татар җанлы сөйләменең сәнгатьчә үзенчәлекләре гасырлардан гасырларга үстерелә килгән халык авыз иҗаты ядкәрләренә мөрәҗәгать иткән, аларны җыйнап, эшкәртеп, китаби дәрәҗәгә җиткергән һәм бу аның язучылык таланты ачылуга да зур этәргеч биргән. Шул ук 1860 нчы елда ул, “Нәхү китабы” белән берлектә, аңарга ярдәмлек сыйфатында уйланылып та, аерым китап итеп 12 сәхифәдән торган “Буш вакыт” тупланмасын бастырып чыгара һәм аны уку китабы буларак укучыларына тәкъдим итә[2]. Без андагы әсәрләрнең асылда халык иҗаты материалларыннан гына торганлыгын бәхәс итмибез. Башка халыкларның әдәбиятыннан “тәрҗемә” ителгәннәре дә очрый дип ашыгыч нәтиҗә дә чыгара алмыйбыз, әмма шунысын ассызыкларга тиешбез: К.Насыйри бу хезмәтендә халык иҗаты, халык сөйләменең

---

[1] Рамазанов Ш. Каюм Насыйри — татар әдәби теленә нигез салучы.— Каюм Насыйри: 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары).— Б.63.

[2] Бу хезмәте 1963 нче елда 87 сәхифәгә җиткерелеп, яңа вариантта бастырылып чыгарыла, 1909 нчы елда аны “Мәгариф көтепханәсе” кабаттан бастырырга әзерли һәм “Балалар көтепханәсе” сериясеннән 5 нче китап буларак укучыларына тәкъдим итә. Бу факт исә К.Насыйри иҗатының XX йөз башында да актуаль булганлыгы хакында сөйли.

үзенчәлекләрен шактый яхшы күзаллап һәм аның кысаларын, характерын, агышын белеп, төшенеп эш иткән. Аның әдәби фикерләве, әдәби образлар, сурәт-картиналар тудыру, вакыйгаларны тасвирлау үзенчәлекләре нәкъ менә фольклор, халык иҗаты нигезендә формалашалар һәм ул безгә шунлыктан халыкчан рухтагы әдип буларак тоела.

Шулай итеп, без бу фикерләмә нигезендә шундый дәлилгә дә килә алабыз: К.Насыйриның иҗатында халыкчанлык татар фольклорын яхшы белүе аркасында һәм халык иҗатын өйрәнүе сәбәпле барлыкка килә һәм үсеш ала. Шуны да онытмыйк, ул бит, үз чорының башка әдипләре кебек үк, татар мәдрәсәсендә белем алган, китап ятлап, "китабат теле"н генә белергә мәҗбүр ителгән шәкерт булган. Аның хакында М.Гайнуллин: "Башлангыч белемне атасыннан ала. 1841 елда аны Казанның бишенче мәхәлләсендәге мәдрәсәгә укырга бирәләр"[1],— дип яза. Фикер уңаеннан шуны да искәртик, монда Казанның Әхмәдия мәдрәсәсе хакында сүз бара һәм ул татарның иң алдынгы уку йортларыннан берсе булган, анда данлыклы Әхмәт хәзрәт укыткан[2]. Әмма К.Насыйриның әдип буларак формалашуында, безнең уебызча, Духовное училище укытучыларыннан саналган, төрки халыкларның теле, әдәбияты һәм тарихы белән даими кызыксынган, шушы өлкәдә фәнни хезмәтләр язган В.В.Радловның тәэсире дә зур булган. Нәкъ менә ул аның күңелендә татар теленә һәм халык иҗатына мәхәббәт уятканлыгы күз алдына килмичә калмый. Бу хакта галим Габдрахман Сәгъди дә үз заманында боларны язып уза: "1850 нче елда башлангыч дини рус мәктәпләрендә (Духовное училищеда) шулай ук Духовная семинариядә татар телен укытырга чакырылып, рус гыйлем дөньясына барып керә һәм мәшһүр Радлов кебек галим, европа тюркологлары белән якыннан катнаша башлый. Соңыннан, 1873 нче елда татарлар өчен ачылган "Учительская школа" янындагы (бу школа 1872 нче елда ачыла) "Рус-татар башлангыч мәктәбе"нә

[1] Татар әдәбияты тарихы: Алты томда.— Т.II.— Б.259.

[2] *Карагыз:* Сәгъди Г. Татар әдәбияты тарихы: Дәреслек-кулланма.— Татар коммунистлар университетында укылган әдәбият дәресләренең ысулы һәм материаллары буенча язылды.— Казан: Татарстан дәүләт нәшрияты басмасы, 1926.— Б.42.

рус теле укытучысы, ягъни татарлар арасыннан чыккан беренче учитель булып хезмәткә керешә; татар балаларына русча укыта башлый”[1].

Василий Васильевич Радлов (үз исеме — Фридрих Вильгелем, 1837–1918) 1884 нче елда Санкт-Петербург Фәннәр академиясенең академигы итеп сайлана, төрки телләрне өйрәнүдә һәм фәнни тикшерүдә, аларны классификацияләүдә зур эшләр башкара, гомере буе төрки халыкларның җанлы сөйләме чагылыш тапкан фольклор әсәрләрен туплап бастырып чыгаруга зур көч куя[2].

К.Насыйриның фольклористикага тартылуы, шулай итеп, очраклы гына булмаган һәм аның дөньяга карашы формалашуда, гыйльми фикерләре һәм күзаллаулары барлыкка килүдә һәм үсешендә, иҗатының халыкчан нигезләрдә башланып китүендә, европачыл мәгърифәтчелек позицияләренә күчешендә В.В.Радлов зур роль уйнаган. Без моны фольклор һәм әдәбиятның тыгыз бәйләнешен дәлилләүче мисал буларак та билгели алабыз.

К.Насыйриның “Буш вакыт” хезмәте 1909 нчы елда яңача басмада дөнья күрә. Китапта “Наширдан бер-ике сүз” дигән кереш мәкалә урнаштырыла. Анда: “Тәрбиятел-этфаль[3] фәненә маһир галимнәр балаларның зиһеннәрене ачу, мәгълүматларны күбәйтү өчен төрлечә юллар күрсәтәләр. Болар арасында иң мәкъбуль күрелгән тарикълардан[4] берсе — сабактан бушаган заманнарда баланың кулында бик җиңел тел илә ачык итеп язылган китаплар булдырудыр. Фәнгә яки әдәбиятка даир[5] бик асат тел илә язылган китапларны уку һәм аңлауда бала һичвакыт мөгаллимгә мохтаҗ булмый. Әгәр китаплар да бала ялыкмаслык рәвештә кыска һәм кызыклы нәрсәләрдән гыйбарәт булса, үз-үзлегеннән бик күп

---

[1] Сәгъди Г. Татар әдәбияты тарихы.— Б.43.

[2] *Карагыз:* Татарский энциклопедический словарь / Глав. редактор — *Хасанов М.Х.*— Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 1999.— С.460.

[3] Тәрбиятел-этфаль — балалар тәрбиясе.

[4] Иң мәкъбуль күрелгән тарикълардан — иң лаеклы күрелгән методлардан.

[5] Даир — караган.

мәгълүматы артып, зиһене ачыладыр. Ләкин балага биреләчәк китапларның балалар өчен махсус язылган булуына дикъкать кылынырга тиешледер. Баланың кулына зиһене җитмәслек агыр язылган китаплар керсә, ул вакыт укудан тәмам гайрәте чигәдер”[1], диелгән.

Бу урында наширларның балалар әдәбиятына мөнәсәбәте генә түгел, бәлки К.Насыйриның эшчәнлегенә дә тирән эчтәлекле бәя бирелгән һәм аның фольклористика өлкәсендәге хезмәтләренең төп тенденцияләре дә ачыклап күрсәтелгән. Болардан чыгып без К.Насыйриның җәдиди мәгърифәтче позицияләреннән торып эш иткәнлеген аңлап торабыз. Аның карашынча татар фольклоры милләтебезне кызыксындырган аң-белемне киңәйтүдә зур әһәмияткә ия саналган.

“1860 нчы елны басылып чыккан “Буш вакыт” исемле әсәре татар телендә, бер яктан, фәнни-популяр әсәрләрнең берсе була, икенчедән, балалар өчен язылган, укырга күңелле итеп төзелгән фәнни-әдәби әсәрләрнең дә башлангычы булып тора”,— дип аңлаткан үз вакытында галимә Җ.Вазеева[2]. Дөрес, бу фикер белән өлешчә генә килешергә мөмкин, чөнки балалар өчен фәнни, фәнни популяр, фәнни-әдәби хезмәтләр татар әдипләре тарафыннан элгәрерәк чорларда да тудырылып килгәннәр. Әмма К.Насыйриның бу хезмәте асылы белән башка төрле, ул нәкъ менә европачыл җәдиди мәгърифәтче карашлары кысаларында тудырылган. Тагын да шунысын онытмыйк: “Буш вакыт”ның татар мәдәнияте үсешендәге әһәмиятен кабаттан өйрәнәсе бар әле. Ул безнең яңа, ягъни җәдиди әдәбиятыбызның балалар өчен язылган тәүге әдәби әсәре дә түгелме? Чын мәгънәсендәге балалар әдәбияты Европада Ш.Перроның (1628-1703) халык иҗатыннан алынган экиятләреннән (1697 нче елдан) башланып киткән кебек[3],

---

[1] Насыйри К. Буш вакыт: “Балалар көтепханәсе”ннән беренче җөзьә.— Казан: Мәгариф көтепханәсе, 1909.— Б.3–4.

[2] Вазеева Җ. Каюм Насыйри һәм балалар әдәбияты // Каюм Насыйри: 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары).— Б. 110.

[3] ***Карагыз:*** Зарубежная детская литература: Учебник для студентов библ. фак. ин-тов культуры / Сост. С.Н.Черняевская.— 2-е изд., перераб. и доп.— М.: Просвещение, 1982.— С.27-28.

бездә ул К.Насыйриның “Буш вакыты”ннан (1860 нчы елдан) беренче адымнарын ясамыймы? Әлбәттә!

1868 нче елда чыгарылган “Буш вакыт”ның эшләнеше 1860 нчы елгысыннан шактый аерылып та тора. Китап 12 битледән 87 сәхифәгә җиткерелә. Аның тышлыгы да башка рәвешле формалаштырыла, анда: “Буш вакытларда сүзләр, берничә төрле нәрсәләр хакында. Бу дөньяда ни-нәрсәләр, ни эшләр бар. Белергә мәел итүчеләрне [1] белемләндерер өчен Габделкаюм Габденнасыйр углы тәэлиф итеп бастырды”,— дип куелган. Шушы ук хәлдә, үзгәртелүсез, китап 1884 нче елда кабат дөнья күрә.

“Буш вакыт” китабына (аның да 1868 нче елгы вариантына) мөрәҗәгать итсәк, бусы җыелма дәреслек-өйрәтмәлек рәвешен дә алган. Аның башлангыч 44 сәхифәсе татарча-русча сүзлекчәдән гыйбарәт. Алга таба 43 сәхифәдә анатомия, минералогия, табигать күренешләре хакында фәнни-популяр, фольклор һәм әдәбият материаллары бирелә. Икенче бүлек “Яңа дөнья” турында, ягъни Американы Христофор Колумбның ачуы белән бәйләнештә сөйләнелә, аннан ары бүлекләр Җир шары, һава, күк йөзе, ел фасыллары, пыяла, тимер, кит балыгы, болан һәм башкалар турында. К.Насыйри алар хакында халыкчан тел белән, җиңел аңлаешлы итеп сөйли. Болар, иң беренче чиратта, европачыл җәдиди мәгърифәтчелек идеяләрен тарату булса, икенчедән, балаларга белем бирү өчен шактый җиңел итеп төзелгәннәр, өченчедән, уку әсбабы хезмәтен дә үтиләр. Аның төзелеше, методик яктан төгәл эшләнелеше татар телен өйрәнүчеләр өчен аталганлыгын да аңлатып торалар һәм безнең бу хезмәтне “дәреслек-өйрәтмәлек” дип билгеләвебезнең дөреслеген раслыйлар. Балалар җәдитчелек матур әдәбияты бездә шулай киң кырлы, тирән эчтәлекле, мәдәни-мәгънәви юнәлеш алып башланып китә. Аның татарның акылына, рухына, аңына муафыйк килүе соклandыра. Татар акылы практик юнәлешле, рухы ихтыярый куәткә ия, аңы табигыйлекне сөя.

“Буш вакыт”ны язганда К.Насыйри, европачыл җәдиди мәгърифәтчелек карашларыннан тыш, хәтта фольклористик

[1] Мәел итүчеләр — теләүчеләр.

фикерләмәләрдән дә чыгып эш итә. Ул, һәр хәбәрен халыкчан рухта бирү белән бергә, аларга татар экиятләренә хас аңлатып тасвирлау алымын да сала. Бу юл белән әдип китап башында ук язып белдергән үзенең максатына бара: милләтне аңлы, белемле итү, томаналыкта адашудан саклау. Татар әдәбиятында нәкъ менә шушы уңай башлангыч җәдиди мәгърифәтчел әдәбиятны тудыра да инде, Әхмәтҗан Биктимеров, Әхмәт Хуҗаши, Әхмәтфәрит Ширвани кебек XIX йөз ахыры – XX гасыр башы әдипләренең иҗатында К.Насыйриның “Буш вакыт” хезмәтенең урыны зур. Р.Фәхретдинов исә тулысы белән К.Насыйри юлындагы әдип буларак хаклы рәвештә бәяләнә ала. Аларны халкыбызның алга дөрес юлда китеше кызыксындырган. Болар — татар милли аңын башлап формалаштыручылар.

“Иҗтимагый прогресс идеясе белән нык сугарылган Каюм Насыйри,— дип язган Х.Ярми,— халыкның үз тарихы белән янәшә баручы, аерым урыннарда халыкның тарихын аңлауга ярдәм итүче халык авыз иҗатын яшәүчән, тормышны алга этәрүчән культура җимеше итеп карады”[1]. Аның борынгы Болгарстан һәм болгарлар, кадими-тәүге Бөек Татарстан һәм татар халкы тарихына кагылышлы иске язма һәм фольклор истәлекләрен өйрәнүе, аларга биргән бәяләмәләре милләтебезнең тарихын аңларга, төшенергә омтылуы белән бәйле иде. Ул “Таварихы Болгария”, “Дәфтәре-Чыңгызнамә” кебек борынгы татар язма истәлекләренә дә бик сак карады, Ш.Мәрҗани бу әсәрләрне тәнкыйть итеп чыкканда, К.Насыйри “Таварихы Болгария”ны да яклый алды. Билгеле инде, моның аркасында алар арасында каршылык та барлыкка килде. Әмма ул галимнәр икесе дә үз позицияләрендә тотрыклы кала бирделәр. Хикмәт нәрсәдә иде соң? Җыйнап кына әйткәндә, К.Насыйриның фольклорист булуында һәм халык күңеленә ышаныч белән каравында, ә Ш.Мәрҗаниның дәлилле китап сүзенә, расланган мантыйкый фикердә

[1] Ярми Х. Татар фольклорын җыйнау һәм аны бастырып чыгару өлкәсендә Каюм Насыйриның эшчәнлеге // Каюм Насыйри: 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары).— Б.97.

рационалист буларак эш итүендә иде. Бу факт исә шулай ук татар фикер үсешенең XIX гасырдагы тенденцияләре белән бәйле, һәм ул хәтта фольклористика фәненә дә уңай йогынты ясамый калмаган.

Ш.Мәрҗани фольклорист түгел, ул халык иҗатына К.Насыйри кебек зур хөрмәт һәм ихтирам белән карамаган. Аны язма истәлекләр һәм аларның ышанычлы фактларны эченә алулары күбрәк кызыксындырган. Ә К.Насыйри тарихны халык күзаллавы аша өйрәнергә, тикшерергә һәм аңлатырга омтылган. Аларның икесенең дә дөрес юлда булганлыгын билгеләве авыр түгел. Бер-бер тарихи вакыйгага халык үзенчә бәя бирсә, галимнәр аны башкача күзалларга хаклы, хөкемдарлар ул хәлләргә үзләренчә караш-мөнәсәбәтләрен белдергәннәр. Монда аерма — принципларда, хәтта бу аерма шактый зур яки капма-каршы да булырга мөмкин. Һәм шулай булуы зыялы кеше өчен бер дә сәер тоелмый. Хакыйкать тә берьяклы гына булмый.

Халык авыз иҗатын өйрәнү эшчәнлеген К.Насыйриның өч төрле юл белән алып барганлыгын билгеләп үтеп Х.Ярми: “Беренчедән, ул татар фольклорын халыкның үз авызыннан язып ала һәм еллар буенча үз тарафыннан җыйналган фольклорның иң яхшы үрнәкләрен сайлап алып, аны бастырып чыгаруда зур хезмәтләр күрсәтә”[1],— дип яза. Бу өлкәдә әдипнең никадәр зур көч түккәнлеге китапларыннан да күренеп тора. “Икенчедән,— дип белдерә Х.Ярми,— Каюм Насыйри татар халкының аң-белемен күтәрү өчен культура ягыннан алда торган милләтләрдән ярдәм алуын истә тотып, иң элек үз халкының тарихы, тормыш-көнкүреше, дөньяга карашы белән башка халыкларны, бигрәк тә рус халкын таныштыру кирәклеген алга куя”[2]. Монда аның рус теленә татар фольклоры ядкәрләрен тәрҗемә итү фактлары күздә тотыла, билгеле. “Ул татар халкының борынгы ырым һәм ышанулары турында рус телендә аерым мәкаләләр яза”[3].

[1] Ярми Х. Татар фольклорын җыйнау һәм аны бастырып чыгару өлкәсендә Каюм Насыйриның эшчәнлеге // Каюм Насыйри: 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары).— Б.97.

[2] Шунда ук.— Б.97–98.

[3] Шунда ук.— Б.98.

К.Насыйриның фольклористика өлкәсендә башкарган эшчәнлегенә бәя биреп, Х.Ярми: “Өченчедән,— дип белдерә,— Көнчыгыш халыклары фольклорын өйрәнү һәм аның үрнәкләрен татар теленә тәрҗемә итеп, татар халкын алар белән таныштыру өлкәсендә шактый хезмәт күрсәтә”[1]. Монда, әлбәттә, аның “Кырык вәзир”, “Әбугалисина кыйссасы” кебек Шәрык әдәбиятыннан тәрҗемә әсәрләре күздә тотыла. Аларда К.Насыйриның фольклорчы буларак кына түгел, чын мәгънәсендә язучылык осталыгы да ачыла. Шунысын онытмыйк, бу әсәрләр Г.Ибраһимовның “Яшь йөрәкләр” романында сурәтләнгән Галим муллалар заманында барлыкка килгәннәр.

Г.Ибраһимов татар байлары һәм муллалары арасында булган бер сөйләшү вакыйгасын тасвир итеп, Галим мулладан үз укучысы яшь әдип Салих хакында мондый сүзләрне әйттертә: “Сөйләмә шул юкны! Күрдем мин аның ул лыгырдыкларын... Кайчандыр Сабир кибетче йөгереп килгән дә, алтын тапкан адәм кебек: “Хәзрәт, хәзрәт, кара әле,— ди,— синең шәкертең, теге ятим Салих, зур мәртәбәгә ашкан икән... Менә әллә нинди гыйбрәтле нәрсәләр язган... Калада бар халык мактый!”— дип очына. Карасам, Сабирның керткәне әкиятләр, җырлар икән. Өстенә аяк тибеп кычкырдым да, син мине мыскыл итәргә кергәнсең икән дип, эт урынына тиргәп чыгардым. Үзе ахырдан тәүбә итә, юк, ди, хәзрәт, ди, кешеләр мактагач, мин яхшы нәрсә дип белгән идем, ди...”[2]. Мондагы вакыйгалар нәкъ менә К.Насыйри чорларына туры килә. Кадимче, искелек тарафдары булган муллаларның типик йөзе шушы Галим муллада ачыла. Менә аның әдәби иҗат хакындагы фикерләре: “Ул әкиятне кем язмас?.. Имеш, бер кыз булган, кияүгә барган... Ире кыйнаган... Бер шәкерт булан... мәдрәсәдә укыган... кызлар артыннан йөргән... Шуны

[1] Ярми Х. Татар фольклорын җыйнау һәм аны бастырып чыгару өлкәсендә Каюм Насыйриның эшчәнлеге // Каюм Насыйри: 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары).— Б.98.

[2] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.II. Яшь йөрәкләр. Казакъ кызы.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1975.— Б.138.

язалар да китап дип чыгаралар. Җитмәсә җырлар да кушалар”[1].

Г.Ибраһимов язганнарны исәпкә алсак, К.Насыйриның да мондый каршылыкка очраган булуына шик калмый. Әмма ул барыбер дә фидакарьләрчә хезмәт итүеннән туктамаган. Х.Ярминең фикерләре белән дә тулысынча килешә алабыз. Шәрык халыкларының фольклор әсәрләрен үз халкыбызга җиткерүе дигәнендә исә, исәпкә алынып җитмәгән башка бер мәсьәлә дә бар. Ул да булса — “Әбугалисина кыйссасы”, “Кырык вәзир” һәм башка шундый әсәрләрне татар халкы электән белгән, әмма К.Насыйри аларны “яңа әдәби телдә” халыкка тәкъдим иткән. Хикмәте дә шунда, моңа кадәр татар әдипләре төрки әдәби тел кысаларында иҗат итеп килсәләр, К.Насыйри “яңа әдәби тел”не мәйданга чыгарган галим һәм язучы да булды. Ул казан сөйләшенә нигезләнгән әдәби тел нормаларын барлыкка китерде, аның дөрес язу һәм дөрес уку кагыйдәләрен эшләде, үз хезмәтләрен шул кагыйдәләргә таянып язып халыкка җиткерде.

Бу мәсьәләгә аерым тукталып, “Каюм Насыйриның татар телен назари эшләве иң беренче мәртәбә фәнни нигездә, чын татар грамматикасын төзеп бирүендә булды”[2] дип, Г.Сәгъди татар әдәби теле үсешендә XIX йөзнең икенче яртысында “каюмчылар” һәм “гаспринскийлар” юллары барлыкка килүе хакында язды. К.Насыйри юлы, академик М.З.Зәкиев фикерләренә таянып әйтсәк, сепаратизмга корылган иде[3].

Әмма без моны асылда татар милли әдәби телен мәйданга чыгару эше дип бәяләргә тиешбез. Татар халкы XIX йөзнең икенче яртысынача һәммә төрки халыкларга уртак буларак үстерелеп килəнгән төрки әдәби тел чорын К.Насыйри заманнарында узып, иҗтимагый-сәяси яктан тотрыклы һәм алгарышлы фикерле дөнья халыклары белән бергәлекне һәм

---

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.II. Яшь йөрәкләр. Казакъ кызы.— Б.138.

[2] Сәгъди Г. Татар әдәбияты тарихы.— Б.52.

[3] *Карагыз:* Зәкиев М.З. Беренче Бөтенсоюз тюркология съездына Г.Ибраһимов бәяләмәсе һәм хәзерге көн // Галимҗан Ибраһимов һәм XXI гасыр: Тууына 120 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары.— Казан: ИЯЛИ, 2007.— Б.23.

бердәмлекне алга куйган буржуаз милләт сыйфатында формалашуын дәвам итеп, милли әдәби тел рәвешендә казан сөйләшен мәйданга куярлык дәрәҗәдә җитлекте. К.Насыйри, татар әдәби телен Казан татарлары теле нигезендә өйрәнеп, аны гамәлгә куя алуы белән тел өлкәсендә зур галим мәртәбәсендә танылды. Бу аңарга татар фольклорын җыю һәм өйрәнү өчен дә юл ачты. Моны ничек аңларга? Бик гади дә кебек: татар сүзен татар авызыннан җыеп алу өчен язмада бу телнең төгәл чагылуын тәэмин итәргә кирәк. Ә моңа төрки тел нормалары җавап бирми. Димәк, татар теленең үз сөйләм үзенчәлекләрен чагылдыручы язу кагыйдәләрен ачыклау сорала.

Шушы урында Х.Ярми сүзләрен искә алу урынлы булыр. Ул бу хакта болай дип белдерә: "Ачык итеп әйтергә кирәк ки, К.Насыйрига хәтле татарлардан халык авыз иҗатын халыкның үз авызыннан фәнни нигездә җентекләп һәм бөтен нечкәлекләрен истә тотып язып алучылар булмады. Бездә фольклорны турыдан-туры җырчының, экиятченең үз авызыннан язып алу эше Каюм Насыйридан башланып китте"[1].

Халыкның сөйләмен камил рәвештә язып алу өчен әлбәттә шул сөйләмнең үзенчәлекләрен белергә һәм язмада чагылдыру юлларын, сүзләрнең яңгырашын дөрес тасвирлаучы язу кагыйдәләрен ачыкларга һәм булдырырга кирәк, ягъни ул сөйләмне тел гыйлеме ярдәмендә гамәлгә кую сорала. Менә бу яктан К.Насыйрига тел өлкәсендә ясаган үз гыйльми ачышларын практик җәһәттән тикшерү мөмкинлекләре ачыла. Димәк, аның фольклорчы булып китүендә субъектив сәбәпләр дә бар икән. Халыкның теле белән кызыксыну, аны өйрәнү әлбәттә авыз иҗатына карата да мәхәббәт уята. Менә шуның өчен дә филология факультетларында студентларның фольклор һәм диалектология экспедицияләрен оешкан төстә уздыру, практик эшне җәелдерү укыту программаларына

---

[1] Ярми Х. Татар фольклорын җыйнау һәм аны бастырып чыгару өлкәсендә Каюм Насыйриның эшчәнлеге // Каюм Насыйри: 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары).— Б.99.

кертелгән. Әмма аларның зарурлыгын кайбер югары уку йортларында белеп һәм аңлап кына җиткермиләр.

1871 нче елда "Казан календаре"н чыгара башлавы белән К.Насыйри татар милли мәдәни тормышына зур яңалык өсти. Шул ук вакытта анда фольклористиканың тарихи-иҗтимагый әһәмиятен бар тулылыгында аңлавы күзгә да ташлана.

Календарьга материаллар туплау эше шактый катлаулы булган, билгеле. Халык өчен файдалы итәргә тырышканлыгы да ачык сизелә. Календарьның беренче чыгарылышында ук К.Насыйри аның ахыргы өлеше итеп бик әһәмиятле булган бүлек ача һәм исемен "Халык арасында тәҗрибәләр буенча көн вә һава үзгәрүнең галәмәтләре бәянында" дип атый. Бүгенге фәндә аларны "Сынамышлар" дип йөртәләр. "1871 елга "Календарь"да... күк җисемнәренең, хайваннар һәм кошларның үз-үзләрен тотышларына карап һава торышының нинди булачагын белдерүче 81 сынамыш китерелгән. Шулар ук 1879 ел өчен "Календарь"да кабат басылганнар"[1]. 1876 нчы елгы "Казан календаре"нда К.Насыйри шушындый сынамышларны "Халык телендәге сүзләр" башы астында урнаштыра.

Ул җыйнаган сынамышлар халкыбызның күзәтүчән һәм борынгыдан мәдәни халык булуын сөйләүче фактлар буларак бәяләнергә тиешләр. Алар К.Насыйриның шушы фәнни-практик юнәлештәге эшчәнлегенә карата укучыда зур хөрмәт уяталар. "1875 нче елгы календарьда инде халык телендәге сүзләр,— дип бәяләп яза Х.Ярми,— нәкъ халык арасында әйтелеп йөргәнчә матур рифмага салынып китерелә"[2]. Мисал буларак, кайберләрен карап үтәргә мөмкин:

*"Гыйнварь аенда 6-сында тулы ай — язгы ташу суга бай.*
*6-сында бик җылы — кырда икмәк бик куе.*
*6-сында ябалак кар — бик нәфис килер яз.*
*6-сында ябалак кар — кырда икмәк бик уңар"*[3].

---

[1] Мәхмүтов Х. Каюм Насыйри һәм татар фольклористикасы // Насыйри Каюм. Сайланма әсәрләр: 4 томда.— Т.3.— Б. 5–6.

[2] Ярми Х. Татар фольклорын җыйнау һәм аны бастырып чыгару өлкәсендә Каюм Насыйриның эшчәнлеге // Каюм Насыйри: 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары).— Б.99.

[3] Насыйри К. Сайланма әсәрләр: 4 томда.— Т.3.— Б.43.

Болар һәммәсе дә хәзерге ел исәбенә күчергәндә 18 нче январь көненә туры киләләр. К.Насыйри һәр ел фасылына бәйле шушындый милли сынамышларны җыюга бик зур көч куйган. Мондый фидакарь хезмәтне бүгенге көндә бәяләп бетерү мөмкин түгел. Х.Ярминең хәбәренә караганда, шушы рәвешле сынамышлар календарьның 1877 нче елгысына кадәр даими рәвештә бирелеп барыла [1], алары да бер-берсен кабатламаулары белән кызыклы. Асылда бу сынамышлар иртәгәгә яки алдагы көннәрнең ничек булулары хакында гына сөйләп калмыйлар, алар татар халкының милли-мәдәни үзенчәлекләрен дә чагылдыралар.

Аларның күбесе игенчелеккә карый. Игенчелек хәзер дә табигать шартларына тыгыз бәйләнештә яши торган җитештерү-икътисади өлкә. Моны К.Насыйри бик яхшы аңлап эш иткән. Шушы сынамышлар гына да халкыбызның борынгы заманнардан бирле игенчелек белән шөгыльләнгән булулары хакында сөйлиләр. Аларның кайберләре *Никола (Микула), Питрау, Симән, Ыспас* дип аталган керәшен бәйрәмнәре белән бәйле. Мәсәлән:

*“Никола көн җил булса, бөтен җәй җил.*
*Никола җитми җәй булмый,*
*Никола җитми кыш булмый”*[2].

Бу Никола, ягъни Изге Микула бәйрәме, елына ике тапкыр була, аның беренчесе хәзерге ел исәбе белән 21 нче майга туры килсә, икенчесе 18 декабрь көнендә уза. Әмма без шунысын да онытмыйк, бу хисап-сынамышлар кайвакытта һава торышына бик төгәл туры киләләр. Шулай да без аларны шартлы күренеш буларак билгеләргә тиешбез. Бу шартлылыкны борынгы бабаларыбыз да яхшы аңлаганнар, әмма аларга таянмый эш итми калмаганнар. Тагын да шунысына игътибар күзен салырга тиешле: сынамышлар керәшеннәрнеке булмасын, мөселман татарларына карамасын, алар К.Насыйри тарафыннан үзара бәйләнештә

[1] *Карагыз:* Ярми Х. Татар фольклорын җыйнау һәм аны бастырып чыгару өлкәсендә Каюм Насыйриның эшчәнлеге // Каюм Насыйри: 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары).— Б.99.
[2] Насыйри К. Сайланма әсәрләр: 4 томда.— Т.3.— Б.44.

тикшерелгәннәр, ягъни бер-берсенә каршы куелмаганнар һәм әдип тарафыннан дингә бәйле инкарь ителмәгәннәр. Бу факт исә татарларның борынгыдан бер үк халык булуын да раслый. Тагын да шунысы әһәмиятле, бу сынамышларда бәрәңге һәм помидор кебек бакча культуралары искә дә алынмый, ә менә шалкан һәм кыяр турында әйтелә. Болар да кызыклы нәтиҗәләр ясарга, ул сынамышларның борынгы булуларын ачыкларга мөмкинлек бирәләр.

К.Насыйри календарьларында "Казан бәете", "Шыгали бәете" кебек халык иҗаты әсәрләренә дә, Казан шәһәренә һәм Кабан күленә бәйле легенда-риваятьләргә дә урын бирә (мәсәлән, 1881 нче елгысында). "Бу вакытларда инде Каюм Насыйриның халык телендә йөргән төрле тапкыр сүзләр, авыл хуҗалыгы-игенчелек тәҗрибәләре белән бәйләнгән төрле ышануларны гына язып алу белән чикләнеп калмыйча, фольклор әсәрләрен җитди өйрәнә башлауга күчүен күрәбез"[1]. Бу исә фольклористиканың этнографиядән аерылуыннан килгән процесска да бәйле булган.

Х.Ярми шушы елларда К.Насыйриның халыктан җырларны, табышмак һәм мәкальләрне, әкият һәм башка төр жанрларны зур кызыксыну белән фәнни юнәлештә җыярга керешүенә игътибар итә, календарьларында аңлатмалы язулар бирүне шушы фикерен куәтләүче факт рәвешендә китерә[2]. Календарьларында К.Насыйри теге яки бу фольклор әсәренә мөнәсәбәтле махсус аңлатмасын урнаштырып, асылда аларга карата фәнни фикер тудыра. Бәяләмәләре гомумилек характерына ия һәм фәнни югарылыкта булулары белән аерылып торалар, әдипнең чын мәгънәсендә фольклорчы буларак җитлегүе хакында сөйлиләр.

Халык иҗатына игътибар борынгы заманнардан ук үстерелеп килсә дә, "фольклор" термины фәнни кулланылышка бары тик XIX йөзнең икенче яртысында гына

[1] Ярми Х. Татар фольклорын җыйнау һәм аны бастырып чыгару өлкәсендә Каюм Насыйриның эшчәнлеге // Каюм Насыйри: 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары).— Б.100.

[2] Шунда ук.

кертелә[1]. К.Насыйри, фольклористика белән даими рәвештә шөгыльләнеп, халыкның бөек иҗатчы булуын раслаучы шактый күп дәлилләр таба, ул фольклорга халыкның примитив аңы чагылышы дип карамый, бәлки анда мәдәни яктан камиллек үрнәкләрен күрә, таба һәм фикерләрен башкаларга җиткерә белеп эш итә. Бу исә татар фольклористика фәненең төп тенденциясен барлыкка китерә һәм ул К.Насыйри тарафыннан формалаштырыла. Нәкъ менә шушы юнәлештә Г.Тукайның да фикерләре җитлегә һәм ул "Халык әдәбияты" (1910) хезмәтендә шушы юлдан килеп татар халык иҗатына бик югары бәя бирә[2]. Анда хәтта фәнни әһәмияткә ия мондый нәтиҗә чыгара: "Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятымызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр"[3]. Ул монда халык иҗаты матур әдәбиятның нигезе икәнлеген ачык итеп раслый. Тукай чыннан да пәйгамбәрләрчә әйткән, XX йөз шигъриятебез халыкчан рухта, халыкчан алымнарда, халыкчан үлчәмдә, ягъни халык иҗатыннан килгән традицияләр агымында үсте.

К.Насыйриның татар халык иҗатын җыйнап бастырып чыгаруда төп хезмәтләреннән берсе дип әлбәттә "Фәвакиһел-җөләса" китабын санарга кирәк. Дөрес, шушы 609 сәхифәдән гыйбарәт булган күләмле җыентыгының башлангыч өлешен китаби материаллар били, әмма да 546 нчы биттән соң ул татар халык иҗатына караган мәкаль һәм әйтемнәргә игътибарын юнәлтә. Аның фольклорны шушы рәвештә бирүенең хикмәте дә бар. К.Насыйри татар халкының мәдәни үсешен Шәрык халыклары иҗатыннан аерылгысыз үсеш алганлыгын дәлилләүне максат итеп куйган. Шуңа күрә дә, "Кырык бакча" китабы кебек үк, монда гарәп-фарсы халыклары иҗаты белән уртак мотивлар һәм җитди уртаклыклар булган материаллар урын алганнар. Аларны бары тик Шәрык халык әдәбияты ядкәрләре дип кенә түгел, бәлки татарның үзенеке буларак та бәяләргә кирәк. Уртак яшәү

[1] Краткий словарь по эстетике: Кн. для учителя / Под ред. Овсянникова М.Ф.— М.: Просвещение, 1983.— С.181.

[2] Тукай Габдулла. Әсәрләр: Биш томда.— Т.4. Проза. Публицистика (1907–1913).— Казан: Татар. кит. нәшр., 1985.— Б.163–186.

[3] Шунда ук.— Б.177.

рәвеше, дөньяга караш, мәдәни мохит К.Насыйри иҗатында инкарь ителмәде. Бу факт аның чын мәгънәсендә фәһемле, интернационалистик рухлы әдип булуын да дәлилли.

Халык иҗаты ул милли компоненттан гына гыйбарәт түгел, аңарга интернационалистик рух хас. Халыклар аралашмыйча гына яшәмиләр, алар бер-берсенә тарихи, иҗтимагый, гыйльми, әдәби, мәдәни, тәрбияви тәэсирләр ясаудан һичвакыт тукталмаганнар. К.Насыйриның 1884 нче елда басылып чыккан шушы рухтагы “Фәвакиһел-җөләса” хезмәте, шул исәптән 1880 нче елда ук дөнья күргән “Кырык бакча”сы боларның ачык дәлиле булып торалар. Андагы материалларны әдип бары тик Шәрык халыклары иҗатыннан гына алган, алар белән татар халкын таныштыру максаты белән эш иткән дип мәсьәләне җиңелчә хәл итәргә омтылучы галимнәрнең фикеренә катнашып китү безне бер дә җәлеп итми.

“Моннан соң үз халкымызда бәгъзы мөгамма вә лөгазьләрне[1] бәян кылаек ки, телебездә җомак вә табышмак тәгъбир кылыныр[2]. Ләкин мәзкүр[3] җомак вә табышмак дигәнебез күбрәк ләгызь кабилендәдер[4]”,— дип белдерә К.Насыйри “Фәвакиһел-җөләса”да. Әдипнең “Сайланма әсәрләр”ен укучыларга тәкъдим итүчеләр “Фәвакиһел-җөләса”дагы бу бүлекчәне “Халык иҗаты әсәрләре” башы астында, “Табышмаклар” исеме белән атап, кайдан алынганлыклары күрсәтелмичә биргәннәр[5].

“Фәвакиһел-җөләса”да 27 табышмак китерелә, алардан соң “Шигырьләр” дигән бүлек башлана. Фольклорчы галим Х.Мәхмүтов: “Шигырь дип К.Насыйри җырларны атый”[6],— дигән искәртү ясый.

К.Насыйри төп игътибарын халык җырларының төзелеш үзенчәлекләренә юнәлтеп кенә калмый, аларның эчтәлеген ачыклауны да максат итеп куя һәм бу хакта болай дип белдерә:

---

[1] Мөгамма вә лөгазьнәләрне — табышмак һәм тапкыр мәсьәләләрне.
[2] Тәгъбир кылыныр — гыйбарә ителер, мисалга китерелер.
[3] Мәзкүр — телгә алынган, бәян ителгән.
[4] Ләгызь кабилендәдер — табышмак мисалындадыр.
[5] Насыйри К. Сайланма әсәрләр: 4 томда.— Т.3.— Б.15–22.
[6] Шунда ук.— Б.53 (текст асты искәрмәләре өлешендә).

“Мәгълүм ки, логатемезнең [1] шигырьләре һәркайчан ике мисраглы [2] булып, күбрәк шигырьләрдә соңгы мисраг максудны ифадә кыладыр[3]. Вә янә телемезнең хавасыннандыр[4] ки, бер шигырьне 10–15 төрле итеп тәрәннем кылмак[5] мөмкин. Бу хасият башка телләрдә ишетелмидер. Вә дәхи шигырьләремез фирак вә һиҗран [6] вә мәдех [7] вә иштиякы-васләт[8] вә үпкә бәянында тәрәннем кылынадыр”. “Фәвакиһел-җөләса”дан бу бүлек К.Насыйриның “Сайланма әсәрләре”нең өченче томы “Җырлар” бүлекчәсендә кайдан алынганлыклары күрсәтелмичә генә бирелгәннәр[9].

“Фәвакиһел-җөләса”дагы 116 җырның барысы да диярлек сөю-сәгадәт турында. Шунысы әһәмиятле, К.Насыйри кайбер җырларга үзенең шәрех-аңлатмаларын да бирүне кирәк тапкан, аларның шуклык белән иҗат ителүләрен дә сиздерми калмаган. Бу аның җыр тематикасын шактый яхшы аңлап һәм укучыларына эчтәлекләрен төшендерергә теләп эш итүеннән килә. Мәсәлән:

Кашларың нечкә бик әйләнгән,
Казанда бөккән дугадай,
Йөзең күркәм, буең зифа —
Банкаларда үскән кынадай,—

дигән җырга ул мондый аңлатма бирә һәм: “Бу мәзкүр [10] шигырьдә мәхбүбләрнең [11] кашын дугага тәшбиһе [12] мөнәсәбәтсезрәк күренсә дә, җырның йыртыгы юк дигән көллияне[13] игътибарга алсак, мәгъфүдер[14]”,— дип белдерә[1].

---

[1] Логатемезнең — телебезнең.
[2] Мисраглы — строфалы.
[3] Ифадә кыладыр — белдерәдер.
[4] Хавасыннандыр — үзенчәлегеннәндер.
[5] Тәрәннем кылмак — көйләмәк, җырламак.
[6] Фирак вә һиҗран — аерылу һәм китү.
[7] Мәдех — мактау.
[8] Иштыякы-вәслат— кавышу теләгендә сагышлану.
[9] Насыйри К. Сайланма әсәрләр: 4 томда.— Т.3.— Б.53–84.
[10] Мәзкүр — телгә алынган, искәртелгән.
[11] Мәхбүбләрнең — гашыйкларның.
[12] Тәшбиһе — охшатуы.
[13] Көллияне — әйтемне, сүзне.
[14] Мәгъфүдер — гафу ителерлектер.

Җырлардан соң, инде искәрткәнебезчә, “Чәй бәете” һәм “Уңмаган килен бәете” китерелә һәм К.Насыйри аларның шигъри яктан төгәл һәм дөрес төзелештә булуларын мактый, эчтәлекләренә игътибар итә, вәзен үлчәмнәрен билгели. Алардан соң мәкаль һәм әйтемнәргә күчә.

“Каюм Насыйри,— дип яза Х.Ярми,— халык авыз иҗатының мәкальләр өлешеннән бик нык файдалануы һәм аңа аерата бер мәхәббәт белән каравы билгеле”[2]. “Фәвакиһел-җөләса”да да мәкаль һәм әйтемнәргә ул шактый зур урын бирә.

Мәкаль һәм әйтемнәр хакында К.Насыйри боларны яза: “Мәгълүм ула ки, һәр телнең үзенә махсус әмсаль вә мәкальләре, вә көллияләре буладыр. Халкына күрә гакыл ияләре вә хәкимнәре дәхи бардыр”[3]. К.Насыйри әйтемнәрне монда көллияләр дип атый, әмсаль дигәнендә хайваннар һәм киек-җанварларга карата әйтелеп тә, асылда кешегә нисбәтле мәкальләрне күздә тота. Аның бу рәвешле мәкаль һәм әйтемнәрне өч төрлегә бүлүе кызыклы күренеш һәм хәзерге фольклористика гыйлемендә әлегә файдаланылмый. Әгәр дә бүгенге фәнебезгә “әмсаль” термины кире кайтарылса, бу хәл табигый буларак аңлашылыр иде.

“Фәвакиһел-җөләса”ның 583 нче сәхифәсеннән башлап К.Насыйри 310 мәкаль һәм әйтем, әмсальләрне китерә. Сайланма әсәрләренең 3 нче томында ул 22–43 битләргә урнаштырылган. Әмма анда да мәкаль, әйтем һәм әмсальләр аерымланып урнаштырылмаганнар. Тагын да шунысы әһәмиятле, К.Насыйри бу материалларның эчтәлегенә аерым игътибар итә, аларны аңлатып, укучыларына төшендереп бирә, кайбер урыннарда гарәп яки фарсы фольклорыннан мәгънәдәшләрен китерә. Шуңа да аны без шактый олы хезмәт дип атарга батырчылык итәбез.

---

[1] Насыйри К. Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият.— Казан: Университет табигъханәсе, 1884.— Б.548.

[2] Ярми Х. Татар фольклорын җыйнау һәм аны бастырып чыгару өлкәсендә Каюм Насыйриның эшчәнлеге // Каюм Насыйри: 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары).— Б.102.

[3] Насыйри К. Сайланма әсәрләр: 4 томда.— Т.3.— Б.22.

Х.Ярми К.Насыйриның фольклористика белән даими шөгыльләнүенең төп сәбәпләрен аның татар әдәби телебезне баету өлкәсендәге эшчәнлеге дип бәяли[1]. Димәк, К.Насыйри казан татарлары сөйләшен әдәби телебез буларак туктаусыз пропагандалау эшен дә башкарган, шунлыктан әдәби тел җәһәтендә "каюмчылык" юнәлеше барлыкка килгән. Бер яктан, татар әдәби теленең язма һәм сөйләм нормаларын грамматик нигездә тикшерүе һәм гамәлгә куюы, икенче яктан, шушы әдәби телне халык иҗаты материаллары һәм язма мирас ярдәмендә (ул бу җәһәттән Г.Кандалый иҗатын аерып алып өлге итә) туктаусыз нығытуы, үзенең дә шул нигездә әдәби иҗат һәм фәнни хезмәтләр язу эшләре белән шөгыльләнүе К.Насыйриның карашлары җитлеккән, максатчан галим булуы хакында сөйлиләр. Бу гына да түгел, ул әле татар фольклоры җәүһәрләрен башка халыкларга җиткерү белән дә кызыксына.

1880 нче елда чыккан "Записи Императорского географического общества" тупланмасының VI томында ул рус телендә "Поверья и обряды казанских татар" мәкаләсен бастырып чыгара. Бу язмасын Х.Ярми "Казан татарлары мифологиясен өйрәнүдә беренче фәнни хезмәт"[2] дип атый.

Аның белән килешми мөмкин түгел. Ул мәкаләдә халкыбызның Ислам динен кабул иткәнчегә кадәрге булган карашлары, мифик затларга ышанулары һәм шулар белән бәйле гореф-гадәт һәм йолалары махсус тикшерелә.

К.Насыйриның хезмәтләре асылда XIX гасырга карасалар да, алар бүген дә актуальлекләрен югалтмаганнар, төрле фәннәр үсешендә зур әһәмияткә ия булып торалар. Без аның бары тик татар фольклористика фәнен барлыкка китерүендә һәм үсешендә керткән өлешенең кайбер якларын гына карап үттек, бу гыйльми өлкә белән кызыксына башлавының төп сәбәбен ачыкладык. Ә менә Ислам мәдәнияте кысаларында үсеш алган башка халыкларның иҗатларына бәйле язмаларын, аларны да фәнни нигездә өйрәнүләрен читкә куеп тордык.

---

[1] Ярми Х. Татар фольклорын җыйнау һәм аны бастырып чыгару өлкәсендә Каюм Насыйриның эшчәнлеге // Каюм Насыйри: 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары).— Б.102.

[2] Шунда ук.— Б.103.

Шунысын онытмыйк: К.Насыйри татар халкы үсешендә Ислам мәдәниятенең шактый әһәмиятле роль уйнаганлыгын ачык күзаллап эш иткән, татар халык иҗатын Ислам мәдәниятеннән аерылгысыз дип санаган. Моны аның “Фәвакиһел-җөләса” хезмәте кебек үк башкалары да раслап торалар. Татар халкының рухи дөньясы шушындый катлаулы мәдәни кысаларда формалашкан һәм үсеш алган, без моны бүгенге көндә дә инкарь итә алмыйбыз.

К.Насыйриның татар фольклористика гыйлемен үстерүдә төп эшчәнлеге, беренчедән, милли әдәби татар телебезне гамәлгә кую белән бәйле булса, икенчедән, халык авыз иҗатын өйрәнү аша аны пропагандалаудан, халкыбызның дөньяга карашын киңәйтергә омтылышыннан гыйбарәт. Фольклорны җыйнау гына да гаять зур хезмәт сорый. Ул аларны анализлаган, фәнни нигездә эшкәрткән, бастырып чыгарган, бу гына да түгел, татар халык авыз иҗатын беренче булып системага салган, татар фольклористикасын гыйльми нигездә үстереп җибәргән галимебез дә. Без аны татар фольклористика гыйлемен европача җәдиди нигездә үстереп җибәргән беренче зур галимебез дип атыйбыз һәм монда бернинди арттыру юк икәнен дә беләбез.

2

К.Насыйри Казан Император университеты каршындагы “Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте”нең төп галимнәреннән берсе булган. Җитмәсә аңа акчалата да ярдәм итеп торган. Монысы тагын да гаҗәп. К.Насыйри галим һәм язучы гына түгел, сәүдәгәр, ягъни, үз чорының термины белән искәрсәк, “гельдий купец” дәрәҗәсен дә йөрткән. Мондый кеше галимнәргә ничек инде матди ярдәмен күрсәтми калдырсын? Тик шунысы бар, К.Насыйрины бездә фәкыйрь булган, авыр яшәгән, фатирда гына торган, подвал бүлмәдә гомер сөргән кебек һәм башка шундый хәбәрләргә ияртеп искә алырга маһирлар. Ул да үз тормышында төрле авырлыклар аша узгандыр, бәхәс итмибез. Әмма аның дәрәҗәле, товар-акча әйләнешендә йөргән шактый гына сумма акчасы да

булган сәүдәгәрлек таныклыгын өнәмәвебез дә бер көлке күренеш түгелме?

“Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте”нең 1896 нчы елгы “Известия” альманахының XIII томында К.Насыйриның рус телендә “Казан татарларының халык әдәбияты үрнәкләре” (“Образцы народной литературы Казанских татар”) дигән зур һәм җитди фәнни хезмәте басылып чыга, ул анда табышмак, мәкаль һәм әйтемнәр белән бергә халык җырларының үрнәкләрен дә татар һәм рус телләрендә урнаштыра. Профессор Н.Ф.Катанов аның татар фольклористикасы өлкәсендәге казанышларына аерым басым ясап, шушы мәкаләгә сүз башы буларак язган бәяләмәсендә болай дип белдерә: “Бу көнгә хәтле Казан татарларының халык иҗаты памятникларын җыйнаучылардан берәү дә бу хәтле күп җырлар һәм мәкальләр тапшырганы юк иде. Насыйров әфәнде тарафыннан тапшырылган материаллар, бөтен гомерен үз халкы арасында үткәреп, аны төрле яктан өйрәнүе аркасында, аның үз халкының тормышы һәм теле белән яхшы таныш икәнлеген бик ачык күрсәтә. Безнең җыйнаучыбыз тарафыннан китерелгән табышмаклар, аның халкының искиткеч акыллы икәнлеген исбат итәләр... Барлык бу җырлардан, мондагы татар халкының үзләренең шатлык һәм кайгыларын тасвирлы һәм җиңел итеп сурәтләүләрен күреп була” (Х.Ярми тәрҗемәсе)[1]. К.Насыйри татар халык җырларын “Кырык бакча” китабындагыча бүлекләргә бүлеп, тематик яктан аларны классификацияләп һәм тәртипкә салып укучыларына тәкъдим итә. Аның “Сказки казанских татар и сопостовление их со сказками других народов” дигән хезмәте дә шушы ук җәмгыятьнең “Известия” тупланмасында 1900 нче елда басылып чыга (XVI том). Монда барлыгы 11 әкият китерелә. К.Насыйри аларны гарәп графикасында әзерли, профессор Н.Ф.Катанов аларга академик транскрипция ясый, академик П.А.Поляков исә аларга башка халыкларның

[1] Ярми Х. Татар фольклорын җыйнау һәм аны бастырып чыгару өлкәсендә Каюм Насыйриның эшчәнлеге // Каюм Насыйри: 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары).— Б.103.

экиятләре белән чагыштырма анализ уздыра[1]. “Каюм Насыйри бу әсәрендә,— дип яза Х.Ярми,— татар халкының тормышын, аның үз тирә-юнендә, үзен әйләндереп алган табигый көчләргә булган карашын ачык чагылдырган реалистик экиятләрне сайлап биргән”[2].

Монда бирелгән экиятләрнең табигый рәвештә башка халыкларның да иҗатлары белән уртак яңгырашка ия булулары ачыкланыла. Бу факт исә татар халкының мәдәният ягыннан бер дә башкалардан калышмавын, рус халкы белән дә бер дәрәҗәдә икәнлеген галимнәргә төшенергә ярдәм итә.

Шушы җәмгыять “Известия”сенең XII томында 1894 нче елда хәрби офицер В.А.Мошковның (ә рус офицерлары арасында фән белән шөгыльләнү, традиция буларак, XVIII йөздән үстерелеп киленә) “Материалы для характеристики музыкального творчества инородцев Волжско-Камского края.— Мелодии Оренбургских и Ногайских татар. Введение” хезмәте 1–67 нче сәхифәләрдә урнаштырыла. Ул шушы материалларны Варшава хәрби округында хезмәт итүче татар солдатларыннан җыя [3]. Хезмәтнең башлангыч 20 бите сүзлекчәдән гыйбарәт. Тел тарихын өйрәнүчеләр өчен кызыклы материаллар арым төркемнәргә төркемләп бирелгәннәр. Мәсәлән, анда мондый кызыклы материал бирелгән: “Козалык җир” — козалык үзе арба дигән сүз; козалык җир — борынгы үлчәү берәмлеге; арбаның ике тәгәрмәче арасындагы тар һәм 100 атлам озынлыгындагы (30 сажин) җир бүлеме. 15–20 шундый кишәрлек пай була. Бер пай — бер гаиләгә бүлеп бирелә. Тамга — шушы пай җирләренә куелган билге”[4] ***(алынма безнең тәрҗемәдә)***.

---

[1] *Бу хакта киңрәк мәгълүматны карагыз:* Ярми Х. Ярми Х. Татар фольклорын җыйнау һәм аны бастырып чыгару өлкәсендә Каюм Насыйриның эшчәнлеге // Каюм Насыйри: 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары).— Б.104.

[2] Шунда ук.

[3] *Карагыз:* Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском казанском университете.— Т.XII.— Вып. 1.— Казань: Типо-литография Императорского университета, 1894.— С.1.

[4] Шунда ук.— Б.19.

Мондый кызыклы хәбәрләр һәм аңлатмалар тарихи яктан да әһәмиятле һәм татар халкының җир бүлешү системасын дөрес аңларга безгә ярдәм итәләр. Тагын да шунысын искәрик: Алтын Урдада монгол хөкемдарлары тарафыннан кертелгән тамга (урда = хәзер без аны “орды” дибез, ягъни “мөһер орды”) системасы татарда XIX йөздә дә яшәгән икәнлеге тарихлардан хәбәрдар кешегә аңлашылып тора. Алтынчы бүлекчәдә В.А.Мошков “Верования” (“Ышанулар”) белән бәйле материалларны туплый. Халык авыз иҗатында татарлар Җирне табак кебек дип күзаллауларын яза, аны Күк Үгезе мөгезендә тотып тора икән, ә ул Үгез Балык өстендә тора, ә Балык Диңгездә йөзеп йөри [1], имеш. Бу, әлбәттә, Ислам динендә кабул ителгән Җир шары хакындагы мифка туры килә.

Беренче кеше Җирдә Исуп (Йосыф) пәйгамбәр булган икән (“... Первый человек назывался Исуп Пайһамбар” [2]). Ул баштарак ялгызы яши, аннары картая. Аллаһы тәгаләдән бирелгән хатынын очрата — Залека, ул да ялгыз яши.

Кыш көнне алар юллары туры килеп очрашалар. Бер-берсен күреп исләре китә.

Исуп сорый: “Син кайдан киләсең? Моңа кадәр җир йөзендә бер генә кешене дә күрмәгән идем”.

Залека да моңа кадәр һичбер кешене күрмәгән булуын сөйли, әмма очратачагы төшенә кергәнлеге хакында сөйли. Исуп аңарга тәкъдим ясый һәм аны өенә алып кайта.

Икенче көнне Исуп уяна һәм бер төш күрүен Залекага сөйли. “Мне, говорит он, явился во сне Джибраһил Гиссалям и сказал, что нам так жить нельзя, что мы должны обвенчаться”[3].

Залека да төшендә шушыны ук күргән икән. Исуп Пайһамбар кулына китап ала, үзен үзе никахлый, чөнки әлегә бүтән кешеләр булмый. Шулай алар яшиләр һәм беренче балалары Исаф Пайһамбар туа.

---

[1] Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском казанском университете.— Т.XII.— Вып. 1.— С. 21.

[2] Шунда ук.

[3] Шунда ук.— Б.21–22.

Әүвәле алар җәннәттә, матур бакчада яшиләр. Бернәрсә дә ашамыйлар. Аннары Ходай аларга җимеш — “курма” бирә, кечкенә һәм тәмле, баллы. Тәүлеккә берне генә ашыйлар, “йомышка да йөрмиләр”. Соңрак алар комсызланалар, күбрәк ашый башлыйлар. Шуның өчен “йомышка да йөрү” ихтыяҗы туа. “В раю, где они жили, были все хорошие запахи, а тут пошел дух нехороший и Бог вывел их из рая”[1].

В.А.Мошков бу риваятьне хәрби хезмәттәге әстерхан татарларыннан язып алган. Аларның ышанулары буенча Җирдәге беренче кешеләр шушы Исуп һәм Залека, ягъни Йосыф белән Зөләйха булганнар.

Бу факт аерым тарихи-мәдәни әһәмияткә ия. Мотивлары белән ул рәсми дини риваятьләргә дә берникадәр якын, Адәм белән Хәува турында да кебек, әмма хәбәр ителгән вакыйгалар аларныкыннан шактый нык аерылып та торалар. Шунысы да бар: берничә дини риваятьнең бергә кушылуы аркасында барлыкка килгән дип нәтиҗә чыгарырга һич мөмкин түгел. Әмма В.А.Мошков язып алган ул риваять бу факт шактый кызыклы һәм Ислам диненә кадәр үк дини ышануларга бәйле түгелме дигән фикергә дә китерә.

Шушы ук вакыйгаларны Оренбург татарлары башкачарак сөйлиләр икәнлегенә тукталып, хезмәтендә В.А.Мошков, махсус игътибар юнәлтеп, Исуп белән Залеканы Шайтан котыртканлыгына ышануларын искәртә, (“уговорил их съесть пшеницу”) бодай җимешен ашарга күндерүен әйтә[2]. Мондагы бодай//богъдай җимеше исә Ислам динендә рәсми кабул ителгән версиягә туры килә, әмма Адәм белән Хәува урынына Йосыф белән Зөләйха булуы факты мәсьәләне катлауландыра. Солдатка аңгы-миңге егетләрне алмаганнар, билгеле. Алар хаталы сөйләмәгәннәр. Мәгәр шулай икән, димәк, халык ышанулары төрле төбәкләрдә төрлечәрәк булган. Оренбург татарлары сөйләгәннәр “Пәйгамбәрләр тарихы”нда тасвир ителгән вакыйгаларга, ягъни Ислам диненең канунлаштырган риваятьләренә турырак килә. Бу фактлар татар халкында

---

[1] Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском казанском университете.— Т.XII.— Вып. 1.— С.22.

[2] Шунда ук.

Йосыф-Зөләйха белән бәйле сюжетларның актив кулланылышта йөрүләре һәм хәтта рәсми дини риваятьләрне алыштырулары хакында да сөйлиләр.

Краснодарски нугайларында, В.А.Мошковның аңлатуынча, беренче кешеләр татар телендә сөйләшкәннәр, аларны бу телгә Җәбраил фәрештә өйрәткән. Шулай ук шушы Җәбраил фәрештә, Аллаһы тәгалә кешеләрне бар кылгач, аларга, шәрә йөрмәсеннәр өчен, шунда ук киемнәр кидергән [1]. Болары милли үзаңның татарда ул заманнарда шактый көчле булуы хакында сөйли торган фактлардан.

В.А.Мошков бу риваятьләрне һәм мифларны турыдан-туры татар халкының ырым һәм ышануларына китереп бәйли. Дөрес, алар арасында Ислам дине тәгълиматы тарафыннан тәмам ныгытылган мифларның кайбер элементларын да очратырга була, әмма ул уртак мотивлар һәм яңгырашлар борынгы татар ышанулары белән турыдан-туры бәйле булырга да мөмкиннәр.

В.А.Мошков язып алган кыргый хайваннарның килеп чыгышы хакындагы татар мифы да фәнни яктан кызыклы.

Борын заманда бер бай була, ул бик тә саран икән. Аның хайваннары, мал-туары шактый күп, ди. Әмма ул аларны корбан итеп чалмаган, ярлыларга алардан өлеш чыгармаган.

Бервакыт бара икән бу, җир ярылып, тездән шунда чумган. Ходай килеп, аңардан: “Ярлыларга моннан ары корбан чалырсыңмы?”— дип сораган, ул: “Әйе!”— дип җавап биргән. Шунда ук бәладән котылган. Әмма биргән сүзендә тормаган.

Мондый хәл өч тапкыр кабатланган. Икенчесендә бу саран бай, җир ярылып, шунда биленнән чумган, өченчесендә муенына кадәр һәм дә ахырда бөтенләй җир тишегенә олаккан. Аннан инде чыга алмаган.

Шунысы әһәмиятле, өч тапкыр кабатлану вакыйгасында без дүртенче очракка да тап булабыз. Димәк, татарлар Аллаһы тәгаләне өч тапкыр сыный, дүртенчесендә хөкем итә дип белгәннәр. Безнең халыктагы борынгы нумерологиядә менә ни

---

[1] Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском казанском университете.— Т.XII.— Вып. 1.— С.22.

өчен “дүртле” үлем саны буларак аңлатыла икән! В.А.Мошков моңа игътибар итмәгән.

Бу саран бай җир астында калдырылгач, аның мал-туарлары берәм-берәм таралышып бетәләр һәм кыргыйлашалар. Кайсылары бүрегә, төлкегә, куянга һәм башка хайваннарга әвереләләр. Әүвәле бу хайваннарның теле булмаган, аннары соң Ходай аларның берләренә сөйләргә ярый, икенчеләренә юк дип, тиешле санаганнарына тел биргән[1].

Бу миф гыйбрәтле һәм тәрбияви әһәмияткә ия. Карун бай турындагы риваятьләрне дә бераз хәтерләтә, әмма аны һич тә кабатламый.

Шушы риваятьләрдә борынгы татар халкы ышануларының мифологик-хорафи катламы чалымнарын шактый таба алабыз. Ислам дине үзенеке дип таныган риваятьләрнең татарлар арасында активлашуында халык иҗаты белән аваздаш мотивлары булудан икәнлеге дә аңлашыла башлый. Халыкның борынгы заманнардан яшәп килгән ышанулары һәм мифлары белән аваздашлык һәм уртаклыклары сәбәбеннән Ислам дине татарда утсыз-кылычсыз таралыш алган. Моны башкача итеп турыдан-туры раслап булмый, әмма бу фәнни гипотезаны уздырмыйча да мөмкин түгел, фактлар күбәйгән саен ныклы күзаллау да тумыйча калмый.

Шундый ук мифларның берсе Ходайның җан ияләренә ризык бүлүе хакында. Ходай, хайваннарга мөрәҗәгать итеп: “Кем кайсы ризыкны ашыйсы килә?”— дип сораган. Ат шунда кеше ризыгы саналган итне, икмәкне һәм башкаларны ашарга теләге барлыгын белдергән. Аның белән Ходай да килешергә әзер икән, әмма Исуп Пәйһамбәр (В.А.Мошков аның Оренбург татарларында һәм нугайларда шушылай сөйләнелгәнлеген ассызыклый) яки аның улы Исаф Пәйһамбәр (монысын В.А.Мошков Краснодарски нугайларына нисбәтли) үтенгәч, ит һәм икмәк кешеләргә калдырылган, ә атларга — үлән.

Елан шунда кеше канын эчәргә теләге барлыгын белдергән. Хәбәрендә вакыйгасы болай була:

---

[1] Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском казанском университете.— Т.XII.— Вып. 1.— С.22-23.

Ходай кешеләрнең гөнаһы өчен Җирне суга батыра. Идел ташып чыга. Исуп Пәйһамбәрдән ары башкалар батып үләләр. Ул зур көймәдә исән кала. Аның көймәсе бер тау яныннан үтеп барганда, берничә кеше аңардан үзләрен коткаруын үтенәләр. Ул, аларны кызганып, үз янына ала. Ходай моңа ачулана һәм тычканнарга көймә төбен тишәргә куша. Тишектән су кереп, көймә бата башлый. Исуп һәммәсен көймәне төзәтергә чакыра. Әмма файдасыз. Шунда елан килә. "Әгәр дә миңарга кеше канын эчәргә Ходайдан рөхсәт алып бирсәң, мин ярдәм итәм!"— дип белдерә. Тормышы өчен куркынган Исуп Пәйһамбәр риза була. Елан үз койрыгы белән көймәнең тишеген каплый.

Болардан аңлашылганча, бу хәбәрләр Нух пәйгамбәр вакыйгаларын искә төшерәләр. Әмма Ислам динендә канунлаштырылган риваятькә Исуп Пәйһамбәр вакыйгалары туры килми, Идел елгасы хакында сүз бару да хәбәрнең татар акылы белән уйлап чыгарылуы хакында сөйли. Тау яныннан узып барганда көймәгә кешеләрне утыртуы да кызыклы һәм, гомумән, мондый тәфсилле вакыйгалар халык уйдырмалары булып торалар әлбәттә. Дөрес, авыз иҗатына нигезләнеп язылган хикәятләрне искә алсак, башка хәл. Аларда без әллә нинди гайре табигый һәм табигый, хикмәтле вакыйгаларга тап булырга мөмкинбез. Аннары Җирне су басуны татар халык авыз иҗатында, күргәнебезчә, беренче кеше дип күзалланган Исуп Пәйһамбәргә нисбәт иткәннәр. Бу фактлар фән өчен аерым игътибарга лаек.

Еланга рөхсәт бирер алдыннан Ходай, В.А.Мошков язып алган татар риваяте буенча, кеше канын эчеп карарга дип, шунда черкине җибәрә. Татлымы икәнен белергә. Черки очып бара, туйганчы кеше канын эчә, кире кайтканында аңарга карлыгач очрый. Ул: "Татлымы?"— дип сорый. Черки: "Аннан да тәмлесе юк",— ди. Карлыгач әйтә: "Әйдә, телеңне күрсәт!"— ди. Черки күрсәтә. Карлыгач шунда аның телен тешләп өзә.

Черки шулай Ходай каршына килә. Әмма соравына җавап бирә алмый, безелдәп тик тора. Ходa белми кала, еланга бака канын эчәргә боера. Елан, ачуы килеп, карлыгачны

койрыгыннан элəктереп ала, шуннан аның койрыгы өчпочмаклы булып бүленеп кала[1].

Моңа охшашлы хикəят 2004 нче елда Татарстан китап нəшриятында дөнья күргəн “Гыйбрəтле хикəятлəр” китабында “Ни өчен карлыгачның койрыгы икегə аерылган?” дигəн исем астында китерелə, əмма аның кайдан алынганлыгы искəртелми[2].

Детальлəргə игътибар итеп, аларны чагыштырганда, шуңа тап булабыз: “Ни өчен карлыгачның койрыгы икегə аерылган?” хикəятендəге елан кеше канын түгел, бəлки итен ашарга рөхсəт ителүен телəп Нух пəйгамбəрдəн сорый. Аннары еланнар да бер генə булмыйлар. Шулай ук черки урынына соры чебен, Ходай урынына да, Исуп Пəйһамбəр урынына да Нух пəйгамбəр куела. Əмма Карлыгач койрыгының икегə аерылуы белəн өчпочмаклы булып калуы мотивларында охшашлык бар. Бу гыйбрəтле хикəят шактый əдəбилəштерелгəн һəм В.А.Мошков китергəн халык риваятеннəн детальле һəм сурəтле булуы белəн бик нык аерылып тора. Бу фактлар исə халык əсəренең бер-бер укымышлы шəкерт тарафыннан хикəят итеп язып алынган, эшкəртелгəн булуын фараз кылуга этəрə.

Элеклəрне, димəк, татар халкында беренче кешелəрне Адəм белəн Хəува дип түгел, Исуп Пəйһамбəр һəм Залека дип күзаллау да яшəгəн, аларның улы Исаф Пəйһамбəр хакында да хəбəрлəр сакланган. “Пəйһамбəр”нең “пəйгамбəр” икəнлеген төшенүе авыр түгел, аннары җəннəт, Җəбраил фəрештə, туфан-су басу вакыйгасы — болар барысы да Ислам динендəге канунлаштырылган риваятьлəргə нисбəтлəре барлыгын дəлил итүче фактлар булып торалар. Ə менə ни өчен аларда зур аермалар бар — болары фəндə яңа бер эзлəнүлəргə һəм ачышларга таба юл ача. Исупның Йосыф пəйгамбəр, Залеканың Зөлəйха икəнлеген искəрттек. Моны Болгар чоры шагыйре Кол Галинең “Кыйссаи-Йосыф” əсəреннəн халык

---

[1] Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском казанском университете.— Т.XII.— Вып. 1.— С.23–24

[2] *Карагыз:* Гыйбрəтле хикəятлəр / Кульязмаларны басмага əзерлəүче, хəзерге əдəби телгə күчерүче һəм рəссам-бизəүче — Нəҗип Нəккаш-Исмəгыйль.— Казан: Татар. кит. нəшр., 2004.— Б. 135–136.

күңелендә уелып калган эздер бу дип әйтергә була. Әмма Исафы кем? Анысы — Нух пәйгамбәрнең улы Яфәс (төрле китапларда Яфес, яки Яфәз, яисә Яфет исемнәре белән искә алына), монда шик була алмый. Берничә дини риваятьнең бергә укмашуы кызыклы. Бу күренеш акыл күчешеннән түгел, бәлки тарихи аңның яшәү рәвешеннән килә. Ерак хәбәрләр белән якын вакыйгалар, үзара охшашлыклары була калса, халык күңелендә кушылып китүчән. Монда да шундый метаморфозалар күзәтелә. В.А.Мошков теркәп алган бу миф һәм риваятьләр, шулай итеп, татар халкының борынгы заманнарын аңлау-аңлату өчен дә шактый зур фәнни әһәмияткә ия булып чыгалар. Бер яктан Адәм белән Хәувага бәйле риваятьләр, икенче яктан Нух пәйгамбәр вакыйгалары халкыбыз иҗатында Йосыф белән Зөләйханыкы (Исуп һәм Залека) булып киткән, Нух пәйгамбәр улы Яфәз пәйгамбәр дә аларның улы итеп аңлатылган. Ә өченче яктан монда Йосыф һәм Зөләйханың үз тарихлары да катнаша. Бу өч катламның бергә тупланы һәм бер үк яссылыкта яшәве татар акылының һәм аңының шактый катлаулы булуын гына түгел, аның борынгыдан үз дини күзаллаулары яшәгәнлеген дә күрсәтә. Дөрес, мондый риваятьләр халкыбыз тарафыннан тарихи үсеш дәверендә дә тудырылган булырга мөмкиннәр. Ул вакытта без мондый әсәрләрнең җаһилияткә төшкән заманнарда барлыкка килүләрен искәрергә тиешбез. Әмма ул XIX йөз (коммунистик уку-тәрбия еллары XX гасыр түгел инде) бер дә андый чор сыйфатында хәтергә килми. Шушы мантыйгыбыз дөрес һәм хакыйкый икән, димәк, фикерләмәләребездән бары тик берсе, ягъни борынгы заманнардан татарлар беренче кешеләрне шулай Йосыф-Зөләйха дип күз алдына китергәннәр дигән фаразыбыз гына урынлы булып кала.

В.А.Мошковның хезмәтендә табигать күренешләренә бәйле ырым һәм ышануларның да теркәлеп калынуы кызыклы. Аның язмасыннан аңлашылганча, борынгыдан Оренбург нугайларында Кояш һәм Айның бердәй, игезәкләр сыман итеп яратылулары хакында хәбәрләр йөргән. Аларны бер-берсеннән аерып та булмаган. Шуннан Ходай, фәрештәләр җибәреп,

Айның яктылыгының бераз өлешен кырып алырга һәм Кояшка кушарга боерган. Шуннан соң Кояш яктырак яна башлаган.

Краснодарски нугайларында Ай-Кояшка бәйле риваятьләр тагын да кызыклырак итеп сөйләнелә: болар икесе дә буш куык-шар икәннәр. Аларның эчендә игезәк корткалар утыралар. Кояшта — Җилмәвез кортка, Айда — шундый ук исемдәге Җилмәвез әби. Димәк, исемнәре дә бер үк төрле. Аларның берсе көндез, икенчесе төнлә Җир йөзен күзәтәләр. Кояш, Ай баткан төннәрдә бу әбиләр, Ходайга килеп, ниләр күргәнлекләрен сөйлиләр. Кояш һәм Айның тотылулары сәбәбе дә Җир йөзендә күп төрле явызлыклар булудан икән[1].

"Җилмәвез" дигән сүзнең асыл мәгънәсе "фәрештә" түгелме икән дигән сорау да күңелдә туа.

Бу риваятьнең тәрбияви функциясе шактый көчле. Аның килеп чыгышы борынгы ырым-ышануларга барып тоташканы аңлашылып тора. Ходай сүзе урынына Тәңре атамасы кулланылса, без андый нәтиҗәне хәтта хакыйкать буларак та танырга өлгерер идек. Гомумән дә, В.А.Мошковның хезмәтен укыганда безнең күңелдә Краснодарски нугайларында (татарлары хакында сүз барганлыгы аңлашыла) борынгы ырым һәм ышанулар белән бәйле халык авыз иҗаты әсәрләренең шактый әһәмиятле катламы сакланып калган дигән тойгы уяна.

Татарлар һәркемнең үз бәхет йолдызы барлыкка ышанганнар, кеше үлсә, йолдызы да егылып төшә дип исәпләгәннәр[2]. Димәк, күктә йолдыз атылуны алар кеше үлеме, кайгы килү буларак күзаллаганнар, хәзергечә бәхеткә юрамаганнар.

"Киек каз юлы" йолдызлар тезмәсен Краснодарски нугайлары "Кавы җула" дип, Оренбург татарлары "Кәгъбә юлы" исеме белән йөрткәннәр[3]. "Кәгъбә юлы" дигәненең мәгънәсе аңлашылып тора. Сүзнең хаҗга бару юлы белән, ул йолдызлар тезмәсенең кыйблага таба юнәлеш тотуга бәйле

---

[1] Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском казанском университете.— Т.XII.— Вып. 1.— С.24.

[2] Шунда ук.

[3] Шунда ук.

аталуыннан икәнлеген инкарь итү урынсыз. Халкыбыз яшәгән җирләрдән Мәккә шәһәре Көньяк тарафта, Идел елгасы аккан юнәлештәрәк урнашкан. Бу йолдызлар тезмәсе дә нәкъ шул якка юлны күрсәтеп тора. Ә менә “Кавы җула” дигәнендә “Кави юлы” күздә тотылуын, ягъни “Куәт иясе Аллаһы тәгаләгә илтүче юл” икәнлеген дә белә алабыз. Рухларның Аллаһы каршысына ашу юлын фаразлап шулай аталганмы ул? Әллә халкыбыз борынгыда “Киек каз юлы”н дини-мистик аңлау-аңлатуларга төргәнме? Бәлки ул шул ук “хаҗилар юлы”, “Кәгъбә юлы” дигән сүздер?

Бу кызыклы фактка аңлатманы В.А.Мошков та эзләгән. Аны шул ук солдатларның үзләреннән тапкан. Аларның сөйләве буенча Кавы — дөньяда иң матур һәм рәхәт урын, анда бервакытта да кыш булмый. Кавыга кергәндә рәшәткәле капка бар икән, аны “Кавы капхасы” дип йөртәләр һәм ул гаҗәеп үзенчәлекләргә ия: әгәр дә аңа муллалар һәм изгеләр килсә, рәшәткәләре ачылалар, кешеләр имин рәвештә аннан узып китәләр, әгәр дә гөнаһ ияләре керергә тырышсалар, алар тараялар һәм болар шунда кысылып үләләр, ди. Шушы Кавыга барганда “Изге Караташ” бар, аны “Сынтас” дип йөртәләр. Гөнаһ иясе аңа якын килсә, бу таш сытып үтерә икән[1].

Бу бәян ителгәннәрне Ислам динендәге хәбәрләр белән тәңгәл китерсәк, “Кавы”ны “Каф тавы” дип тә кабул итәргә мөмкин. Шулай икән, димәк аның Кавказ тауларына бәйле булуы да бик мөмкин. “Кавы капхасы” да “Каф тавы капкасы”ның иске нугайча әйтелеше дип аңларга була. Әгәр дә Кавыны Кавказ тавы дип алсак, Кавказ тауларында андый капкада да барлыгы билгеле, аны “Дирбәнд капкасы” дип тә йөртәләр. Ислам диненә бәйле риваятьләрдә Зөлкарнәйн пәйгамбәр төзеткән дип аңлаталар. Хәзерге Коръән тәфсирләрендә Зөлкарнәйн пәйгамбәрнең тарихи шәхес буларак кем икәнлеге тәгаенләнеп атала. Ул — Мидия һәм Персия шаһы, ягъни ике илнең патшасы (төшендә ике кулына бер тәкәнең ике мөгезеннән тотучы итеп үзен күргән, шуңа бәйле аны Зөлкарнәйн, ягъни Ике мөгезле атап дип

---

[1] Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском казанском университете.— Т.XII.— Вып. 1.— Б.24–25.

йөрткәннәр; төшен ике илне берьюлы идарә итәрсең дип юраганнар, аларның берсе — фарсы иле, икенчесе — туран азербайҗаны икән) Дарий Беренче падишаһ[1].

Дарий I падишаһ безнең эрага кадәр 521–485 нче елларда хөкемдарлык иткән. “Еще более убедительным, однако, может служить свидетельство Британской энциклопедии: «Дербенд, или Дарбанд, город на Кавказе, находится в провинции Дагестан, на западном побережье Каспийского моря… Он занимает узкую полоску земли вдоль моря, поднимаясь вверх по крутым склонам гор… К югу находится южная оконечность Кавказской стены (протяженность 50 миль), иначе известной как стена Александра, она перегораживает узкий проход Железных, или Каспийских, ворот (Порте Албане или Порте Каспе)…» Неправильное название *Стена Александра* произошло, видимо, вследствие ошибки мусульманских историков, считавших, что Дху-л-карнайн — это Александр”[2].

“Кавы капхасы” шушы Дарий I падишаһ төзеткән Тимер капка яки Каспий капкасы, яисә Дирбәнд капкасы, я Кавказ капкасы һәм Каф тавы капкасы исемнәре белән төрлечә аталып йөртелә торган капка булып чыга түгелме? Мөгаен борынгы заманнарда татарлар шул капка аша узып хаҗга барганнардыр, В.А.Мошков теркәп калдырган халык риваяте безгә шул хакта да бәлки хәбәр итәдер? Чөнки ул шунда ук хаҗилар хакында телгә ала, аларның “аккып” дип аталуларына туктала. Сәбәп хаҗиларның намазга ак чалма киюләренә бәйле икән[3].

“Сынтас” һәм “Кавы капхасы” турындагы риваятьләр гөнаһлы кешеләрне хаҗга барудан тыяр өчен дә уйлап

---

[1] *Карагыз:* Священный Коран: Двуязычное издание / Автор перевода с арабского языка на английский, вступительные статьи и комментарии — *Маулана Мухаммад Али*; перевод на русский язык подготовил доктор *Александр Салецкий* (профессор университета Лаваля).— США: ЛАХОР ИНК.: Ахмадийа Анжуман Ишаат Ислам, 1997.— С. 601–602 (подстраничный комментарий №1517).

[2] Шунда ук.— Б.605 (бит асты төшермәсенең тәртип саны 1523).

[3] Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском казанском университете.— Т.XII.— Вып. 1.— С.25.

чыгарылган булырга мөмкиннәр. Әмма ул ташның изге Караташ икәнлеген дә ваклап кызыксынучан В.А.Мошковка солдатлар искәрткәннәр. Тик нигәдер аны үзләре дә Кавы юлындагы таш дип белгәннәр.

Әмма бу "Кавы капхасы" дигәне "җәннәт капкасы" буларак та аңлашыла, чөнки аның аша гөнаһлылар уза алмыйлар дигән хәбәр язмада ачык сөйләнелә. Шушы капкадан кергәннәрне алда бәхетле тормыш көтә, ул җирдә кыш булмый — бу хәбәрләр дә җәннәт тасвирына турыдан-туры бәйледер кебек.

Шулай да "Сынтас" һәм "Изге Карташ" дигәннәре мәсьәләне дөрес чишәргә ярдәм итәләр. Ул "Сынтас" — "сын ташы" дигән сүз. Андый таш Кәгъбәдә бар. Аны "Караташ" ("Хаҗәре-әсвад") дип тә әйтәләр. Бу хакта да В.А.Мошковны солдатлар искәрткәннәр. Ул таш чыннан да сын, ягъни мәҗүсиләрнең табына торган потларыннан берсе булган, метеорит, күк җисеме кисәге. Мөселманнарда изге таш санала. Пәйгамбәребезгә аны Кәгъбә ташы итәргә белдерелгән. Хәзер дә халкыбызда ул таш хакында, әгәр дә гөнаһлы кешеләр аңа якын килсәләр, сытып үтерә икән дигән урынлы-урынсыз сүзләр сөйләнелә.

Алга таба шул ук хезмәтендә В.А.Мошков, кызыклы риваятьләрдән берсе, җил турындагы мифик күзаллауны теркәгән. Краснодарски нугайлары җилне бер карчык һәм аның кызлары белән бәйләнештә сөйлиләр икән. Имеш, бер карчык бар, ди, аның да җиде кызы. Шуларның берсе аксак һәм усал, икән. Калган алты кызы аның белән бергә яшәргә теләмиләр, һаман да аңардан качалар. Качканда йөгерәләр һәм итәкләре белән җил чыгаралар. Качып өлгергәч, беразга хәл җыярга туктыйлар, шуңа күрә андый вакытларда җил дә исми тора, имеш[1].

В.А.Мошковның өермә белән бәйле язып алынган хәбәрләре дә кызыклы. Алары да әкияти планда бирелгән, мифик әсәрләр рәтенә керә.

Өермә белән тузан кубарыла, чөнки аның эчендә Шайтан утыра, имеш. Әгәр дә кешегә өермә килсә, тиеп китсә, яки аны

---

[1] Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском казанском университете.— Т.XII.— Вып. 1.— С.25.

эчендә калдырса — аңарга Шайтан сихере эләгә икән. Кешене хәтта акылдан яздыру көченә дә ия, ди. Аңардан котылу өчен, өермә күрсәң, дога укырга, өрергә һәм төкеренергә кирәк[1].

Болардан соң В.А.Мошков Шайтан һәм шайтаннар хакында халык ышануларын теркәгән. Татарларның белүләре буенча, шайтаннар күп икәннәр, аларның җитәкчеләре Иблис, ди.

Иблис әүвәле пәйгамбәр булган, җәннәттә яшәгән. Ходай аңарга кукуруздан башка барлык җимеш һәм җиләкләрне дә ашарга рөхсәт иткән. Ул аны беренче кешегә алдап ашаткан. Моның өчен Ходай Иблискә "яман камыт" кидергән, аны җәннәттән куган. Шуннан бирле Иблис Ходай белән ярыша башлаган, пәйгамбәрләрне һәм кешеләрне дөрес юлдан яздырырга тырыша икән.

Иблиснең ярдәмчесе — яман рухлы Даджал. Аны Иблис көн дә кешеләрне аздырырга җибәрә, үзара сугышсыннар, аракы эчсеннәр дип өйрәтергә куша. Хатыннары ирләренә хыянәт итсеннәр, ирләре — хатыннарына. Һәм шуның ише башка начар гамәлләргә кешеләрне шушы Даджал өйрәтә, имеш[2].

Ислам дине тәгълиматлары буенча караганда, монда китерелгән вакыйгалар ул өйрәтмәләргә туры да киләләр сыман. Әмма берникадәр аерымлыклар да бар. Мәсәлән, богдай//богъдай җимеше урынына "кукуруз кайаба" (ягъни кукуруз бодае — кукуруз чәкәне) хакында сүз бара, Иблиснең Аллаһы тәгалә белән ярышуы, Адәм һәм аның балаларына Даджалны җибәрүе кебек урыннары дини риваятьләргә тартымнар, әмма аерылып та торалар. Ходайга Иблисне каршы кую да борынгы, Ислам дине таратылганчы булган мәҗүси тәгълиматтан килә кебек. Дәҗҗалны дөрес итеп "Дәҗҗал" дип түгел, "Даджал" дип атап йөртү татар халкында хәзергәчә очрый, казан татарлары да аны "Дәджал" яки "Дәджан" дип әйткәлиләр, бигрәк тә шаян һәм шук балаларны шушы рәвешле атап ачулану гадәте аларда бүген дә сакланган.

---

[1] Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском казанском университете.— Т.XII.— Вып. 1.— С.25.

[2] Шунда ук. – Б.25–26.

В.А.Мошков Даджал (ягъни Дәҗҗал) хакында бер кызыклы риваятьне дә искәртә. Татар солдатларының сөйләгәннәренчә, ул Даджал бер ярлыга хезмәтче булып яллана һәм алар арыш үстерергә килешенәләр. Иген үскәч, Даджал аңардан бер тәпән аракы ясый һәм моны эшләү серен шул адәмгә өйрәтә. Ул менә шулай һәртөрле исерткечләр ясау серен кешеләргә белдереп йөри торгач, ахырда җир ярылып, шунда төшеп олаккан, артыннан кара төтеннәр генә чыгып калган. Бу хакта Иблис белеп алган, аны каршыларга музыка һәм биюләр белән бәйрәм оештырган. Шайтаннар бер ай буена олы туй ясаганнар[1].

Әстерхан татарларын да В.А.Мошков нугайлар дип атый һәм алардан да Дәҗҗал белән бәйле бер риваятьне язып ала. Анысы да Ислам динендә кабул ителгән мифик күзаллауларга берникадәр охшаш, әмма алардан аерылып та тора.

Көнбатышта, дөньяның иң читендә Гаф-таһа бар икән. Аның артында шайтаннар иле башлана. Шайтаннар арасыннан Татҗал (ягъни Дәҗҗал инде бу) дигәне яшь чагында ук кешеләрнең җирләрен яулап алмакчы була. Татҗалның әтисе аның бу ниятенә каршы чыга. Татҗалның моңа ачуы килә һәм әтисен үтерә. Моның өчен Ходай шушы Татҗалны туган җиренә бәйләп куярга куша. Шуннан бирле ул чылбырда утыра икән һәм Гаф-таһаның төбен казый, шуннан кешеләр ягына тишеп чыкмакчы була. Көне буе казый, арып йокыга китә. Таң белән уяна. Ә тау яңадан үз хәленә кайткан икән.

Ул кабат казый. Кай вакытларда бу авыр эш аның ачуын чыгара һәм ул чылбырларын өзгәләп ташларга тырышып бәргәләнә, боргалана. Шул сәбәпле җир тетри. Татҗалны тынычландырырга дип Ходай тәгалә пәйгамбәрне җибәрә.

Пәйгамбәр, килеп, Татҗалны тимер чыбык белән кыйный. Кыйналган Татҗал җиргә ава. Кабат аңына килә һәм тырмашып-тырмашып Гаф-таһа төбен казырга кабат керешә.

Аның кешеләр яши торган бу дөньяны күрәсе килә. Ул бу дөньяга чыкса, дөнья бетәчәк. Дөнья бетәр алдыннан 30 ел кала Татҗал Гаф-таһаны тишеп чыгачак. Ул музыка һәм җыр

---

[1] Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском казанском университете.— Т.XII.— Вып. 1.— Б.26.

белән дөнья буйлап үтәчәк. Кемнәр аны күрә һәм ишетәләр, алар аңа иярәчәкләр һәм шайтаннарга әверелә барачаклар. Шунда хак дин ияләре Татҗалны үтерәчәкләр.

Кайчан Татҗалны пәйгамбәр кыйный, шуннан яшен чыга. Татҗалның яман үкерүеннән күкләр күкри. Яшен сугудан үлгән кеше гөнаһлы була, андыйларның рухы чиста түгел, диләр. Андый кешене, үзен-үзе үтерүчене, эчкечене, суга батучыны башкалар янына күмәргә ярамый.

Салават күперен Әстерхан татарлары һәм нугайлар “айэндук” дип йөртәләр икән. Аның бер башы суга тиеп тора дип беләләр. Ул шулай суны суыра, тирәсендәге алтмыш чакрым җирдәге кораб һәм көймәләрне дә үзенә тартып ала, хәтта тимер чылбырларын да өзеп калдыра, ди[1].

В.А.Мошков җыйнаган бу фольклор әсәрләре асыллары белән мифларга туры киләләр. Татар халкында алар киң таралыш алганнар. Алар әдәби мотивлары, сюжет элементлары, кайбер геройлары белән Ислам динендәге хәбәрләргә дә тартымнар. Беренчедән, халкыбызның борынгыдан яшәп килгән ырым һәм ышануларына барып тоташсалар, икенчедән, Ислам диненә бәйле риваятьләрне дә хәтерләтәләр. Димәк, алар Ислам дине таратылу чорында борынгы ырым һәм ышанулардан трансформацияләнгән булырга тиешләр. Дөрес, халык авыз иҗаты үсештән тукталып тормый. Димәк, өченче яктан, без бу ырым һәм ышануларның халык тарафыннан баетыла барылуларына да игътибар итәргә тиешбез. Әмма шунысын онытып бетерергә ярамый, ырым һәм ышану кебек шактый катлаулы һәм үтә җаваплылык сорый торган мәсьәләләрдә иҗатка һәм фантазиягә бирелү дә бик үк мөмкин түгел һәм ярамый торган гамәлләрдән санала. Алар булган кадәрләренчә үзгәрми саклананалар һәм традицион кысаларында, үз рәвешләрендә кала бирәләр. Ә менә яңа тәгълиматлар тәэсирендә иҗади үзгәрүләрен фәнни яктан тикшерү тарихи һәм мәдәни әһәмияткә ия. Мәсьәләнең ул ягы да бар.

[1] Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском казанском университете.— Т.XII.— Вып. 1.— С.26–27.

Татар ырым һәм ышануларында төрле ияләргә бәйлеләре дә шактый. Су анасы, йорт иясе, шүрәле кебекләргә килгәндә, Әстерхан татарлары һәртөрле сулыкларның да ия-рухлары бар дип ышанганнар. Су анасын алар “албаслы” дип йөртәләр[1]. “Дух этот, как и человек, бывает обоих полов и плодится,— дип язып алган В.А.Мошков алар хакында.— Кроме воды, главного его местоприбывания, албаслы водится еще в старых банях, на мельницах и на старых кладбищах. Видом он похож на человека, но у него нет носовых костей, а только одна ноздря. Тело его покрыто очень мягкой шерстью в роде пуха, а ноги обращены ступнями назад»[2]. Аны әгәр дә чәченнән тотып өйгә алып кайтсаң, ул гади кеше рәвешенә керә. Албаслының күкрәкләре гайре табигый, зур, җиргә кадәр асылынып торалар, аңа йөрергә һәм йөгереп качарга комачаулыйлар.

Әгәр дә албаслыны күкрәкләре алга салынып торган чагында күрсәң, аны куып тотарга була. Әгәр дә инде ул аларны аркасына ташлап өлгерсә, артыннан атта чаптырып та җиту мөмкин түгел.

Албаслы кешеләрне суга батырып үтерә, хатыннарның, бала тапкан чакларын туры китереп, җаннарын суырып алырга тырыша. Кайвакыт моңа ирешә дә.

Албаслыны бил каешы белән генә кыйнарга ярый, әгәр дә аңа камчы яки чыбыркы ише белән суксаң, ул үсә, зурая башлый. Күпме күбрәк суксалар, шулкадәр үк дәү була бара.

Оренбург татарлары су иясен “албаслы” дип әйтмиләр, бәлки “су анасы” дип йөртәләр икән, аның чәчләре бик озын һәм күкрәкләре шулай ук тезләренә чаклы, ди[3].

Әлбәттә безнең күңелгә Г.Тукайның “Су анасы” әкият-поэмасы килә, әмма Әстерхан һәм Оренбург татарларында таралган бу риваятьләрдә алтын таракլары барлыгы хакында нигәдер бөтенләй искә алынмый.

Су анасы, ягъни албаслы белән бәйле мондый бер вакыйганы В.А.Мошков Әстерхан нугайларыннан язып алган:

---

[1] Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском казанском университете.— Т.XII.— Вып. 1.— С.27.

[2] Шунда ук.

[3] Шунда ук.— Б.28.

Нишләргә кирәклеген белгән бер кеше албаслыны эләктергән һәм чалбар каешы белән кыйнаган. Албаслы елый икән, башка һичкайчан аңа яманлык эшләмәскә антлар итеп, күзләреңдә яшь тә күренмәс дип.

Бу кеше ул албаслының ике чәч бөртеген алып кала, ә үзен җибәрә. Әгәр дә кешедә албаслының чәч бөртеге булса, ул аңарга бер дә зыян кыла алмый икән.

Ул кеше, аның чәч бөртекләрен алып кайтып, Коръән эченә яшереп куйган. Ә албаслы килгән, чәч бөртекләрен кире бирүен сорый икән. Ә теге кеше ахмак булмаган, бирергә ашыкмаган.

Албаслы хәйләгә керешкән. Бу кешегә хезмәтче булып ялланган. Хуҗалар туйга киткәч, аларның биш-алты яшьлек малайларыннан теге чәч бөртекләрен Коръән эченнән алып бирүен сораган да, теләге үтәлгәч, ул баланы кайнар казанга ташлап, чыгып та качкан. Шуннан бирле күзгә күренгәне юк, ди[1].

Оренбург һәм Әстерхан татарлары җил тегермәнендә тартылган оннан пешерелгән ризыкны ашауны гөнаһка саныйлар икән[2]. Оренбург татарлары тегермәннең иясе бар дип уйлыйлар, аны “тегермән пирисы” яки шулай ук “албаслы” дип йөртәләр. Тегермәндә йоклаган кешеләрне алар басып үтерәләр, ир һәм хатын затларыннан булалар, имеш.

Йорт ияләренә килгәндә, В.А.Мошков фикеренчә, күчмә һәм ярым күчмә нугайлар аларның барлыгына ышаналар, әмма ул рухларны урысча “домовой” дип атыйлар, чөнки йорт салуны алар руслардан алганнар икән[3].

Йорт ияләре бүрәнә ярыкларында яшиләр, имеш, аннан чыксалар — зураялар. Йоклаган кешене буарга мөмкиннәр. Әгәр кулың белән селтәнеп суксаң, тимиләр, ди. Оренбург нугайлары исә аларны “ий албастысы” яки “ий асы” дип йөртәләр. Имеш, ул хатын-кыз затыннан, чәчләре 40 аршын озынлыгында, 70 имиле, һәрберсе җитмешәр мендәрле. Төп

---

[1] Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском казанском университете.— Т.XII.— Вып. 1.— С.28.

[2] Шунда ук.— Б.29.

[3] Шунда ук.

эшләре — хатыннарны, шулай ук ат-бияләрне, сыерларны, сарык һәм башка йорт хайваннарын куркыту икән. Әгәр дә аларны сөйсәләр, чәчләрен тарап үрәләр, бөдрәләтәләр, ди[1].

Шүрәлегә килгәндә, ул — урман иясе. Аны Әстерхан татарлары “тирәк иясе” дип йөртәләр. Алар утка яки эткә әверелергә мөмкиннәр, яисә адәм сурәтенә дә керәләр. Кешене суга кадәр куып киләләр, ут шары сыман очып баралар, әмма суны үтеп чыга алмый. Оренбург татарларында аларны “шурали” дип атап йөртәләр, ирләре дә, хатыннары да, балалары да булуга ышаналар. Үзләре кеше кебек, кул-аяклары да бар, әмма бармаклары һәм тырнаклары озын. Кешеләрне кытыклап үтерәләр. «Астраханские ногайцы думают, что род человеческий, с тех пор, как живет на свете, становится всЦ хуже и грешнее,— дип яза В.А.Мошков,— а потому всЦ более мельчает: первые люди были великаны — *и к о п а д а м*, а потом измельчали и стали среднего роста; после нас же люди больше измельчают и сделаются совсем карликами — *к е ш к э а д а м*»[2].

Болардан тыш В.А.Мошков Әстерхан һәм Оренбург татарларыннан төрле легендалар да язып ала. Алары да казан татарлары тарихи риваятьләреннән аерылып торалар. Мисалга “Хәмит хәзрәт” турындагысын алырга мөмкин. Анда Хәмитнең әүвәле бик көчле баһадир булуы хакында сөйләнелә, ул бик күп дошманнарын җиңә.

Аның аты булган, хуҗасының телен аңлый икән. Хәзрәт Хәмит Әстерханда мәчет төзеткән.

В.А.Мошковның хәбәрләренә караганда, бу мәчетне 1602 нче елда руслар чиркәү итеп үзгәртәләр, ә 1698 нче елда бөтенләй сүтеп, яңадан салалар.

Мәчетне төзеткәндә хәзрәт әйтә: “Монда беренче булып килгән берәр малайны күрсәгез, тотыгыз да нигезгә салыгыз!”— ди. Төзүчеләр янына беренче булып Хәмит хәзрәтнең үз малае килә. Осталар аны кызганалар һәм бер рус малаен үтереп салалар. Хәзрәт, килеп, алардан сорап, ничек

[1] Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском казанском университете.— Т.XII.— Вып. 1.— С.29.

[2] Шунда ук.— Б.30.

булганын белгәч: “Харап иттегез төзелешне!”— дип борчыла. Ахырда нәкъ аның фаразынча килеп чыга: мәчет итеп төзетелгән бина чиркәүгә әверелдерелә[1].

“Хәзрәт Кхали”, “Тува батыр”, “Хәзрәт Игали” кебек тарихи риваятьләрдә дә сугышчан баһадирлар турында сөйләнә. В.А.Мошков аларны да язып ала. “Хәзрәт Кыхали” вакыйгаларында калмык-кытайлар белән сугышлардан хәбәрләр бирелә. Кхалины икенче төрле исем белән дә йөртәләр, ул — Казыр-Мөхәммәд (Хозер-Мөхәммәд) икән. Аның Арыслан дигән аты булган. Кытайларның Шака исемле баһадирлары белән сугыша һәм аңардан өстен чыгуга ирешә, аны үтерә. Кытайлар куркып качалар.

Вакыйгаларны бәян иткәндә В.А.Мошков бу баһадирның аяусыз булына игътибар итә. Ул шулкадәр көчле икән, бер сугуда йөзәр дошманны кырып сала. Арый, йокыга китә. Уяна. Маштагы (ягъни аты) аның янында тора. Фарсыларны да “татар диненә кертмәкче була”. Алар белән дә сугыша, әмма җиңә алмый, һәлак ителә. Фарсылар шунлыктан үзләренең әүвәлге диннәреннән китәләр, әмма татар диненә дә кереп җитә алмый калалар[2] (монда сүз сөнни мәзһәбе хакында барадыр дип уйларга кирәк).

Тува батыр исә руслар белән сугыша. Әстерханны руслар алгач, ул Сарычин (Царицын) шәһәренә кача, урысларны тупка тоткалап тора. Әмма җиңелә башлый һәм суга батып үлүдән гайре аңа башка юл калмый. Аны Әстерхан янындагы Сарай зиратына күмгәннәр. Кайчан Татҗал Гаф-таһын тишеп чыгачак, Тува батыр да кабереннән кузгалачак һәм аның белән сугышачак[3], диләр.

Игали хакындагы риваятькә килсәк, В.А.Мошковның белдерүе буенча, ул да баһадир булган. Бу риваятьнең эчтәлеге “Бакырган китабы”ндагы Хатаи Сакыйнның “Кыйссаи Әхтәм” әсәренә туры килә[4], бу факт җитди аерым әһәмияткә ия һәм ул

[1] Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском казанском университете.— Т.XII.— Вып. 1.— С.63–64.

[2] Шунда ук.— Б.64–65.

[3] Шунда ук.

[4] *Карагыз:* Бакырган Китабы: XII–XVIII йөз төрки-татар шагыйрьләре әсәрләре.— Б.208–230.

шагыйрьнең нугай татарларыннан булуын фаразларга юл ача. Әмма бу әсәрләр арасында кайбер аермалыклар да бар. Мәсәлән, Мәдинә шәһәре урынына — Ташкент, яһүдиләр урынына — руслар. Еллар узу белән әдәби язма әсәр, халык эчендә фольклорлашып, заманасына бәйле үзгәреш кичерүе аркасында ул шулай килеп чыккан. Һәрхәлдә риваятьнең Оренбург нугайлары арасында телдә йөргән булуы кызыклы һәм фәнни әһәмияткә ия күренеш. Фольклор әсәрләрен өйрәнү һәм аларны язма әдәби мирас белән тәңгәл куеп тикшерү көтелмәгән гыйльми ачышларга китерә ала.

“Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском казанском университете” тупланмасында турыдан-туры фольклорга гына багышланган мәкаләләр, күзәтү материаллары алай ук күп түгел. Тарихка, археологиягә һәм этнографиягә караганнары төп күпчелекне тәшкил итә. Шулай да этнографик язмалар арасыннан фольклор әсәрләрен һәм фольклористикага бәйле хезмәтләрне дә таба алабыз. Моның сәбәбе фольклористика гыйлеменең аерым фәнни өлкә буларак бары тик XIX йөзнең икенче яртысында гына формалашып җитүенә бәйле. Русия гыйлем дөньясында ул әлегә күтәрелеп кенә килә. Халыкның әдәби иҗаты гыйлемен җирле сөйләшләрне этнографик планда өйрәнү җәһәтеннән дә, ырым һәм йолаларны тарихи-этнографик планда барлау белән бәйле дә искә төшерәләр. Шулай да әдәбият, тарих, этнография һәм тел фәннәре берсе дә халыкның авыз иҗаты материалларыннан башка һәм фольклористика гыйлеменең фәнни казанышларын исәпкә алмыйча эш итми диярлек.

В.А.Мошковның шушы анализлап үтелгән хезмәте рус фольклористика гыйлеменең XIX йөз ахырында да әлегә этнография фәне кысаларыннан тәмам аерылып җитмәвен күрсәтеп тора. Бу тенденция XX гасыр башында да шушы рәвештә сакланып кала. Әмма алга таба фольклористика гыйлеме киңәя һәм үсә, ныгый бара.

Татар фольклористикасы исә, К.Насыйри эшчәнлеге белән бәйле рәвештә, этнография гыйлеменнән иртәрәк аерымлана. Аның бездә барлыкка килүендә һәм үсешендә тел гыйлеме,

әдәби иҗат белән шөгыльләнүчеләр дә, этнографлар да, тарихчы галимнәр дә катнашканнар.

Тагын шунысы әһәмиятле, рус хәрби офицерлары да татар халкының авыз иҗаты белән кызыксынганнар. Шул белемнәре ярдәмендә халкыбызны аңларга тырышканнар Мошков Валентин Александровичка (1852–1920) килгәндә, ул хәтта Русия география җәмгыятендә һәм Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятендә әгъзалар да булып торган[1].

3

Фольклористика гыйлеменә XIX гасырның икенче яртысында нигез салына һәм ул шул чордан безнең татар фән дөньясында татар халык авыз иҗатын барлау, җыйнау, өйрәнү, системага салу эшчәнлеге киң җәелдерелә һәм ул уңышлы рәвештә үсә башлый. Бу аның тамырлары нык булудан килә, билгеле. Шул сәбәпле XIX йөздә татар халык иҗатын өйрәнүнең торышын, үзенчәлекләрен, кайбер үсеш юнәлешләрен барларга туры килде. Дөрес, мәсьләнең барча якларын да колачлап алу мөмкин дә түгел. Әмма аңа омтылышыбыз булмады түгел. Куелган мәсьәләләр — катлаулы, аларны чишү зур белем һәм җитди эзләнүләр таләп итте. Аларның нәтиҗәсе буларак, ясалган ачышлардан чыгып, без боларны төгәл белергә тиешбез:

Беренчедән, татар фольклористикасы XIX гасырда тулысынча формалаша һәм үсеш ала башлый. Аның формалашу һәм үсешендә мәгърифәтче, галим һәм язучы К.Насыйриның эшчәнлеге бәяләп бетергесез. Татар дөньясында фән һәм гыйлем бервакытта да башка халыкларныкыннан артта булмаган, аларга ияреп кенә баручы түгел икәнлеген төшенергә вакыт. Әдипләрнең XX йөз башында халкыбызны наданлыкта һәм артталыкта тәнкыйтьләве дә бары тик әдәби идея буларак махсус кабартылган фикер икәнлеген аңларга вакыттыр.

[1] Татарский энциклопедический словарь / Главный редактор — *Хасанов М.Х.*— С.369.

Икенчедән, К.Насыйри фольклористикага тел гыйлеме белән шөгыльләнә башлаган елларында ук игътибар итә. Ул казан татарлары сөйләше нигезендә татар телен әдәби тел буларак гамәлгә кую өчен халык авыз иҗатын өйрәнүгә алына, аның ярдәмендә тел үзенчәлекләрен гыйльми тикшерү эшенә керешә. Халыкның җанлы сөйләме аңа күп төрле кызыклы материалларны һәм хикмәтле гыйлемнәрне барларга ярдәм итә. К.Насыйри үзе дә рәхмәтле булып кала һәм халыкның җанлы сөйләмен өйрәнеп, аның матурлыгын аңлап, аны әдәби тел дәрәҗәсенә күтәрә. Бу юлдагы эзләнүләре фәнни фикерләмәләренең дөрес юнәлештә алып барылуын төшенергә дә ярдәм итә. Әдип чын мәгънәсендә халыкчан язучы буларак формалашып өлгерә. Аның хикәят һәм кыйссалары бүгенге көндә дә безне сокландыралар. Җанлы һәм сурәтле әдәби тел ул чорның кайсы татар язучысында анықы кебек камил иде икән?

Өченчедән, К.Насыйри Шәрык халыкларының авыз иҗатлары ядкәрләре белән бергә, язма әдәби мирасларының нәкъ менә фольклорга иң якын торган үрнәкләрен халкыбызга җиткерә, шуның белән безне Шәрык мәдәниятенә тагын да ныграк якынайта. Аның ул ядкәрләрне халкыбызга җиткерүенең төп сәбәбе халкыбызның да алар белән кызыксынуына бәйле булган, билгеле. Гомумән дә бу өлкәдәге К.Насыйриның эшчәнлеге туктаусыз мактауга лаеклы.

Дүртенчедән, К.Насыйриның төп хезмәтләре татар фольклорын барлау, җыйнау, системага салу һәм халыкка кабат кайтару белән дә бәйле. Ул болар белән чын фольклорист галим буларак шөгыльләнә һәм татар фольклористикасы фәнен гамәлгә куюга ирешә. Аңа кадәр бу өлкәдәге эшне аның кебек дөрес юнәлеш тотып, аңлап һәм белеп башкарган бер генә галим дә булмаган. Дөрес, кызыксынучылары шактый, әмма алар фольклорист буларак түгел, бәлки этнограф яки тарихчы, яисә телче сыйфатларында, үз фәнни эзләнү һәм тикшеренү өлкәләре белән бәйле юнәлештә эш алып барганнар. К.Насыйри исә халык авыз иҗатын өйрәнүнең зарурлыгын һәм әһәмиятен ачык күзаллап эш иткән, бу өлкә күләмле, тарихи һәм гыйльми

әһәмияткә лаеклы хезмәтләр язган. Бу очракта аңа әдиплеге, язучылыгы ярдәм иткән, этәргеч биргән. Башка халыкларны да татар фольклоры белән таныштыруны ул кирәк тапкан һәм гыйльми мәкаләләр белән рус матбугатында да чыгышлар ясаган.

Бишенчедән, татар фольклористикасы барлыкка килүдә һәм аның үсеп китүендә Казан университеты каршындагы "Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте" һәм аның туплап бастырып килгән фәнни альманах-җыентыклары зур ярдәм иткәннәр. Бу өлкәдә Н.Ф.Катановның эшчәнлеген аерым әһәмияткә лаеклы. Аерым алганда, В.А.Мошков кебек этнограф галимнәрнең дә татар фольклорын өйрәнү белән бәйле эшчәнлегенә игътибар бирергә вакыт. Аның фәнни җыелмалар нигезендә төзегән, мәкаләбездә анализланган язма хезмәте татар фольклорының кызыклы катламын яктырта, киң җәмәгатьчелеккә дә ул туклаган фактлар күптән ачылырга тиеш иделәр.

Алтынчыдан, М.А.Мошков барлаган риваятьләр һәм мифлар татар халкының ырым һәм ышануларының шактый катлаулы үсеш һәм үзгәреш кичүен күзалларга ярдәм итә. Кол Галинең "Кыйссаи Йосыф" дастанының халык күңеленә никадәр тирән үтеп керүен дә төшенергә алар ярдәм итә. В.А.Мошковның мәкалә-тупланмасы белән күптән фәнни әйләнешкә кертелеп тә, ни өчендер игътибардан читтә калдырылган кызыклы риваятьләрбез, мифларыбыз булганлыгын ачыклау үзе бер әһәмиятле гыйльми яңалык буларак бәяләнә ала.

Шулай итеп, XIX йөз татар фольклористикасында ике төп фәнни көч мәйданга чыккан, аның берсе — халыкның гореф-гадәтләрен, йолаларын, телен һәм дөньяга карашын яхшы белеп, аның үзендә тәрбияләнеп үскән вәкил буларак К.Насыйри кебек галимнәрнең фидакарьләрчә хезмәт итүчеләр, икенчесе — яңа буын зыялы рус галимнәре, алар татар халкының эчке дөньясы белән фәнни нигездә кызыксына башлыйлар, аның авыз иҗатын өйрәнү аша үзләренең һәм рус халкының да дөньяга карашларын киңәйтәләр.

Бу фәнни көчләр татар фольклористика гыйлемен XIX гасырда ук башлап җибәрәләр, аның төп үсеш юнәлешләрен билгелиләр. Алар, ягъни ул тенденцияләр, беренчедән, халык авыз иҗатын барлау һәм җыйнап бастырып чыгарудан, икенчедән, аны фәнни яктан системага салып бәяләүдән, үсеш закончалыкларын ачыклаудан гыйбарәт булалар.

# М.АКМУЛЛА ИҖАТЫНЫҢ ТАРИХИ ӘҺӘМИЯТЕ, ӘСӘРЛӘРЕНӘ ТЕКСТОЛОГИК АНАЛИЗ

## I

Мифтахетдин Акмулла (1831-1895) татар шигъриятендә ике төп борылышның икенчесен башлаган һәм тормышка ашырган шагыйрь. Аның беренчесе, әйтергә кирәк — мөгаен авырыдыр, Габделҗәббар Кандалый иҗаты белән бәйле рәвештә булды. Тагын да шунысын алдан ук белдереп куярга тиешбез: Габдерәхим Утыз Имәнинең бу хәрәкәтләргә нисбәтән мөнәсәбе юк иде.

Шушы борылышлар бәлки үзләреннән-үзләре, тарихи-мәдәни процесс сәбәбеннән барлыкка килгәннәрдер? Әмма монда шагыйрьләрнең үз ихтыярларын бөтенләй исәптән чыгарып ташлау хата булыр иде.

М.Акмулла татар шигъриятен идея-проблематиканың куелышы ягыннан кискен үзгәртеп җибәргән шагыйрь буларак хаклы рәвештә характерланырга тиешле әдип. Моның өчен аңа Ш.Мәрҗани шәхесенә булган мөнәсәбәтеннән чыгып кына бәя бирү аз. Әйе, галимнең әдәби образын ул мәйданга куйды, халыкка белдерде. Бу — зур эш, батырлык иде. Әмма аның бөеклегенең хикмәте анда гына да түгел!

М.Акмулланы татар фәне “җәдитче” дип тә, “мәгърифәтче шагыйрь” дип тә атый. Моңарга без дә каршы түгел, әмма җәдитче белән мәгърифәтче дигәннәребездә аермалар барлыгын онытып җибәрмик. Бәлки тарихчы галимнәр өчен барыбердер, әмма әдәбият фәне бу мәсьәләгә сак карарга тиешле. Бездә тарихи сәбәпләр аркасында җәдиди хәрәкәтне, аңа бәйле туган җәдитчелекне мәгърифәтчелек, хәтта ренессанс-яңарыш дип күзаллыйлар, аларның үзара мәгънәдәш сүзләр түгеллеген исәпкә алып тормыйлар. Моны социализм дәверендә җәдитчелекне дөрес аңламау һәм аңлатмау аркасында туган күренеш дип бәяләми мөмкин түгел. Югыйсә бу хатаны һәм аның белән барлыкка килгән буталуларны ничек акларга мөмкин? Дөрес,

җәдитчеләр мәгърифәт байрагын югары күтәрделәр, әмма ул әле сәбәп түгел, сәбәпнең нәтиҗәсеннән гыйбарәт күренеш иде.

Җәдитчелек татар буржуаз демократиясенең XX йөз башында рәсми идеологиясенә әверелде. Бу исә татар буржуазиясенең аерым сыйныф буларак оешып җитүенә һәм милләтнең әйдәп баручы көченә әверелүенә бәйле иде. Димәк, җәдитчелек, идеология буларак, әдәби түгел, бәлки иҗтимагый күренеш. Шулай икән, әдәбият тарихына бәйле рәвештә без аны ничек аңлатырга тиешбез, дигәндә, әлбәттә идеологиягә бәйләнештә аңлау хәерлерәк икәнлеген ассызыклау белән генә чикләнә алмыйбыз. Җәдитчелекнең татар фикере үсешендәге роле һәм милли мәгариф системасына ясаган йогынтысы инде тикшерелеп, шактый гына кызыклы күзаллаулар һәм белем системаларын тудырды. Әмма әдәбиятка бәйләнештә җәдитчелекне өйрәнү, дөресрәге — җәдитчелек белән бәйле татар әдәбияты тарихын тикшерү эше XX йөзнең 20 нче еллары дәрәҗәсендә кала бирде дисәк тә әллә ни ялгыш сүз булмас. Шулай итеп без, М.Акмулла хакында фикер әйтергә җыенганда, аның җәдитчелек вәкиле икәнлеген ассызыклаудан эшне башларга тиешбез. Текстологик анализ өчен текстка нинди карашлар системасы белән якын килергә кирәклеген белүдән тыш, ул текстның кайсы әдәби алымны яки методны кулланып язылуын ачыклау — төп шартларның берсе булып тора.

Җәдитчелекне без татар милли буржуазиясенең асыл идеологиясе булуын ассызыклап тагын бер кат искәртеп үтәргә тиешбез. Әгәр дә ул аның идеологиясе икән, М.Акмулла шушы җәдитчелек әдәбиятының төп вәкиле саналгач, ул ничек казакъ яки башкорт туганнарыбызга бәйле шагыйрь була ала соң? Без хәтта, мәсәлән, рус әдибе И.С.Тургеневның да татар каныннан булуын яки А.С.Пушкинның да эфиопларга нәсел башы барып тоташканын беләбез. Бу исемлек бик озын, аны санаудан монда мәгънә юк. Әмма аларга мөнәсәбәтле аерым мәсьәлә бар: болар кем язучылары-әдипләре соң? Әлбәттә рус әдәбияты вәкилләре! Ни өчен? Чөнки рус әдәбияты, аның ярдәмендә рус халкының мәнфәгатен яклауга, аның аша рус халкының бөек мәдәниятен үстерү өчен алар хезмәт иткәннәр!

Әйе, рустан гайре халыклар турында да язганнар, башкаларның да мәнфәгатьләрен яклаганнар. Әмма шушыларга карап кына рус әдәбиятыннан аларны чыгарып ташларга тиешбезме? Алар әле әсәрләрендә, мәсәлән, француз сүзләрен дә кулланганнар. Әмма моңа карап без аларны француз әдипләре дип атарга тиешбезме? Юк, әлбәттә. Рус әдәбиятын һәм мәдәниятен алардан башка күз алдына китерүе мөмкинме соң? Ә татар әдәбиятын ничек Акмулласыз калдырып була? Аның казакъ икәнлегенә дә, башкорт белән бәйләнешенә дә каршылыгыбыз юк. Безнең бөек мишәребез Габдерәхим Утыз Имәни дә “башкорт” аталган, ләбаса! Әмма алар бит татар әдәбияты үсеше өчен хезмәт иткәннәр һәм, әдип буларак, татар әдәбияты вәкилләре булып торалар. Әллә Гали Чокрый яки Таҗетдин Ялчыгол “башкорт” аталган түгелләрме? Аңа карап кына без аларны татар әдәбияты тарихыннан һәм мәдәниятеннән чыгарып ташларга, татар әдәбияты һәм мәдәнияте үсешләрендә рольләре юк дип белдерергә тиешбезме? Язган хезмәтләре, әлбәттә, бәяләп бетергесез һәм без дә мәдәниятебез һәм әдәбиятыбыз үсеше өчен шундый әдипләр “биргәннәренә” бөек башкорт халкына да мең рәхмәтлебез, казакъларны да олыларга тиешбез. Әмма әдиплектә уртаклык мәсьәләләренә килгәндә, гафу, без аларны һәм алар белән бергә Акмулланы да татар милли мәдәнияте һәм әдәбияты үсеше системасыннан алып ташлый алмыйбыз, Акмулланың татар әдибе булуын хаклы рәвештә горурланып белдерергә тиешбез. Фәнни мәсьәләләрдә сәясәт уенын файдалану хакыйкатькә, гыйлемгә хилаф эш икәнлеген искәрсәк иде.

Шулай итеп, М.Акмулланы татар җәдитчелек әдәбиятының икенче этабына караган төп әдипләребездән берсе дип белдереп, моңа нисбәттә аның әсәрләрен бүгенге көндә ничек аңларга һәм кабул итәргә тиешлегебезне ачыклауны алга куябыз. Бу мәсьәләләрнең органик рәвештә үзара бәйле булуына инде тукталып узган идек.

Беренче карашка, әсәрләренең эчтәлегеннән, шигырьләрендә фикер корышыннан чыгып тикшергәндә, М.Акмулланың хәтта XII йөз шагыйребез Әхмәт Яссәвидән дә әллә ни аерылып тормавын күрербез. Шундый ук дини-иҗтимагый фәлсә-

фә, фикер сөреше, агымы, шундый ук шигырь тукымасы, шул ук үгет-нәсыйхәтчелек. Болар — татар әдәбиятының безгә мәгълүм булган 800 еллык дәвере буенча шулай бара, шигърият һаман да бер агымда килә, аның фикер һәм алым чикләре төгәл аңлашылып тора, яхшылыкка өйрәтә, дини булырга чакыра, гөнаһтан януны алга сөрә. Һәм менә XIX йөз башында Г.Кандалый үзгә агымны пәйда итеп, шул гасырның икенче яртысында М.Акмулла: “Шагыйрьләрдән сүз чыгар хикмәт белән!”— дип белдереп, татар әдәбияты мәйданында хикмәт, ягъни фикер фәлсәфәсенә тугыры кала. Бу инде хикмәт жанрында иҗат итүгә чакыру дигән сүз түгел, бәлки шигырьдә хис белән фикернең берлеген таләп итү буларак та кабул кылына.

Шулай да М.Акмулла татар шигъриятен яңа, үзгә агымга борып җибәргән әдип тә әле. Г.Ибраһимов аны татар прозасын яңа, европа эзенә кертеп җибәргән Муса Акъегет белән янәшә куя[1]. Прозада М.Акъегетнең җәдитче әдип булуын, шигърияттә М.Акмулла икәнлеген аның дәлиленнән соң раслап торасы да юк.

## II

М.Акмулланың әсәрләрен бүгенге көндә ничек аңларга һәм кабул итәргә тиешбез дигән сорауны алга чыгарып, әлбәттә җәдитчелеге белән бәйле рәвештә генә төшенә, асыл эчтәлегенә ирешә алабыз дип җавап бирергә мөмкин.

Безгә кадәр дә шулай аңлаганнар, без дә җәдитчелекне “яңарту” буларак аңлатабыз. Әмма бу ренессанс мәгънәсендәге яңарту түгел, бәлки камилләштереп яңарту, ягъни мөкәммәләштерү, модернизация тибындагы яңарту. Моңа күптән игътибар итәргә тиеш идек инде.

Модернизмны татарда, термин буларак, җәдитчелек дип үз чорында ук атаганнар һәм бу бер дә сер түгел. Әдәбиятта без аны, иң әүвәле, европалашуда, икенчедән, миллиләшүдә күрәбез. Аңарга кадәр милли әдәбият булмаган икән дип күзалларга ярамый, әлбәттә. Җәдитчелек милли әдәбият кысаларын милли тел һәм күзаллаулар, милли эчтәлек белән тыгыз бәйлә-

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.V.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. — Б.290.

гән. Моңа кадәр Ислам (Шәрык) мәдәнияте кысаларыннан тайпылмау, милли әдәбиятны Ислам әдәбияты юнәлешендә үстерү эстетик карашларыбызның нигезен тәшкил итсә, инде җәдитчеләр яңадан-яңа идеяләрне алга чыгарып, әдәбиятның милли үзенчәлекләрен башкача аңлый башлыйлар. Әмма бу процесс җиңел һәм үз агымы белән генә бармаган, кадимчелекнең, ягъни иске карашларда торучыларның басымы әледәнәле көчәеп алу вакыйгалары белән озатыла килгән.

Җәдитче буларак М.Акмулла, Г.Кандалый башлаган юлны дәвам итеп, халык аңлаган телдә язуны алга чыгаручылардан санала. Ул чорда татар милли буржуазиясе барча Русия мөселманнары өчен үзен җаваплы тоеп, алдынгы сыйныф дәрәҗәсен ала бара. Һәрхәлдә татар, башкорт һәм казакъ халыкларына милли буржуаз идеяләр, һаман да әлегә дини фикерләр белән төрелеп, киң җәелдерелә. Татар дөньясында 1850 нче еллардан башланып киткән телдә татарчалык, 1883 нче елдан аңа каршы булып килеп кушылган төрекчәлек ярышы[1] кискенләшә бара. Кырым һәм Кавказ төрки халыклары бу ярышны төрекчәлек файдасына хәл итү ягында торалар. М.Акмулланың исә турыдан-туры ул мәсьәләгә кагылышлы фикерләрен белдергән әсәрләре юк, әмма мөнәсәбәтен аңлар өчен шигъриятенең теленә игътибар итү дә җитә. Тел өлкәсендә шагыйрь, борынгы төрки традицияләрне дәвам иттерү белән бергә, җирле сөйләм сүзләрен актив куллану ягында тора. Әдәби телне халыклаштыру юнәлешендә әсәрләрен язуы сәбәпле шигырьләренә башкорт һәм казакъ сүзләре, сүз формалары да күпләп үтеп керә. Билгеле, мондый үзенчәлекле әдәби телне халкыбызга Әхмәт Уразаев-Кормаши үзенең "Бүзьегет" һәм "Таһир-Зөһрә" дастаннарында да тәкъдим иткән иде. Без аларны да XIX йөз әдәбиятының җәдитчелек агымына бәйле әдәби үрнәкләр буларак бәяләргә тиешбез.

Безнең татар мәгърифәтчелек реализмы асылда җәдитчелек әдәбияты, ягъни модернизм юнәлеше белән параллель, хәтта бергә үсеш алды. Моны милли әдәби-тарихи үзенчәлек дип бәяләү дөрес булыр. Шушы чорда рационалистик агымның да көч алуы хакында эндәшми киләбез. Безнең әдәбият фәнендә

[1] Сәгъди Г. Татар әдәбияты тарихы.— Б.98-99; 167-168.

һәммә әдәби агымнарны һәм алымнарны-методларны бер термин артына яшерү күренеше яшәп килә. Моның хаксызлыгын галимә Д.Заһидуллина беренче булып дәлилләп чыкты түгелме? Без аның “Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы” хезмәтен күздә тотабыз[1].

Җәдитчелекнең асылы — яңартуда (иске карашларны дип тә әйтергә мөмкин, әмма тормышыбыз нигезен хасил иткән дөньяга карашларны дип билгеләү дөресрәк булыр), дөньяга караш системаларын үзгәртеп коруда, ягъни модернизацияләүдә, яшәешкә яраклаштыруда. Моның хикмәте нәрсәдә соң?

XIX йөзнең соңгы чирегенәчә әдәбиятыбыз үзенең үсешендә һаман да бер эздән күтәрелә килә. Европалашу гына аны бу эзеннән тайпылдыра ала, тип буларак әдәбият үзгәреш кичерә башлый. Бу — кискен һәм көчле яңару, җәдитләшү. Тик җәмгыять үзе моңарга каршы килә, чөнки бу яңарыш аркасында милли үзенчәлекләр юкка чыга баралар. Моны җәдитчеләр югыйсә дөрес аңлап эш итү ягында торалар. Алар миллилекне иң беренче чиратта ислам дине йолаларын саклау һәм ныгытуда күрәләр. Шул ук вакытта бу юнәлештә иске карашларда да кала алмыйлар, Әбун-Насыйр Курсави күтәреп чыккан фикер хөрлеген алга үстереп[2], дини карашларны яңарту идеясе ныгытыла, картлар сүзенә таяну хата буларак аңлатыла башлый. М.Акмулла да “фәлән сәләф (бабай) фәлән нәрсә әйткән диләр” тезисы белән чыгыш ясый, карашларны фән нигезендә яңартып тәртипкә салуны, рационалистик юнәлешне тотуны җәмәгатьчелектән таләп итә. Әмма шагыйрь “сәләф сүзе” белән “борынгылар сүзен” нисбәтле, үзара мәгънәдәш бергәлектә аңламый һәм тәкрарламый. Аныңча сәләфләр һәм борынгылар бер үк төшенчәләр түгел. Моны дәлилләү өчен шагыйрь Ш.Мәрҗанине үрнәк итеп күрсәтә, Хисаметдин Мөслими адресына, аның “Тәварихы Болгария” хезмәтенә бәйле рәвештә, кискен тәнкыйть белән чыга. М.Акмулла өчен Х.Мөслиминең шәхесенә бигрәк тә әдәп-әхлак принципларыннан чыгып бәя бирү әһәмиятле. Аның китабына каршы фикерләр белдерүдә

---

[1] Заһидуллина Д.Ф. Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. — Б.255.

[2] Татар әдәбияты тарихы: Алты томда.— Т.2. — Б.21.

ул Ш.Мәрҗанидән узмый, әмма сүзләрен кабатлап, Х.Мөслиминең хаталарын санап чыгуны кирәк тапмый, бәлки “нинди кеше булган ул шундый ялганчы” дигән рәвештә, усал сүзләрен куертып, шәхесенә төрттерә.

М.Акмулла өчен Х.Мөслими дә сәләфләр исемлегендә, алар һәр заманда да булган, халык менә шуларга иярү аркасында хаталанган, ә кирәк иде Ш.Мәрҗани кебек ирләр юлыннан барырга.

Шагыйрь менә шушындый җәдитчелек карашларында тора, әсәрләрен шушы юнәлештә аңлавыбыз аларны дөрес төшенергә һәм бәяләргә ярдәм итә.

М.Акмулла, ни кадәр генә без аны җәдитче-модернист дип әйтмик, борынгы әдәби традицияләрне дәвам иттерүче нәсыйхәтче шагыйрь дә булып тора. Билгеле булганча, нәсыйхәтчелек — бөтен Шәрык әдәбиятына хас күренеш. Хикмәт нәрсәдә соң, нигә Шәрык әдәбияты һәм XX гасыргача аның бер тармагын булган татар әдәбияты хәтта Г.Тукай иҗатында да нәсыйхәтчелек кысаларында кала биргән? Моның сәбәбе Шәрык әдәбиятының Ислам дине идеологиясе белән сугарылган булуыннан килә, хәтта шигъриятне дини карашлар аерым кысаларда тота. Аның “шайтан чыбыркысы” *(хәдистән)* булмавы өчен Коръән нигезендә өммәткә тәрбия бирүе шарт, ягъни үгет-нәсыйхәт итүе тиешле. Шәрык суфичылык шигърияте шушы юнәлешне хис-тойгы белән 800 елдан артык, хәтта 900 еллар буена үреп бара алды. Моңардан бер тын белән генә котылу мөмкин түгел иде. Башкача шигырь — шигырь буларак кабул ителмичә, җыру мәгънәсендә кире кагыла, “бидгатьнамә” атала иде. М.Акмулла нәкъ шушы каршылык белән очрашкан шагыйрьләрдән булды да. Әмма ул бу каршылыкны чишү юлын тапкан әдип икәнлеген белдереп чыкты. “Шагыйрьләрдән сүз чыгар хикмәт белән” тезисын алга таба үстереп, бу мәсьәләдә хәдискә мөрәҗәгать итүне кирәк тапты һәм “Хатыннар биегәндә пәйгамбәребез кулын чәбәкләп торды” дигән хәбәргә халык игътибарын юнәлдерде. Моның хикмәте исә диннең үгет-нәсыйхәт белән генә чикләнмәвен, кысаларны киңәйтү кирәклеген, хиснең кеше өчен дөньяны танып-белүдә әһәмиятен белдерүдән гыйбарәт иде.

М.Акмулла “сәләфләр” фикеренә каршы борынгы галимнәрнең дәлилләрен куя алды, аларның карашларына яңача күз салды һәм шуның белән әдәбиятта яңача яшәүне, яңалыкны яклаучы буларак күтәрелде. Без башка төрле Акмулланы белмибез. Аның бүгенге көн укучысына килеп җиткән әдәби мирасы тулысы белән җәдитче икәнлеген дәлилләп тора.

М.Акмулланың реалист шагыйрь булуында да, мәгърифәтчелек идеяләрен яклавында да һичбер бәхәс юк. Шуңа күрә дә аны әдәбият галимнәре татар мәгърифәтчелек реализмы вәкиле буларак бәялиләр[1]. Җәдитчелек-модернизм белән реализм арасында без шулай ук каршылык күрмибез, бәлки модернизмны романтик яки реалистик юнәлешләрдә бердәй була дип кенә билгелибез. Әмма мәгърифәтчелек реализмын модернизм агымы кысаларына кертүне аларның табигатьләренә каршы килә дияргә тиешбез. Димәк, М.Акмулланың җәдитче-модернистмы, әллә мәгърифәтче реалистмы булуы хакында бәхәсләр мәйданга алда да чыгачак әле.

Аның нинди агым шагыйре булуын төгәл күзаллар өчен тулы иҗатына бердәм анализ ясарга кирәк. Моның өчен текстологик анализ принципларына мөрәҗәгать итәргә тиешбез. Әдипләрнең тулы иҗатларына бердәм анализ ясау шактый катлаулы эш һәм монографик планда эзләнүләрне, фәнни-тикшерү эшен оештыруны таләп итә. Текстологик анализ юлы исә бу эшне шактый җиңеләйтә. Иң әүвәлдә әдипнең барлык иҗат мирасын яхшы күзалларга, бергә тупларга, аннары гына билгеле бер принципларны алга куеп, әсәрләрен шул нигездә төркемләргә тиешбез.

## III

Әдипләрнең тулы әдәби мирасын төркемләүнең хронологик, монографик (ягъни тематик) һәм хронологик-тематик принциплары бар. Асылда без беренче ике принцип белән эш итүче галимнәрне ешрак очратабыз. Соңгысы таләпләрендә язылган хезмәтләргә дәреслек мәкаләләрен кертә алабыз. Бу принципларның һәркайсын җентекләп аңлатуның монда кирәге юк. Хронологик-тематик принципны файдалану да фәнни эз-

[1] Татар әдәбияты тарихы: Алты томда.— Т.2.— Б.440-462.

ләнү мәкаләсе өчен кулай түгел. Әдипләрнең иҗатларына анализ ясар өчен (бөтен бар, тулы иҗатлары хакында сүз бара) монографик (ягъни тематик) принципны сайлап алу уңышлы дип беләбез. Мисалга Г.Тукай иҗаты белән бәйле бер фикерне белдереп узасы килә: ул бөек шагыйребезнең әсәрләрен инде ничәмә еллар буе укучылар игътибарына хронологик принцип нигезендә тәкъдим итәбез (монда җыентыкларын, томлыкларын төзеп бастырып чыгаруларны күздә тотабыз) һәм китапларын "Мужик йокысы" яки "Государственная думага" шигырьләренең берәрсе белән ачабыз. Һәм алар аның шагыйрьлегенә бераз шик тә тудыруга сәбәпче булалар. Әгәр дә шунда монографик принципны сайлап алып, мәсәлән, шул ук "Государственная думага" шигырен "Китмибез"е артыннан укучыга тәкъдим итсәк, ул "бичара" "Государственная думага" шигыренең эчтәлеге һәм шигъри яңгырашы күңелләргә мәгънә белән барып ирешер иде. Димәк, монографик принцип томлыкларны бастыруда уңышсыз юл түгел икән!

Шигырь җыентыкларын чыгарганда Г.Тукайның тематик принцип белән эш итүенә Г.Ибраһимов та үз вакытында "Татар шагыйрьләре" хезмәтендә игътибар иткән һәм моны "сәүдәгәрлек кылудан" күргән[1]. Бу юл белән бүгенге шагыйрьләребезнең дә эш итүен китапларыннан күрергә мөмкин. Асылда алар һәммәсе дә шигырьләрен тематик яктан бер-берсен ача торган итеп төзергә тырышалар һәм шушы принципта җыентыкларын эшләп чыгаралар. Бу юл аларны уңышка китерә. Хронологик принцип исә иҗат мирасын "сыекландырып", "сибеп җибәрә". Шунлыктан әдәби иҗат үзенчәлекләрен билгеләнгәндә тематик (монографик) принцип иң уңышлыларыннан санала ала.

Әгәр М.Акмулланың иҗат мирасын төркемләсәк, аның "Дамилла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе" әсәре үзенә күрә аерым тематик төркемне хасил итүен ачыклаудан эшне башлау таләп ителә. Аның мәдхия алымы белән язылган мәрсия булуы сер түгел, фәндә мәгълүм факт[2]. Шуңа да карамастан, жанрын мәрсия (элегия) дип билгеләп, аны анализлаганда җи-

---

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.V.— Б.111.
[2] Татар әдәбияты тарихы: Алты томда.— Т.2.— Б.452.

де кисәктән гыйбарәт булуын күрсәтүдән эшне башлый алабыз. Беренче кисәген “Шиһабетдин хәзрәтнең мәдхиясе...” дип тә атаганда дөрес булыр, икенчесен “Акмулла, күп сөйләмә, инде җитәр...”, өченчесен “Бирелдем мин яшьлегемдә угрылыкка...”, дүртенчесен “Акмулланың сүзе шул...”, бишенчесен “Карасаң, Акмулланың “Диван”ы бу...”, алтынчысын “Бәгъдәс-сәлам, Нургали мулла...”, җиденчесен “Нургали мулла белән бәхәс” исемнәре белән аерырга тиешбез.

Асылда аларга бу исемнәрне авторның үз шигъри юлларыннан чыгып куябыз, ул кисәкләрнең эчтәлеген тулы килеш ачарга мөмкинлек бирүләренә игътибар итәбез. Аңлашыла ки, монда да нәкъ шул тематик (монографик) принцип белән эш итәбез, төркемләүне зур әсәрне анализлау, ягъни таркатуга, кисәкләргә бүлгәләү принцибына корабыз. Әсәрнең бу бүлекләре шактый катлаулы һәм мәрсия кысаларыннан чыгып китүен дәлилләп торалар, мәдхия генә дә түгеллеген аңларга ярдәм итәләр.

М.Акмулла бу әсәрен, әйе, Ш.Мәрҗанигә атаган, әмма мәдхия яки мәрсия итеп кенә түгел, бәлки үз уй-кичерешләрен шул “алмаз кебек галим” белән уртаклашу максатында да язган, чөнки һәр шигъри кисәге аерым бер эзлекле фикергә этәрә, мөрәҗәгать тойгысы калдыра. Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдьяр бине Мәхмүд үз кичерешләрен ханнар белән уртаклашкан булса, XIX йөз ахыры әдибе М.Акмулла бәхетенә фикер алышыр өчен бөек галим бар, менә шуңа горурлык хисләре кичерә ул, дан һәм мактау сүзләрен мул куллана түгелме? Әсәрдә авторның “сәясәте” шигъри алымга әверелеп киткәне, хәтта стильгә тәэсир иткәне сизелеп тора.

Шагыйрьнең иҗат мирасының икенче төркемен үз язмышына зарланган әсәрләре алып тора. Алар беренче төркем белән шактый аваздаш та әле: “Гаҗәп һәркем — гани булса...”, “Йа Хода, юлыңда булсын бу газиз башым фида...”, “Адәмнән һәва калмас — гарип булмай...”, “Һәркемне мулла димез алдаганда...”, “Муллалык эше кыен — җүн белмәсә...”, “Хат йибәрдем Ырынбург каласыннан...”, “Минем кебек булыр микән бәхетсез...”, “Акмулла, хәлеңне бел, үзең калай...” һәм “Хатимә”. Аларда М.Акмулла үз язмышына карата суфичыларча мөнәсә-

бәттә тора, тәкъдирнең Аллаһы тәгалә кулында булуын тәкрарлый, дөньялыкны кабул итмәвен әйтә, муллаларны наданлыкта гаепли, кешенең күңеле тулы фетнә икәнлеген белдерә. Шушы әсәрләрендә ул үзен чын мәгънәсендә суфийана шагыйрь итеп күрсәтә. Моның сәбәбен борынгы әдәби традицияләрне яңартуыннан һәм модернизацияләвеннән килә дияргә кирәк. Шагыйрь суфилык-диндарлыкны эчке халәт итеп тоя, күрә.

Болар янәшәсендә М.Акмулланың нәсыйхәт бирү юнәлешендә язган "Аһ дәрига, безнең җортта җук иттифак...", "Бөрадәр, чын мулла кем, беләсезме?..", "Мамәрдкә сүзең зая — ялынсаң да...", "Үткән җук алдымыздан хәвеф-хәтәр...", "Айтамын үгет кылып казакъ халкын...", "Тугырылык бу заманда корып калган...", "Адәм шул — гадел булып, диндар булса..." әсәрләрен алырга кирәк. Аларда бер үк әдәби мотивлар, шул ук тематика кабатлана диярлек, әмма аермасы шигъри композициядә һәм үгет аша акыл бирү, акылга өйрәтү эчтәлегендә булуларында. Бу бүлекне "М.Акмулла нәсыйхәтләре" дип атарга мөмкин. Казакъ теленә тартым язылган "Кыпчак эче Карабалык — карагызлар...", "Һәр заман сүз башланыр бисмилладан...", "Бәгъдәс-сәлам мин мосафир Акмулладан...", "Әссәламәгаләйкүм, асыл зата..." шигъри әсәрләре дә шул ук рухта язылганнар. Шагыйрь үгет-нәсыйхәтләрен халык эчендәге җитешсезлекләрне шәригать, әдәп-әхлак таләпләрен белдереп тәнкыйтьләү ашау бирә. Үгет-нәсыйхәтләрендә суфичылык фәлсәфәсе нигезендә торуы аның борынгылардан әллә ни ерак китмәвен күрсәткән кебек тоелса да, М.Акмулла фикерләмәләрне конкрет тормыш вакыйгалары белән бәйләнештә куя белүе белән әдәби иҗатта алга чыга. Ул тормыш материалын үз күңеле аша уздыра һәм дини белеме ярдәмендә тудырылган әдәп-әхлак карашларыннан чыгып аларны бәяли. Шул рәвешле М.Акмулла конкрет тормыш материалы белән эш итә, фикер йөртүдә рационалистик карашларда торса да, чынбарлыкны тасвирлауда реалистик планда язса да, киләчәккә өмет уятучы романтик юнәлешне дә иҗат манерасы итеп ала. Аңардан аермалы буларак, мәсәлән Г.Кандалыйда натуралистик сурәт тудыру көчле, ул хәтта публицистик планга да авыша, ә

М.Акмулла тормышны чагылдыруда реализмнан читкә тайпылмый.

М.Акмулланың иҗат мирасындагы 14 әсәр аерым дүртьюллыклардан тора һәм формалары буенча *кыйтга* жанрына карыйлар. Алар, шигъри кисәкләр буларак, хиснең тулы чагылышын бирмиләр, шигъри фикерне каләм очына алу, кәгазьгә төртеп кую буларак боларны кабул итәргә тиешбез.

Шуларның берсе алты шигъри юлдан, тагын берсе исә бишьюллыктан гыйбарәт.

Дөрес, ул кыйтгаларны аерым төркемгә җыю асылда тематик төркемләү принцибына каршы килә, шулай ук казакъ теленә тартым әсәрләрен аерым бүлек итеп чыгару да уңышлы түгел кебек аңлашыла. Шунлыктан М.Акмулланың иҗат мирасын өч өлештән тора дип билгеләү дөресрәк булыр иде. Аның бер өлешен Ш.Мәрҗани шәхесен әдәби образ дәрәҗәсенә күтәреп сурәтләү белән бәйле дип алсак, икенче төркемен үз язмышын сурәтләп бирүеннән гыйбарәт дияргә мөмкин, өченчесен чорны-заманы тасвирлау ярдәмендә үгет-нәсыйхәт итүче шигъри әсәрләреннән тора дип бәяли алабыз.

Бу рәвешле төркемләү уңышлырак төсле. Әмма шунысы да бар, М.Акмулла кайбер әсәрләрендә бу өч теманы бергә куша, яки ике теманы берләштерә. Шулай да, темаларга бәйләнештә әсәрләрен төркемләп җыйган очракта да, шагыйрьнең аерым бер тематиканы доминанта итүен истә тотарга, шушы рәвешле әдәби абстракт фикерләүгә ирешүен исәпкә алырга кирәк. Мәсәлән:

Һәр җәүһәрнең асыллыгы — алтын ташы,
Берәүнең — милиун сумлык кара башы;
Сөягең сөягемнән ким димәймен,
Затыңыз — затымызның садакасы!

Монда *садака* дигәнендә бөтеннең өлеше дигән мәгънә күздә тотыла, чөнки садака, зәкәт, хәер, бөтеннән өлеше аерылып, Аллаһ каршында кабул булуы теләнеп бирелә. М.Акмулланың “затыңыз — затымызның садакасы” дигәнендә, шулай итеп, бөтен белән кисәкне чагыштыруы аңлашыла. Бу кыйтгада шагыйрьнең үзен кем дип күзаллавы белән үгет-нәсыйхәт, ягъни акыл бирүе бергә бәйләнештә бирелгән.

Тематик яктан бу кыйтганы шагыйрьнең үзе турындагы шигырьләре рәтенә кертү уңышлы булачагы әсәрнең төп фикер салынган кисәгеннән чыгып анализлаудан да аңлашыла башлый. Димәк, төркемләү өчен әдәби әсәрләрне әүвәле анализлап-аңлатып чыгарга тиешбез, аннары гына аларны темаларга беркетү дөрес булачак.

IV

М.Акмулланың әсәрләре композицион яктан катлаулы түгел, әмма фикер үстерелеше белән шигырь структурасы бәйләнешендә гадәти булмаган очраклары шактый очрый. Бу анын бер әсәр эчендә өч теманы бергә җыюыннан килә. Әмма бу очракта аның әсәрләрендә фикер үсешенең структур бәйләнеше һәр куплетта ничек органик бербөтенлек хасил итә алган соң? Алар таркаулык тойгысы калдырмыйлармы? Һәм без һич юк дип җавап бирергә мәҗбүрбез, чөнки ул доминанта фикерне аерып чыгара белә.

Мәсәлән, М.Акмулланың үз язмышына багышланган һәм үгет-нәсыйхәт бирүгә корылган шигъри әсәрләренең куплетлары әүвәле бер фикер әйтелеп, аннары ул фикерне тулы килеш яисә өлешчә инкарь итү төсмерендә яки куәтләү аша хикмәтле, мәгънәле нәтиҗә чыгаруга корылган. Моның шулай булуын шагыйрьнең бигрәк тә “Хатимә” шигыре ачык күрсәтеп тора, ул тулысынча диярлек шушы конструкцияне кабатлый.

Дус дигәндә — риядән зәррә микъдар булмасын,
Дөньясы тар улса улсын — күкрәге тар улмасын.

Беренче куплеттан ук шулай башлап китеп, әсәренең ахырынача бу үзенчәлек саклана. Аның инкаре — раслау, раславы — инкарьгә әверелә. Бу исә әйтелгән фикерне тагын да куәтләндерә, шигъри сүз хикмәт сыйфатын ала. Раслауны инкарь итү төсмере белән белдерү шагыйрьгә әсәренең эчтәлеген киңәйтергә мөмкинлек бирә.

М.Акмулла гадәти тасвирларда гына сурәтләүче шагыйрь түгел, гади бәян итү формаларын да өнәп бетерми, ул — раслаучы. Аның шигъри фикерләү рәвеше шундый. Моның өчен шигырьне яки раслау һәм инкарь итү тонына кору хәерле, чөнки башкача юл белән укучыны шагыйрь үз фикерләрен кабул

итүгә этәрә алмый. Әмма аның инкаре дә раслый, автор теләген төгәл белдерүгә хезмәт итә. “Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе”, мәсәлән, раслап бару юнәлешендә язылган. Моның өчен аңа бәян итү алымына да тартылырга кирәк булган, югыйсә. Без бу очракта әсәрдәге бәхәсләшү тонына корылган урыннарны күздә тотабыз. Ул монда бәян итү формасы белән бәйле публицистик алымны гына файдаланып калмый, аның раславы коры тезмәләр белән генә дә чикләнми, бәлки алар сурәтле-метафорик раслау булып әвереләләр. Сурәтле-метафорик раслауларны М.Акмулла гадәти атау алымнары, хәтта *эт, үгез, кишер* дип ярым сүгенүләр куша барулар белән дә тудыра. Ул аңлатып тору ягында түгел. Раслау интонациясе белән әйтелгән фикерне дәлилле буларак күзаллата, аның шигыре шуның аркасында ышандыра һәм укучыга тәэсир итә, уйландыра. М.Акмулла хәтта юклык формасын да барны раслау итеп куллана, мәсәлән:

Зәррәдәй гаебеңне күрә калса,
Гаурәтне җамауга — бар, ачмауга — юк!

Мондый формалар аңа шигъри агымны монотон итүдән саклау чарасы сыйфатында хезмәт итәләр. Бу исә фикерне бер төенгә җыю һәм бер ноктага юнәлтү өчен дә уңай.

Шулай итеп М.Акмулла укучы алдына раслау интонациясе белән фикер йөртүче шагыйрь буларак килеп баса. Мондый юнәлештә иҗат итүе аны көчле рухлы итә. Ул шигырьләрен бер-бер әһәмияткә ия фикерне раслау яки инкарь итү калыбына кора, әмма үгет-нәсыйхәт һәм публицистик юнәлеш юлларын киңәйтеп, образлы чагыштыруларны һәм әдәби сурәт чараларын мул кулланып, укучыга үз мәгънәләрен тәкъдим итә.

Казанда бер фазыл чыкты алмас булып,
Хасидләре күбәйде гамь-хас булып,
Мәганә җәваһирен кулга элгән —
Хакаикъ диңгезендә гаувас булып.

Аның бу шигъри юллары суфичылык символикасына корылганнар, гүяки һаман ул да Ә.Яссәви һәм С.Бакырганилар эзеннән бара кебек. Әмма монда инде яңа эчтәлек бар. Ул исә

үз заманы шәхесен әүлияләр, изгеләр мәртәбәсендә күрә белү көченнән, замандашына пәйгамбәргә сокландагдай соклана белү бәхетеннән килә.

## V

М.Акмулла әсәрләрендә шигъри юллар һәм аларга аңлатма-шәрехләр, ягъни интерпретацияләр замана үзгәреше белән бергә тирәнәя дә бара. Моның өчен милли тарихыбызны, милли фикер үсешенең эчтәлеген тирәнрәк төшенә бару ярдәм итә. Акмулланың шигырьләрендә замандашлары гыйсьянчылык күрсәләр, без аларда тарихилык һәм халыкчанлыкны табабыз. Ул телдә генә түгел, уйда-фикердә дә, төрекчелек ягына бармыйча, татарчалык юнәлешендә хәрәкәт иткән һәм XIX йөзнең икенче яртысы өчен төп шагыйребез булды. Әмма аның телендә гарәп-фарсы сүзләре дә шактый иде. Шулай да алар инде төркиләшкән, дөресрәге — татарлашкан иделәр, үз чорының гади халкы аңлаган һәм кулланган мәгънә вариантларында булдылар. Ә бу исә бүгенге көн текстология фәненә авырлыклар китереп тудыра. Һәр чорның-заманның үз мәгънәләре булган кебек, сүзләренең дә эчтәлекләре төрлечәрәк.

Сүзләренең төгәл мәгънәсен ачу һәм билгеләү М.Акмулланың әсәрләрен дөрес төшенү, фикерләренә төгәл бәя бирү өчен дә кирәк. Барыбызга да билгеле, ул әле җирле сөйләм сүзләрен, әле себер татарлары һәм башкорт, казакъ гыйбарәләрен уңышлы файдаланган шагыйрь дә. “Акмулла хакында бары стихияле рәвештә “катнаш” телдә язучы шагыйрь сыйфатында хөкем итәргә ярамый” [1] дип, шагыйрьнең әсәрләрен текстологик яктан әзерләп бастырган галим М.Госманов хаклы рәвештә күрсәтмә ясарга кирәк тапкан.

Акмулланың шигырьләре XIX йөз татарчалык юнәлешен тоткан әдәби фикерләүнең үзенчәлекләрен дә үзләренә җыйган иде, билгеле.

Хәл килсә, төрле фәнне күргән яхшы,
Камилләр катарына кергән яхшы,

---

[1] Акмулла. Шигырьләр / Төзүчесе, сүз башы мәкаләсе һәм искәрмәләр авторы — *Госманов М.А.*.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. — Б.30.

Урысча укып кына түгел белмәк —
Хәл килсә, французча белгән яхшы,—

дип яза ул “Бөрадәр, чын мулла кем, беләсеңме?..” шигырендә һәм тел белән динне бер бәйләмдә карамау тиешлеген белдереп чыгыш ясый.

Шушы куплетта “камилләр катары” хакында искә алына. Бу исә “гыйлемдә камиллеккә ирешүчеләр төркеме”н аңлата, “катар” дип асылда “кәрван”ны атыйлар, “көтү” һәм “төркем” мәгънәләрендә дә аны аңларга мөмкин. Әмма ул очракта мәгънә тупаслана. “Камил кешеләр кәрваны” дигәндә мәгънә шигъри төсмер ала, Ә.Яссәви, Колшәриф кебек урта гасырлар дәвере әдипләре хәбәр иткән “суфилар силсиләсе” күз алдына килеп баса. Алар да фикердә һәм гамәлдә үзләреннән тарихи алдагы галимнәрнең “итәгенә ябышып” баруны мактап язган иделәр түгелме?

Фәйзе Хак һәр мескинә шарт имәс Багдад, Хәләб,
Йорты Болгар булса булсын — йортны болгар булмасын!

(*Ягъни:* Аллаһы насыйбы белән һәр суфига Багдад яки Хәләбтән булуы мәҗбүри түгел, Болгардан булса да ярый, әмма илне болгатучы булмасын!)

Бу шигъри юллар М.Акмулланың “Хатимә” шигыреннән, бүгенге көндә дә телләрдән төшмәгән гыйбарә булып тора. Ул, шушы рәвешле мәгънәдәш сүзләр кулланып, укучыны уйланырга мәҗбүр итә белә. Омонимнарны оста файдаланып, шагыйрь гарәп һәм фарсы алынмаларына еш мөрәҗәгать итә. Бу хәл исә текстологларны тагын да каршылыклы, хәтта бәхәсле эзләнүләр эчендә адаштыра. Шул сәбәпле М.Акмулла әсәрләренә өстәмә шәрехләр бирү мәҗбүрияте туа һәм ул эш әдәби әсәргә текстологик анализ биргәндә төп шартларның берсенә әверелә.

Татар әдәби ядкәрләре гомумән дә шәрехкә мохтаҗ. Бу аларның зур мәдәни традицияләр тәэсирендә язылулары сәбәбеннән килә. Монда без М.Акмулланың һәр әсәрен дә шәрехләп бирә алмыйбыз, әмма шуны белдерергә тиешбез: хәзерге вакытта иске китапларны юл асты сүзлекчәләр белән баетып бастырып чыгаруны “шәрехле басма” дип атап йөртү урынлы.

Чөнки алар гадәти сүзлекчәләр генә түгел, күбесе аңлатмаларны эченә алган шәрех төсмерендә биреләләр түгелме?

VI

М.Акмулладан иң каһәрләнгән кешеләрдән берсе — истәк мулла. М.Госманов бу сүзгә аңлатма биреп болай яза: “Акмулла башка әсәрләрендә дә башкортларны шулай “истәк” дип атый”[1]. Шагыйрь “истәк мулла” атамасын казакъ старшинасы Исәнгилдегә бәйле дә куллана кебек әсәрләреннән аңлашыла. Бу сүзнең мәгънәсе нинди һәм каян килеп чыгуы да кызыклы. Әгәр дә М.Госманов фикере дөрес булса, Исәнгилде түрәне башкорттан чыккан шәхес дияр идек. Шуны күздә тотып булса кирәк, М.Госманов “истәк — башкорт, казакълар тарафыннан кулланылган этноним”[2] дип атап фикер йөртә.

Ә кемнәргә карата кулланылган этноним соң ул? Бәлки М.Госманов монда башкортларның һәм казакъларын “истәк” дип аталуларын искәртергә телидер?

Текстологик анализ гомуми аңлатмалар таләп итүче гыйбарә, хәтта абзацларны барлап, аларның мәгънәсен ачыклауны да үз өстенә алудан башка була алмый. М.Акмулла иҗатына килгәндә, бу эшне М.Гайнуллин, М.Госманов, Р.Әхмәтов һ.б. галимнәр этрафлы башкардылар. Әмма “истәк мулла” кушаматы, безнеңчә, әле аңлатуны таләп итә.

Истәк белән Исәнгилде арасында берникадәр аваздашлык бар һәм ул үзен сиздереп тора. Тик текстологик аңлатма өчен бу гына җитми, дәлилләп бирү, раслаучы чыганакларны барлау, аларга таяну сорала. Без бу сорауга җавап эзләп карадык, әмма таянырлык хәбәр табылмаган иде. Шулай да татарда “истәк” һәм “иштәк” атамаларының параллель кулланылуын билгеләп үтәргә тиешбез.

*Иштәк* дип себер татарларын атау әле XX гасыр башында кулланылышта булган. Бу — кызыклы факт. Бездә казан татарларын *чохым* (*ч* авазы белән сөйләшүчеләр яки чокырда яшәүчеләр, ягъни Казанны шулай түбәнсетеп-шаяртып әйтү,

---

[1] Акмулла. Шигырьләр / Төзүчесе, сүз башы мәкаләсе һәм искәрмәләр авторы — *Госманов М.А.* — Б.252.

[2] Шунда ук. — Б.252.

“казаннар” мәгънәсендә), көнбатыш диалект вәкилләрен *мишәр* дип аеру гадәте бар. *Чохым* яисә *чокым* бик кулланылмаса да, *мишәр* атамасы телдән төшәргә җыенмый. Ә менә *иштәк//истәк* дип себер татарларын аерып атап йөртү гадәте бөтенләй диярлек онытыла төшкән. Моның дәлиленә Р.Фәхретдин тарафыннан Оренбург шәһәрендә “Шура” журналына кушымта буларак чыгарылган “Тел ярышы” җыентыгының 1910 нчы елгы 63 нче номерлы “Ата-бабадан сөйләнә килгән” дип аталган “Тройскида мөгаллим Әхмәт Туктабаев” исеме белән имзаланган мәкаләне китерергә була. Автор сүзне “Табуллык улдыгымнан” дип башлап китә. Аның язмасында: “Бу көндә суның түбән агымнарында җәелгән “иштәк” дигән курчакга табынучы кешеләр илә безнең телемез бер булган”[1],— дигән сүзләр бар һәм аларның бер өлеше ислам диненә күчкәнлеге дә искәртелә. Димәк, *иштәк//истәк* атамасы белән себер татарларын мәҗүси вакытларында ук белдергәннәр булып чыга. Хәзерге вакытта Төньяк Боз океанына таба Иртеш буйларында хант һәм мансий халыклары яши. Акмулла “истәк” атамасы белән шуларны искә ала дисәк, бик тә сәер һәм гайре табигый булыр. Борынгы Америка астеклары белән истәкләрне бер үк халык дип сүз җылытучыларны да аз ишетмәдек.

*Истәк// иштәк* этнонимының себер татарлары белән бәйләнешен раслаучы дәлилебез ныклы. Башкорт һәм казакъ халыкларының иштәк дип аталмаулары ачык аңлашылып тора. Шулай ук бу атама-этнонимның географиясе шактый киң булуы да тарихлардан күренә. М.Акмулла аны Исәнгилде түрәгә атап кына кулланган дисәк, ул вакытта да сорау туа: ни өчен аны мулла дип белдерә икән соң? Бәлки истәк мулланы без Акмулланың үзенә антиподы дип белергә тиешбездер? Тик бу сорауга җавап бирү өчен бездә әлегә аргументлар җитешми, шунлыктан аны ачык калдырырга мәҗбүрбез. Әмма мондый фаразыбыз да бар: Исәнгилде себер татарларыннан булган, кайчандыр муллалык иткән, аннары казакъларга түрә итеп куелган, халыкта шул сәбәпләр белән бәйле рәвештә “иштәк мулла” дип аталып йөртелгән (ягъни “себер татары мулласы”

---

[1] Тел ярышы / Мөтәртибе — *Ризаэтдин бине Фәхретдин*.— Оренбург: “Вакыт” мәтбагасы, 1910. — Б.155.

мәгънәсендә). Хәер, әле XX йөз башында гына да Исәнгилдин дигән данлыклы себер татар байлары булган түгелме?

Бу урында М.Акмулла иҗатына ясалган текстологик анализның төп нәтиҗәләрен генә бәян иттек. Шуны аерым ассызыклап үтәргә тиешбез: тулы бер иҗатка текстологик анализ ясау шактый катлаулы эш. Аны аерым әсәрләргә бәйле рәвештә уздыру уңышлырак кебек күренә. Әмма бу фәнни анализ методы шактый киң планда да кулланыла ала.

## АКМУЛЛАНЫҢ ӘДӘБИ МӘКТӘБЕ

Г.Тукай үзенең “Шигырьләребез”[1] дип аталган, “Фикер” газетасының 1907 нче елгы 22 нче апрель санында басылган мәкаләсендә, татар шигърияте үсешенә карата фикерләрен белдереп, М.Акмулла иҗатына да бәя биреп уза. Шунысы әһәмиятле, ул монда үз өстәлендә яткан бер казакъ “үләңе”, ягъни шигыре нигезендә бу уйларга килүен белдерә һәм гомумән дә казакъ шигъриятендә дөньяви мотивларның көчлерәк булганлыгын дәлилләп үтә, аннары Суфи Аллаһияр һәм Габдеррәхим Утыз Имәни иҗатларында суфичылыкның өстенлек алуын, аларның шигырьне “тик тәсаувыф бабында[2] гына сөйләгәннәр”ен белдерә, дөньяви мотивларның татар язма шигъриятендә бөтенләй үстерелмәгән булуына зарланып, андый юнәлештә шагыйрьләр иҗат иткән булсалар да, ул “шигырьләр шагыйрьләре берлә бергә кабергә күмелдеме?” дип ачынуын яза.

М. Акмулланың әдәби мирасына килгәндә, аның иҗатына да тәгассеп-схоластика катышканлыгын ассызыклаганнан соң, “безнең татар рухына, татар халкына бер дә тәэсире юктыр, шигырьләреннән тик казакъ исе, күчмә халык исе чыгып торадыр” дигән нәтиҗә ясый. Шуннан соң фикерен үз чоры

[1] Тукай Г. Әсәрләр биш томда.— Т.4. Проза. Публицистика (1907-0913).— Казан: Татар. кит. нәшр., 1985.— Б.31-34.

[2] Тәсаувыф бабында — суфичылык юнәлешендә.

шагыйрьләренә юнәлтеп, “безнең 17 нче октябрьдән соң мәйданга чыккан ике бөек шагыйребез үрнәкне шул мәрхүм Акмулладан алганнар булырга кирәк, чөнки шигырьләрен галибән[1] шул казакъ бәхре илә[2] язалар” дип, фәнгә мәгълүм булганча, Мәҗит Гафури һәм Нәҗип Думавиларны [3] М.Акмулланың шигъри мәктәбе вәкилләре буларак бәяләп уза. Академиклардан М.Госманов бу исемлеккә Дәрдемәндне дә кертә, Х.Миңнегулов исә “Дәрдемәнд иҗатындагы хас афористик фикерләү казанышлары” белән “Ш.Бабичның тәнкыйди сатирик рухлы язмаларында Акмауллага аваздаш яклар бар” дип конкретлаштырып, бу исемлектә Ш.Бабичны да саный [4]. Шулай итеп, XX йөз башындагы әдәбиятта М.Акмулла шигъриятенең традицияләре яшәүдән туктамаганнар, шагыйрьдән-шагыйрьгә үстерелеп килгәннәр, хәтта бер әдәби юнәлеш хасил иткәннәр икән дияргә кала. Г.Тукай бер дә юктан гына бу турыда язмаган, билгеле. Аның сизгер күңеле әдәби процессны яхшы тойган.

Әмма шуны да искәртергә кирәк, М.Акмулланың шигъри традицияләре М.Гафуриның иҗатында дәвам иттерелү хакында беренче булып аңлатып чыккан әдип Г.Тукай түгел. XX гасыр башы татар шигъриятенең Акмулла традицияләре нигезендә үсеш алуын “Морад” имзасы астында язган Р.Фәхретдинов 1906 нчы елның 9 нчы декабрендә үк белдереп уза. Ул Г.Тукай шигъриятен әл-Мәгари иҗаты белән тәңгәл куюдан тыш, М.Гафурида фарсы шагыйре әт-Туграи үзенчәлекләрен күрә, әмма М.Гафури шигъриятенең асылда Акмулланы дәвам итүен ачык билгели[5].

Г.Тукайны Р.Фәхретдиновның бу мәкаләсе белән таныш булмаган дип әйтеп булмый. Аның “Шигырьләребез” мәкаләсен дә Р.Фәхретдиновка җавабы буларак күзалларга ярамый. Хикмәт шунда ки, Г.Тукай, 1905 нче елгы илдәге үзгәрешләр тәэсирендә мәйданга чыккан яшь шагыйрь, бары

[1] Галибән — үбесенчә.

[2] Бәхре илә — шигъри үлчәме белән.

[3] *Карагыз:* Тукай Г. Әсәрләр биш томда.— Т.4.— Б.296.

[4] Миңнегулов Х.Й. Дөньяда сүземез бар...— Казан: Татар. кит. нәшр., 1999.— Б. 136.

[5] Вакыт.— 1906.— 9 нчы декабрь.

тик бик кыска ара эчендә, ягъни 1906-07 нче елларда үзенә әдәбият мәйданын яулый башлый. Хәтта каләмдәшләренә карата да гаять кискен, мыскыллау дәрәҗәсендә диярлек чыгышлар ясаудан һичбер авырыксынмаган яшь шагыйрь, тәнкыйть мәкаләләрен генә түгел, хәтта әдәби әсәрләрен дә моңа кадәр яшәгән һәм барлыкка килгән әдәби традицияләргә каршы куйгандай иҗат итә. Моны тәрбия җитешсезлегенә генә дә кайтарып калдырырга ярамый. Бу дәвердә, иҗтимагый тормыштагы кебек үк, төрле мәнфәгатьләр каршылыкка киләләр. Шунысы әһәмиятле, ул мәнфәгатьләр һәммәсе дә тормышчан һәм яшәү көче белән сугарылганнар. Аларның кайсы хаклырак булганлыгын тарихлар үткәннән соң гына ачык күз алдыбызга китерергә мөмкинлек туды. Асылда Г.Тукай үз шигъриятенең көчен әдәбият мәйданында раслап чыгу өчен тырышуы белән бергә, халык күңеленә якын шигъри мәктәбен дә барлыкка китерә алды. Ә мондый зур һәм җаваплы адымны бары тик көчле рухлы әдипләр генә ясый ала. Бу хәзер дә шулай.

Г.Тукай, әдәби-эстетик карашларын раслау белән бергә, үзен әйләндергән әдәби мохитнең эчтәлеген һәм үзенчәлекләрен дә ачыклап аңлатып бирә алды. Бу чорда, билгеле булганча, аның иҗат кредосы белән каршылыкка килерлек куәтле әдәби агым — Акмулла башлаган һәм юнәлешен билгеләгән, Г.Ибраһимовның “Татар әдәбиятында өч дәвер” дигән хезмәтендә аңлатылганча, “җәдит әдәбият” инде яшәп килә иде[1]. Г.Ибраһимов “Берничә сүз” (1921) дип исемләнгән мәкаләсендә бу дәверне болай дип характерлый: “Аврупа капитализмы арага керә башлый, матди тормыш үзенең иске үлек ноктасыннан кузгала, үзгәрү мәҗбүрияте килә. Шуның тәэсире белән бездә дини яңалык хәрәкәте туа — Шиһаб Мәрҗани, Насыйри, Курсавилар дәвере башлана. Бу дәвернең шагыйрьләреннән һәммәбезгә мәгълүм булганы — мәшһүр Акмулладыр”[2].

---

[1] *Карагыз:* Ибраһимов Г. Әсәрләр сигез томда.— Т.5. Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910-1933).— Казан: Татар. кит. нәшр., 1978.— Б. 290.

[2] Шунда ук. — Б. 256.

Прозада бу дәвернең башлангычын Г.Ибраһимов М.Акъегетнең “Хисаметдин менла”сына бәйли, Ф.Кәрими, Ярулла Вәли, Р.Фәхретдинов, Җ.Вәлидиләр белән бергә шушы “җәдитчелек әдәбияты” вәкилләре итеп Н.Думавины, М.Укмасины, Дәрдемәнд һәм С.Рәмиевләрне дә күрсәтә[1]. Әдәби процессны тикшерүгә багышланган мәкаләләренең һәркайсында диярлек Г.Ибраһимов шушы фикерләрен туктаусыз кабатлап бара һәм М.Гафурины татар әдәбиятында, аерым алганда, “Берничә сүз” мәкаләсендә, Акмулла традицияләрен үстереп җибәрүдән башлап, җәдит, ягъни мәгърифәтчелек, буржуаз милләтчелек, ягъни тәнкыйди реализм һәм эшчеләр әдәбияты, ягъни социалистик реализмга, өч этапны да узып, өч дәвергә дә хезмәт итә алырлык дәрәҗәдә бөек әдип булуын аңлатып уза[2].

Бу фикерләрне Акмулла иҗаты белән бәйләп карасак, шушы шагыйребезнең татар шигърияте үсешендәге роле никадәр зур икәнлеген күз алдына китерербез һәм аның шигъри мәктәбенең көчле рухлы һәм яшәүчән булганлыгына соклануыбызны да ачык белдерү урынлы тоелыр. Димәк, Г.Рамазановның Акмулладан М.Гафури “шигырьнең табигый агышын, халыкчан кинаялекне, афористик образлылыкны, төзек ритм һәм анык рифмалар белән эш итүне өйрәнә, Акмулла кебек үк ул да халык мәкаль һәм әйтемнәрен, халыкчан параллелизмнар куллана”[3] дигән иҗтимагый-фәнни әһәмияткә ия нәтиҗәләргә килүендә һичбер хата, хакыйкатькә хилафлык юк.

Г.Халит исә, М.Акмулла һәм М.Гафуриларның иҗат мирасларындагы уртак якларны билгеләп, “ике гасыр аралыгында — туып килгән яңалыкларны, прогресс һәм мәгърифәтчелек романтикасын хәбәр итеп — (...) шигырь мәйданына аяк бастылар” дип, аларга теоретик югарылыкта бәяләмә бирә. Галим Р.Әхмәтовның “Акмулла иҗаты татар поэзиясендә мәгърифәтчелек реализмы хәлиткеч җиңүгә

---

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр сигез томда.— Т.5. Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910-1933). — Б. 290.

[2] Шунда ук. — Б. 254-260.

[3] Рамазанов Г. Мәҗит Гафури // Татар әдәбияты тарихы алты томда. — Т.3. XX гасыр башы.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.— Б.152.

ирешә бару хакында сөйли. Сурәтләү объекты чынбарлык булу, тел-сурәтләү чараларын халыкның җанлы сөйләм теленнән, халык авыз иҗатыннан эзләү, әсәрләре турыдан-туры киң халык массасына, аның да изелгән, ярлы катламына адреслану, социаль тигезсезлекне, сыйнфый тигезсезлекне фаш итү, залимлеккә кискен протест белдерү — болар барысы яңа чор — XX йөз башы поэзиясенә юл ачалар"[1] дип биргән билгеләмәсе шагыйрь М.Акмулланың иҗат үзенчәлекләрен тулы канлы итеп ачуын ассызыкламый мөмкин түгел.

Шулай итеп, М.Акмулланың әдәби процесста шактый төгәл һәм әһәмиятле урын биләвен күрәбез. Ул үзеннән соңгы шагыйрьләрнең мәйданга чыгуында да зур роль уйнаган. Шигърияте үзенчәлекләре аларның да иҗат кредосына әверелгән. Болардан чыгып, һич шикләнми Акмулланың татар әдәбияты тарихыннан тәмам аерылгысыз булуын ачык билгеләргә тиешбез.

М.Акмулланың иҗат үзенчәлекләре, сакланып калган иҗат мирасы һәм аның үзеннән соңгы шагыйрьләрнең формалашуына һәм үсешенә йогынтысы фәндә җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелгән, билгеле. Әмма кайбер мәсьәләләргә ачыклык кертәсе бар әле. Шуларның берсе — Акмулланың шигъри мәктәбе белән бәйле. Яшермик, М.Акмулланың М.Госманов тарафыннан әзерләп чыгарылган шигырьләр җыентыгына кертелгән текстларындагы сүзләргә бирелгән ас төшермә аңлатмаларда һәм тәрҗемәләрдә авыр хаталар булу аркасында фикерләре буталган. Күп урыннарда ялгыш укылулар аркасында әдипнең әдәби-эстетик карашларын ачыклауга да кыенлыклар тудырылган. Төп мәсьәләне чишү, ягъни шагыйрьнең әдәби-эстетик карашларын билгеләү — аның шигъри мәктәбенең, яңа бер әдәби агымга башлангычының нигезен ачыклау дигән сүз ул.

Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт берлән,
Анчә күз алартмаңыз миддәт берлән,
Ниһайә булса мөкайад йә мөнәүвәл:
Харам-хәләл шәхесенә нисбәт берлән,—

---

[1] Әхмәтов Р. Мифтахетдин Акмулла. — Татар әдәбияты тарихы алты томда.— Т.2. X1X йөз татар әдәбияты.— Б.246.

(**Сүзлекчә:** *Анчә* — алай, аңа; *миддәт* — тупаслык, әллә кемлек; *ниһайә* — нәтиҗәсе; *мөкайад йә мөнәүвәл* — әҗер йә өмет.)

дигән юллар белән “Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе” поэмасында М.Акмулла үзенең әдәби-эстетик карашларын бәян иткән бер бүлекчәне башлап китә. Асылда нәкъ шушы тугыз куплет эчендә шагыйрь шигърият үсешендә төп роль уйнаган фикерләрен ачыклап бирә дә инде. Монда сүз шигырьнең мәгънәдә тирән, ягъни хикмәтле булырга тиешлеге, әсәрне өмет һәм әҗер белән сугару кирәклеге хакында бара. Гади, тирән, ачык шушы таләп алга таба шигъриятнең төп үсеш кыйбланамәсенә әверелә, XX йөз башы әдәбияты шушы юнәлешне тота. Г.Тукайны гына алсак та, аның шигърияте һәммә барлыгында шушы рух белән сугарыла.

*2001.*

## Г.ТУКАЙ ИҖАТЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЧОРЫ: АСЫЛ ХИКМӘТЛӘРЕ

Г.Тукайны бездә бөек дип атыйлар. Шушы бәяләмәне раслау омтылышында йөзләрчә әдипләр тарафыннан әсәрләр, фәнни мәкаләләр язылды һәм язылачак. Ни өчен Г.Тукай чыннан да бөек дигән сорауга җавап биреп бетерү мөмкин дә түгелдер сыман. Хикмәт нәрсәдә соң? Һәр чор-заманның, хәтта укучының да үз Г.Тукае булуда гынамы? Ни өчен аның гадәти һәм телдән-телгә күчеп йөргән шигырьләре һаман да безнең күңелләрне нурландырып тора?

Боларга кайчан да булса җавап биреп бетерү мөмкин түгелдер сыман.

Г.Тукай татар дөньясының искесе белән яңасы арасында басып торган маяк шикелле ул. Әдәбият халыкның эчке дөньясын чагылдырырга тырыша. Әхлак-әдәп, гадәт кануннарын бәян итә, кешене тормышка әзерли, гомере буе күңелен-зиһенен шатландырып, ныгытып, баетып килә.

Г.Тукай, татар яшәешендә иске карашларга бәйле сакланган гадәтләр белән каршылыкка кереп, яңа дөньяви күзаллауларга берегеп туган әхлак-әдәп төшенчәләрен төгәл аера алып, шигъриятендә хисләрне рухи-мәдәни омтылышлар югарылыгында кора алган әдип буларак иҗат итте. Аның әсәрләре дә яңа белән искенең кискен конфликтын кичерү аша мәйданга чыктылар һәм халык күңелен яулап алдылар.

Г.Тукай яшәгән чорда тормыш реальләре катлаулы үзгәрешләр белән тулы иде. Әмма бу үзгәрешләр һаман да көчле каршылыклар эчендә бара иделәр. Моны яхшы тоеп, ул чор әдипләре бу көрәшне “кадимчелек һәм җәдитчелек тартышы” дип атадылар. Тормыш реальләре үзгәрү шул ук тормышка мөнәсәбәтне дә борды, ничек дөрес була дигән сорау халык алдына килеп басты. Әлбәттә бу иҗтимагый мәсьәләне чишүгә күп төрле әдипләр тартылдылар. Г.Тукай алар арасында беренчесе дә, соңгысы да түгел иде.

В.Шкловскийның итальян гуманисты Җ.Боккаччио (1313–1375) иҗаты белән бәйле тикшеренүләрендә мондый фикер алга чыгарыла: “Мы должны понимать, что единство самобытного нравственного отношения к предмету описания для разных эпох разное, как отличается для разных эпох сама нравственность”[1].

Тарихи-рухи күчеш чорында әхлакый карашлар үзгәрә, язучылар шул үзгәрешләрне прозада характерлар рәвешендә яки шагыйрьләр поэзиядә хисләр каршылыгында сурәтләп бирәләр. Шушы юнәлештә XX йөз башы татар әдипләре ачылдылар да инде. Г.Исхакый, Ф.Әмирхан, С.Рәмиев, Г.Камал, Дәрдемәнд, Г.Ибраһимов, Ш.Камал, М.Фәйзи һәм башка йөзләрчә язучы һәм шагыйрьләрне татар әдәбияты тарихы нәкъ шундый акыл ияләре буларак бәяли. Г.Тукай алар арасында иң халыкчаны иде.

Татар әдәбияты тарихында талантлар Г.Тукайга кадәр дә бар иделәр, аның чорында да аларның саны ике йөзгә кадәр җитте, аннан соң да алар тудылар. Бу яктан халкыбыз үзенең алдынгы милләтләрдән булуын күрсәтте һәм күрсәтә килә. Мәсәлән, бер Дәрдемәнд яки С.Рәмиев кенә дә, Г.Тукайның чордашлары, бөек шагыйрьләр, талант ягыннан, шигъри фәлсәфә, хис-тойгы, әдәби эшләнеш, иҗат мәртәбәсеннән килеп бәяләгәндә — хәтта өстенгә дә чыгалар әле. Моны үз заманында Г.Ибраһимов “Татар шагыйрьләре” (1912-1913) фәнни-тәнкыйди аналитик хезмәте белән раслап аңлата да алды. Аның фикерләре белән килешергә була, килешмәскә, әмма ул күп очракта хаклы да булып кала бирә. Фәнни анализ нәтиҗәләре бәхәс тудыра алалар, әмма аларны юкка чыгару мөмкин түгел.

Г.Ибраһимовның анализлары дөрес, Г.Тукай иҗатын яхшы белүе күренеп тора. Ә карашларда һәммә кеше чикле. Г.Ибраһимовның фикер сөрешен аңлый алган очракта, без аны хаталануда, тенденциоз язуда гаепләргә тиешбез. Хезмәте шундый эчтәлектә аңлашыла да. Дөрес, кистереп әйтергә дә тиешбез: Г.Ибраһимовны якларга яки аның хаталарын акларга

---

[1] Шкловский В. Художественная проза: Размышления и разговоры.— М.: Сов. пис., 1961.— С,177–178.

да җыенмыйбыз. Ул аңа мохтаҗ да түгел, бу безнең максатыбызга да керми. Әмма аның фикерләрен санга алмау шулай ук томаналык сөреме астындагы наданлык булып калыр иде.

Кабатлап белдерәбез: шунысы әһәмиятле, Г.Ибраһимов Г.Тукай турында дөрес яза, иҗатын дөрес анализлый, аңа туры бәя бирә. Һәр фикере дәлилләнелгән, саллы, очраклы фикерләр җыелмасын тәшкил итми. Бары тик бер мәсьәләгә генә игътибары җитмәгәнлеген төшенми калырга ярамый: Г.Тукай чыннан да коеп куйган шагыйрь генә түгел, аның шигъри строфикасында мантыйк гаҗәеп көчле булу белән бергә, шигырьләре поэтик төзеклеге, метафорика ягыннан эшләнешләрендә алай ук хәйран итәрлек тә түгелләр сыман. Бу хакыйкать бары тик башка әдипләрнең иҗатлары белән әсәрләрен чагыштырма планда өйрәнгәндә генә ачыла ала. Шунысын онытмыйк: Г.Тукай шигъри-метафорик мантыйкны формаль логика кысаларыннан читкә чыгаруны өнәмәгән әдип, ягъни ул образлылыкның мантыйклы булуы өчен җан аткан, болар хакында мәкаләләрендә туктаусыз белдерә килгән. Шушы ягы белән ул чын мәгънәсендә даһиларча эш итә. Шигырь теориясендә ат уйнаткан сакчыл хисле күңелләрне ул хәтта аптырашта да калдыра.

Болар без Г.Тукайның шагыйрь буларак талантын, шигырь тудыру ягыннан гаҗәеп тә оста икәнлеген шик астына алабыз кебек аңлашылырга мөмкин. Аның талант дәрәҗәсенең югарылыгы бәхәссез! Сүзләребез Г.Ибраһимовны кабатлау кебек яңгырасалар да, ачык итеп искәртми узу мөмкин түгел: Г.Тукайның шагыйрь буларак хикмәте яңа шигъри формалар, шигъри осталык үрнәкләре күрсәтүдә генә түгел. “И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!/ Дөньяда күп нәрсә белдем син тагын тел аркылы”,— дигән шигырь юлларын укыганда ук “теле” белән “аркылы” рифмасының төгәл булмавы күзгә ташланса-ташланмаса да, шушы “Туган тел” шигыреннән тыш башка әсәрләрендә дә мондый “кытыршы” рифмалар очраса да, халкыбызда аларга карата тискәре караш бөтенләй юк. Хикмәт бит рифмада түгел, шигырьне аны рифма һәм ритм гына тудырмый. Борынгы грек шагыйрьләре әллә рифма белән

генә язганнар, дисезме, әллә инглиз әдибе бөек Уильям Шекспир (1564–1616) рифмага береккән булганмы? Хәер, Г.Тукайның поэтик осталыгын дәлилләүчеләр дә аның ише урыннарга бөтенләй “күз салмыйча” узу ягын карыйлар. Болай эш итүләре әлбәттә гадел дә түгел, чөнки матур өлешләрне генә күзәтеп, башкаларын атлап үтү хакыйкатьне ачарга ярдәм итми. Шулай да төгәл белергә тиешбез: шагыйрьнең бөеклеге камил рифмалы-ритмлы әсәрләр бирүендә генә түгел, бу бары тышкы як кына. Хикмәте — мәгънәләрендә. Әмма шигырь — әдәби сәнгать әсәре, аның һәммә яктан да килгәне, камил булганы яхшы, ягъни әдәби сәгате белән дә, әдәби мәгънәләре белән дә ул җанга үтеп керсен, йөрәк аша, кан тамырлары аша узсын, акылны-аңны нурландырсын. Без менә шуны чын шигырь дип атыйбыз, шуңа да шигырьләрдән мәгънә тирәнлеге һәм сәнгать югарылы эзлибез, шундый шигъриятне илаһи дип таныйбыз һәм аңа коллык итәбез. Андый әсәрләр шайтаный була алмыйлар. Әдәби иҗатта башка төрле принципларга таянып яшәүчеләрне һич тә аңламыйбыз, шулай да әсәрләрен кабул итәргә һәм аңлатырга тырышабыз: дөньяда яшәп тә дөньяныкыннан читтә калу, дөньяныкын артка тибәреп ташлау мәгънәсезлек ул, дибез.

Шәрык әдәбиятлары XII йөздән алып XIX гасыргача бер үк темаларны һәм формаларны, ритм-рифмаларны “чарлап” яшәгән. Әмма әдәбият үсешендәге торгынлыкның ни рәвешле булуына иң яхшы тарихи мисал да булып санала бу чорлар.

Шигырь өчен рифма һәм ритм (алар эчке яки тышкы булсыннар) бик тә мөкатдәс нәрсәләр дияргә тиешбез. Аның камиллеге шигырьне әдәби-сәнгати яктан шулкадәр нурландырып җибәрә ки, укучының күңеле мең төрле сөенечләргә тула. Рифманың да, ритмның да шигырь өчен хикмәтләре бар инде анысы!

Г.Тукай иҗаты турында сүз чыкканда һаман да бу сорау күңелгә килә: әмма хикмәт аларда, рифма-ритмда, әдәбият сәнгате ягында гынамы соң? Һәм, Тукайга соклануыбыз бер дә кимемичә, юк, аларда гына түгел, дибез. “Соң ни бар алайса?..— дип сорый шул ук “Татар шагыйрьләре” хезмәтендә Г.Ибраһимов та, һәм моңа бу рәвешле җавап бирә:

— Татарлык бар, татар рухын һәм тормышын һәйбәт гавамча, табигый итеп ясап чыгару бар...”[1]

Г.Тукай татар күңеле хис иткәнне, теләгәнне, акылы-зиһене омтылганны сурәтләп яза белүче әдип иде. Г.Ибраһимов та аның нәкъ менә халыкчан булуында бөеклеген күрә, таный, мактый. Г.Тукай татар халкының теләк-омтылышларын, өмет һәм хыялларын, дөньяны аңлавын һәм ни рәвешле кабул итәргә, бәяләргә, анда тормыш корырга кирәклеген тоеп алып, шуларны ачык итеп тасвирлап бирә алган әдип иде. Мондый итеп аңардан башка бер шагыйрь дә шушы кадәр халык рухына, җанына үтеп кереп, аңлап, белеп язмады. Г.Тукай әсәрләрендә үзе яшәгән XX йөз башында татар халкының әдәп-әхлакта кискен үзгәрешен тоеп, үзгәрергә теләвен сизеп, үзгәрә баруын аңлап һәм аңлатып сурәтләп бирде. Шуның өчен дә аның иҗатында һәртөрле искелек, иске карашлар кире кагылдылар. Шуның өчен дә ул безгә әхлак һәм әдәп тәрбиясе бирергә омтылучы мөгаллим дә, үгет-нәсыйхәт итүче хәлфә дә сыман яза белде. Шушылар аркасында аңарда мәгърифәтчелек аһәңнәрен, хәтта мәгърифәтчелекнең үзен, вәгазьчелекне күрделәр. Г.Тукайның милләт рухын үзгәртүгә алынуында “мөгаллимлек” итүен без “мәдрәсә исе килеп тора”, ягъни ул укытучыларының дәресләрдә сөйләгән сүзләрен колакларыбызга кабатлап сөйли дип тә билгеләргә мөмкинбез. Әйе, анысы да булгандыр? Әмма үз җаны аша уздырылган шул “мөгаллимлекләр” милли аң, милли әдәп, милли әхлак үсеше файдасына иделәр, бүген дә үз көчләрендә кала киләләр. Әйе, Г.Тукай чыннан да әхлак тәрбиясе бирергә алынучы мөгаллим дә, үгет-нәсыйхәт итүче хәлфә дә сыман яза белде. Г.Ибраһимов исә бу хакта болай дип белдерә: “Ул шуның белән авыз ачты, бисмилласында фикер бирде, кеше өйрәтте... Һәм һичбер вакыт ул бу чирдән, бу мөгаллимлек авыруыннан котыла алмады”[2].

Яңа, җәдиди, заманча әдәп-әхлак принципларын һәм идеалларын күтәреп чыгуны Г.Ибраһимовның шушы рәвешле

---

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.5. Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933) / Галимҗан Ибраһимов.— Б.133.

[2] Шунда ук.— Б.129.

кабул итүенең шәхси, әдипләргә хас аерым сәбәпләре булуы бер дә сер түгел. Ул әлегә саф сәнгатькә омтыла. Бу аның рухи теләге. Ул әдәби сәнгатьчелекне әдәби мәгънәләрдән әлегә өстен куя, аның эзләнүчән күңеле сәнгать биеклегендә оча, мәгънә тирәнлегенә дә чумарга тиешлеген акылы тоеп бетерми. Моның бәхәссез шулай булуы аның шул елларда язылучы "Яшь йөрәкләр" романында да ачык сиземләнеп тора. Әдипнең күңел хисләре төп геройларыннан Зыя образында тулысынча диярлек чагылыш таба.

Г.Тукайга үгет-нәсыйхәт бирү алымнарына да, сабак өйрәтү юлларына да барырга туры килгән. Заман рухы шуны таләп иткән. Дөрес, кайбер әдипләр үгет-нәсыйхәтчелеккә тәмам кереп батканда да ул аның белән артык мавыкмаган. Ничек кенә булмасын, халыкта яңа әдәп-әхлак принципларын барлыкка китереп, аларга алга таба үсәргә мөмкинлекләр ачып, бөек шагыйребез кешелек тарихында күп төрле талантларның кулыннан килмәгән олы һәм югары эшне башкарды, шуның белән заман үзгәрешенә, тарихи барышка көчле этәргеч бирде.

* * *

Г.Тукай үзенең әдәби иҗатын ярым-төрки, ярым-госманлы (төрек) теле белән башлап китә. Бу вакытта татар әдәбиятында, К.Насыйри юлыннан барып, Казан татарлары телен үрнәк итү мисаллары да, И.Гаспринскийча кырым-татарлары теленә авышуны өстен күргән әдәби әсәрләр дә җитәрлек иде. Г.Тукай сүз башлаганында ук бөтен Ислам дөньясы теленнән сөйләүгә алынды. "И каләм!" (1906) шигыре аның башлангыч чор иҗатының һәммә үзенчәлекләрен күрсәтеп тора, автор аларны ачыктан-ачык үзе үк тезмә рәвештә анда язып чыга.

Яңа, җәдиди чор татарда әдәбияты фәне, үзенең үсешендә XIX йөзнең икенче яртысыннан европачылыкка омтылып, 1914 нче елга объектив фикерләүдә тәнкыйди карашның өстенлекле булуын төшенерлек һәм корал итә алырлык дәрәҗәгә килде. Г.Тукайның бөеклеге шигъри фикер бирә алуында һәм шигъри нечкәлегендә генә булмыйча, киңрәк

масштаблы икәнлеген бәяләргә теләсәк, шул чордагы әдәби тәнкыйтьне дә яхшылап өйрәнергә тиешбез.

Г.Тукай Ислам дөньясының артталыгына хәйран иткән әдипләрнең беренчесе дә, соңгысы да булмады. Төрек, азербайҗан әдәбиятлары да XIX йөздә үк шушы юлда иделәр. И.Гаспринский 1883 нче елдан, Бакчасарайның бөек даһие буларак, “Тәрҗеман” газетасы аша халыкка шушы фикерне кабатлап килде. Г.Тукай да аларга иярде. XIX йөзнең соңгы чиреге шагыйре М.Акмулла (1831-1895) иҗаты белән алга чыгарылган шигъри фикер бирү агымы, Г.Тукай тарафыннан куәтләнелеп, XX гасырда тагын да киңәя барды. Фикер әйтү М.Гафури, Н.Думави, З.Бәшири кебек шул чорда исемнәре танылырга өлгергән әдипләрнең дә төп иҗат кредосы иде. Алар фикер сурәтен вәгазь бирүдән аерылгысыз итеп күрделәр. Г.Тукайга да шушы мөгаллимлек сыйфаты хас иде. Әмма ул, башкалардан аермалы буларак, яңа заманның, яңа әхлаклылыкның, гореф-гадәтләрнең җәмгыятьтә барлыкка килә баруын күрергә өлгерде. Моның сәбәбе әлбәттә демократик мөнәсәбәтләргә омтылыш белән бәйле иде.

XX йөз башында барлыкка килгән яңа татар демократик матбугаты прогрессив идеяләрне тормышка ашыруда зур ярдәм ролен үтәде. Н.Думави, З.Бәшири, хәтта С.Рәмиев тә “Бәянел-хак” кебек иске карашлы, кадими матбугат кочагында калган чорда Г.Тукайга башка шартлар тудырылды, башка мөмкинлекләр ачылды. Әдипнең формалашуында әлбәттә беренче адымнары зур этәргеч бирә. Монда уңай шартларның булуы гаять тә зур әһәмияткә ия. Г.Тукай “Әл-гасрел-җәдит” (“Яңа гасыр”), “Уклар” журналлары, “Фикер” газетасы мәйданнарында ирекле үсә, ныгый. Шуның өчен дә шушы Уральски татар вакытлы матбугатын тарихыбызда зур хөрмәт белән искә алырга тиешбез.

“И каләм!” шигыре янында шул ук 1906 нчы елда язылган “Ифтиракъ соңында”, “Шагыйрь һәм Һатиф”, “Мөридләр каберстанындин бер аваз”, “Пушкинә”, “Дәрдемәнд дәгелмием?”, Борадәранә нәсыйхәт”, “Хур кызына”, “Милләтә”, “Сөеклемнең кабер ташында”, “Шәкерт, яхуд Бер тәсадеф”, “Кем ул?”, “Мөхәммәдия” көе”, “Сөальләр” (басылу

вакыты —1907) кебек әсәрләрен искә алсак, алар һәммәсе дә, төрле-төрле эчтәлектә булуларына карамастан, юнәлешләре белән һаман да яңа әхлак, яңа гореф-гадәт, яңа тәртипләр төзүгә юнәлдерелгән иделәр. Г.Тукай бу эшен бер дә өзмичә, туры һәм дәлилле итеп алып бара белде.

“Гыйшык бу, йа!” шигыренә игътибар итик:

Бер гидае җан фидаем, гыйшкыңа пәрванаем;
Кәл, гүзәл, гарз-ит җәмалың: янаем, кил, янаем.

И Ходаем, вир гакыл, чөн хәбсә мәхбүс улмыям,
Бу кызың гыйшкында бән диванаем, диванаем.

*(Бер мескен җан корбаным, гыйшкыңа күбәләкмен,*
*Кил, гүзәл, күрсәт чибәрең: яныpмын, кил, яныpмын.*

*И Ходаем, бир акыл, чөнки зинданга тоткын буламын,*
*Бу кызның гыйшкында мин диванамын, диванамын.)*

Мәхәббәттә Г.Тукайның шигарь дәрәҗәсенә җиткерелгән шигъри юллары болар. Шул ук вакытта аларны яңа әхлак һәм гадәт омтылышлары сыйфатында да кабул итәргә тиешбез. Лирик герой үзен мәхәббәт утына очып баручы күбәләккә тиңли. Борынгы суфичыл әдәбияттан укучыга яхшы таныш, символик мәгънәгә ия образ бу. Әгәр дә урта гасырларда шагыйрьләр Аллаһыга мәхәббәтне шушы рәвешле символик тасвирласалар, суфи-диндарның җанын Аллаһы тәгалә нурына юнәлүче һәм шунда эреп югалучы сыйфатында күзалласалар, Г.Тукай җир кызына мәхәббәтне дә шул дәрәҗәдәге хисләр яктылыгында тасвирлый. Бүгенге укучы бу ике шигъри күзаллау, шигъри хисләр арасындагы аерманы тоймый да, аңламый да диярлек. Әмма XX йөз башы татар тормышы өчен бу аермалыкларның әһәмияте гаҗәеп зур. Лирик герой гүзәл кызның чибәрлекләрен күрергә тели, шулар ялкынында аның янасы килә. Шагыйрь Аллаһыга гыйшыкны инкарь итми, ул бу хакта сүз дә кузгатмый. Урта гасырлар әдипләре С.Сараи булсын, Котб, К.Сайади яки Мәҗлиси, яисә Мөхәммәдьяр бине Мәхмүт, башкасы булсын, Г.Хәям, Г.Нәваилар хакында искә алсак та шул ук хәл,— алар Аллаһыга гыйшык турында сөйли иделәр, Аллаһының үзеннән бу мәхәббәттә ярдәм, ягъни лаеклы җавап үтенергә база иделәр. Әмма Г.Тукайда мәсьәлә

башкачарак куела: аның лирик герое Аллаһы тәгаләдән, Җир йөзендәге кызга мәхәббәт тоткыны булырга теләмичә, бирешмәс өчен акыл бирүен үтенә, чөнки үзен гыйшык аркасында дивана хәлдә күрергә теләми. Бу инде моңа кадәр әдәбиятта яктыртылмаган хәл иде, яңа әхлак билгесе сыйфатын алды.

Суфичылык әдәбиятына хас шул ук образлар, символлар, метафоралар Г.Тукай иҗатында да кабатланып киләләр. Әмма алар башкача мөнәсәбәтләрдә, ягъни үзенчәлекле поэтик модус тәртибенә корылганнар. Шуның аркасында шигъри сүзнең эчтәлеге дә үзгәрә. Суфичыл мистицизм дөньяви карашлар белән алыштырыла. Г.Тукай мәхәббәткә яңача, заманча әдәп-әхлак карашларын тудыра: мәхәббәт хисләрендә һәркем янарга хаклы, әмма акылны югалтыр дәрәҗәгә, диваналыкка төшеп түгел. Бу юлда лирик геройга Ходай үзе ярдәмче!

Бу фикер татар күңеленә генә түгел, суфичылык карашлары тәэсирендә калган башка халыклар өчен дә зур яңалык булып тора. Әгәр дә моңа кадәр Аллаһыга мәхәббәттә дивана хәлгә җитү макталса, Г.Тукай гыйшыкның хисләрне андый дәрәҗәгә җиткерелүен өнәми. Без монда йөрәк эшләрендә яңа әдәп-әхлак кагыйдәсенең эчке һәм тышкы чикләре белән очрашабыз. Шагыйрь аны Ходай бирергә тиешле саналган акылда күрә. Әйе, дини күзаллаулар белән кысаланган шигырь бу, борынгыларны кабатлыйдыр сыман тойгы калдыра, әмма принципиаль яңа, дөньяви әхлак һәм әдәп юнәлешендә тудырылган.

“Мөридләр каберстаныңдин бер аваз” шигырендә дә Г.Тукай яңа дөньяви әхлак һәм гадәтләрне эзләү эшен дәвам иттерә һәм болай ди:

Милләти вәйран идән ишан икәндер, белмәдем;
Ул ишанлар милләтә дошман икәндер, белмәдем.

Милләти идһам идән, игъдам идән шунлар имеш,
Анлари инкарь идән зи шан икәндер, белмәдем.

*(Милләтне харап иткән ишан икәндер, белмәдем,*
*Ул ишаннар милләткә дошман икәндер, белмәдем.*

*Милләтне тузан иткән, харап иткән шулар имеш,*
*Аларны инкарь иткән намуслы икәндер, белмәдем.)*

Шигырь XIII йөз шагыйрьләре Ә.Яссәви һәм С.Бакыргани хикмәтләренә хас вәзен, кафияләү принципларында язылган. Хәтта фикерләр дә шул килеш калдырылган, әмма эчтәлеге бөтенләй башкача. Суфи шагыйрьләрдә замана, Җир тормышы кешене, халыкны, рухны юкка чыгаручы, җимерүче итеп бирелсә, Г.Тукай монда ишаннарны, ягъни суфиларның үзләрен гаепли. Әлбәттә милләт һәм өммәт сүзләренең мәгънәдә берлелеге дә исәпкә алынган. Г.Тукайдагы милләт төшенчәсе әлегә шул ук мөселман өммәте булып кала бирә, әмма ул инде татар милләте буларак та кабул ителә. Бу рәвешле милләт сүзен концепт чикләрендә алу шагыйрьгә фикерен үткен һәм үтемле итәргә мөмкинлек биргән. Г.Тукай динне түгел, диндар суфичылыкны милләтне артта калдыруда гаепли, урта гасырчылык белән бәйле карашларны инкарь итүне намуслылык билгесе буларак бәяли. Бу әсәрдә яңа әхлак һәм әдәп принциплары шушы рәвешле ачыктан-ачык бәян ителәләр.

Әгәр дә без Г.Тукайның дөньяны үзгәртүен, яңа әхлак һәм әдәп белән бәйле карашларын тәкъдим итүен суфичылыкны кире кагуга бәйләп кенә аңлатсак, бу бер яклы һәм чикләнгән фикерләмәләрнең нәтиҗәсе булыр иде. Ул никадәр генә кискен бәяләр-бәяләмәләр биреп эш итмәсен, иске тәртипләрне тулысынча инкарь итү юлыннан гына барган дия алмыйбыз. Аның модернизмы урта гасырларда барлыкка китерелгән принципларны яңартуга корылып, шигъри вәзен һәм кяфияләрдә генә түгел, фикер сөреше юнәлешендә дә аларны кабатлый иде. Әмма бу кабатлану хакыйкатьне күктән җиргә төшерү, абстракт рухтан конкрет тормышка кайтару юнәлешендә барды. Шул ук урта гасырлар әдипләре Ә.Яссәви, С.Бакыргани, яисә Икани, Раҗи һәм Газзәзиләрнең фикерен куәтләгән рәвештә аның сүзләре яңгыраш алып, яңа тормыш реальлеге белән бәйләнешкә кертелде. Бу яктан караганда, бөтен борынгы һәм урта гасырлар (ул чактагы татар укучысына таныш булган дәрәҗәдәгесе) Г.Тукай белән фикердәш һәм сөхбәттәш булып татар укучысының колагына

һәм күңеленә барып җиттеләр. Ни өчен колагына? Чөнки аны күңеле белән кабул итмәүчеләр дә арада бар иде.

“Дәрдемәнд дәгелмием?” шигыре алар өчен махсус язылган сыман аңлашыла:

Нәйләем, аслым, әсасем дәрдә идмеш ибтина?
Та әзәлдән дәрде шәүка мөбтәнаем, нәйләем?

Тәңре гыйшкында шәһадәт итсәләр дәр Гәрбәла,
Бән шәһидем дәр мәхәббәт, дәр бәлаем, нәйләем?

*(Нишлим соң, асылым, нигезем дәрткә бәйле төзелгән,*
*Яратылыштан көчле дәрткә дучармын, нәрсә эшлим?*

*Тәңре гыйшкында ант итсәләр Гәрбәлада,*
*Мин шәһитмен мәхәббәттә, бәладә, нәрсә эшлим?)*

Г.Тукай шигырьнең исеменә үк үзен дәрт иясе, ягъни Аллаһыга гыйшык тотучы суфи-диндар кеше белән тәңгәл куя. Әсәрне шагыйрь Дәрдемәнд (Закир Рәмиев) белән бәйләү әлбәттә урынсыз. Монда аның катнашы юк. Әмма дә бу әсәр Дәрдемәнднең күңеленә хуш килми калмагандыр?

Чөнки Дәрдемәнд шигъриятендә көчле мистицизм бар, ул аңарда дини-суфичыл әдәбият тәэсиреннән шулай. Ә Г.Тукай суфичылыкны инкарь итә. Аңа мистик күзаллаулар һәм мистицизм кыргыйлык булып тоелган. Ул аларда хәтта шигърилек тә күрмәгән. Шуның аркасында иҗатына корылык үтеп кергән. Мистицизм, ни генә дисәк тә, ул эле үлән суты кебек, кешенең тамырлары буйлап хәрәкәт итүче яшәеш, тереклек билгесе сыман да түгелме?

Г.Тукай үзенең күңеле-рухы дәрт белән тәмам бәйләнештә торуын, ягъни асылының дәрткә төрелүенең сәбәбен мәңгелек чикләрендә җаны яратылган чакларда ук Аллаһының биргән тәкъдиреннән күрә. Шунда ук Кирбәланы исенә төшерә, моның белән Ислам дөньясында фән-гыйлем, мәгърифәтнең чәчәк аткан үзәкләреннән берсе — урта гасырларның Испания Андалузиясен искә ала. Бу рәвешле Аллаһы тәгаләгә мәхәббәттә ант итүне, ягъни иман китерүне иске чорлар өчен җиңел, сөенеч булуын белдерсә, яңа дәвердә, ягъни наданлык, артталык дәверендә мәхәббәттә һәм бәладә гуаһлык итәргә мәҗбүр икән лирик герой. Шагыйрь монда поэтик модусны

сурәтләрне тәңгәл кую ярдәмендә төзи. Г.Тукай бу шигырьдә дә шәһадәт һәм шәһит сүзләрен концепт чикләрендә ала, гарәп теленнән кергән ул сүзләр төрле эчтәлекләрдә яңгыратыла.

Шагыйрьгә болай эшләү яңа әхлакый принципларны билгеләү өчен кирәк булган. Г.Тукай Ислам дөньясының куәтле, алга киткән дәверен үз чоры белән янәшә куеп, аермалыкларны хис-тойгыларны кузгатып ача һәм яшәештәге гореф-гадәт принципларының да башкача булырга тиешлеген укучысына сиздереп үтә. Дөрес, Г.Тукайның бу рәвешле белдерүе "Тәрҗеман" газетасы мәкаләләрен, М.Акъегетнең "Әлгасрел-җәдит" журналында басылып чыккан "Аврупа мәдәнияте" күләмле хезмәтен белүеннән үк килә, ул заманның татар укучысы колагына бер дә ят булып ишетелмәве дә аларга да бәйле.

Һәм менә шул җептәге "Япониянe мөселман идәчәк голяма нәрәдә?" шигыре. Бу әсәре Г.Тукайның дин мәсьәләсендәге карашларын тагын да ачыграк төшенергә ярдәм итә:

Сез, и чалмалылар, безне буңа дик итдеңез игъфал,
Вә тәхсыйли дә тәгълими сәрасәр итдеңез иһмаль.

Гасырлар кичде мәрзая өфермәк лә, төкермәк лә;
Язып ялган догаларны вә яхуд ачтыңыз сез фал...

Диләр: — Исламә кермәк хәзрәти солтаны Микадо;
Сези дәгъват идәр дәргяһына — тиз варыңыз фил-халь!..

Такыр баш улмая тәклиф идәрмисез янә бунда?
Мыеклар шөйлә кыркылсын, ки улсын юклыга мәйяль?..

Йитәр, инсаф идең, артык кәрәк инсаф, хәясызлар!
Японлар да чапан кисен диеп куптармаңыз җәнҗал!

*(Сез, и чапанлылар, безне моңа кадәр надан-белемсез иттегез,*
*Һәм гыйлем табуда һәм алуда башыбызны буш иттегез.*

*Гасырлар үтте авыруны өшкерү белән, төкерү белән,*
*Язып ялган догаларны һәм дә ачтыгыз сез фал...*

*Әйтәләр: — Ислам динен алмакчы хәзрәт солтан Микадо,*
*Сезне чакырыр каршысына — тиз барыгыз шул хәл!..*

*Такыр баш булырга кушарсызмы тагын монда?*
*Мыеклар шулай кыркылсын — юк кебеккә якын ителсен?..*

*Җитәр, инсафлы булыгыз, артыгы белән инсаф кирәк, оятсызлар!*
*Японнар да чапан кисен дип куптармагыз җәнҗал!)*

Сүз бары тик дин тарату турында гына бара һәм Г.Тукай исламчылыкка каршы булган дигән фикер чыгару шулай ук чикләнгәнлектән, шигырьне аңламаудан килер иде. Хәер, фәндә мондый карашлар өстенлек алган чорлар да булды. Татар акылы аларны совет хакимияте заманнарында бик сөенеп кабул итә иде.

"Японияне мөселман идәчәк голяма нәрәдә?" шигыре Г.Тукайның Ислам дөньясына бәйле, аның бигрәк тә прогресста-үсештә артта калуына ачынып язган әсәрләреннән берсе булды. Тарихи әһәмияте бүгенге көндә дә югалмады.

Шулай итеп, "И каләм!" шигыре белән Г.Тукай яңа әхлак, гадәт, әдәп принципларын татар тормышында урнаштыру юнәлешендә эш башлап, идея-идеалларын әсәреннән-әсәренә җәелдерә һәм фикерләмәләрендә ныгыта барды. Иҗатының шушы башлангыч чорында шагыйрь бөтен-бар Ислам дөньясы исеменнән сөйләде, әдәби телне дә шуңа күрә, Г.Ибраһимов терминологиясен файдаланып әйтсәк, "гомуми әдәби лисан" кысаларында тотты.

Бу вакытта ул Җаек буендагы Уральски шәһәрендә яши иде. Яшьлегендә Мисырның Әл-Әзһәр университетын тәмамлаган киң һәм югары белемле Мотыйгулла хәзрәт Төхфәтуллин һәм аның улы, шулай ук Әл-Әзһәрдә югары университет белемле белгеч-мөгаллим, татар һәм рус матбугатында баш мөхәррир, язучы, журналист, шагыйрь Камил Мотыйгый Г.Тукайның укытучылары булдылар. Г.Тукайның үз әсәрләрендә аларның фикерләрен халыкка җиткерүе дә сер түгел. Ул бу яктан, ягъни яңа әхлак һәм әдәп принципларын барлыкка китерү һәм халыкта ныгыту юлында әлбәттә ялгызы гына булмады. Шигъриятендә, фикере үсешендә даимилек күрсәтеп, борынгыдан килгән әдәби традицияләргә таянып, каршылыклы иҗтимагый шартлар

эчендә кайнап, Г.Тукай татарның рухи-мәдәни тормышында һәм яшәешендә яңа дәверне башлап җибәрде.

Аның иҗатының беренче, башлангыч чоры “Китмибез!” (1907) шигыре белән тәмамланды. Бу әсәре Г.Тукайның Ислам дөньясына хас карашлар системасы эчендә яшәвеннән һәм иҗат итүеннән Русия шартларына күчүен күрсәтте.

Дөрес, “Государственная думага” (1906) шигырендә үк ул ил эчендәге иҗтимагый-сәяси мәсьәләләргә якын килә башлаган иде. “Китмибез!” шигыре Русия һәм милләтләрнең андагы яшәеше мәсьәләсенә карата Г.Тукайның карашлары төгәл формалашып җитүгә бәйле, аларны ачык күрсәтүче төп әсәрләренең берсе булды. Ул һәр халыкның үз тарихи үсеше барлыгын, аны үзгәртү мөмкин түгеллеген, һәм яшәүдә, һәм белем алуда хакларының шактый икәнлеген ачыктан-ачык белдереп чыгыш ясады. Моңа кадәр татар халкы Русия шартларында аерымланган хәлдә тормыш коручы буларак күзалланса, “Китмибез!” шигыре бу яктан да гадәти карашларны үзгәртте. Русиянең уртак ватан буларак күзаллануы “Олугъ юбилей мөнәсәбәте белән халык өмидләре”ндә (1913) тагын да үстерелде, тәмамланган, бербөтенлек төсен алды. Әмма ул әсәр аның иҗаты чәчәк аткан Казан чорына карый.

## Г.ТУКАЙ “БЕРДӘМЛЕК ҺӘМ ТӘРӘККЫЯТЬ КОМИТЕТЫ”НДА

Уральски чоры Г.Тукайның шагыйрь һәм иҗтимагый фикер иясе буларак танылуында аерым урынны алып тора. Монда “Мотыйгыя мәдрәсәсе”нең, бигрәк тә Камил Мотыйгый-Төхфәтуллинның роленә аерым тукталып үтү сорала. 1903 елда Каһирәдән Әл-Әзһәр университетын тәмамлап кайткан К.Мотыйгый, “Мотыйгыя” мәдрәсәсендә укыту белән генә чикләнмичә, иҗтимагый эшләрен дә киң

җәелдереп җибәрә. Әдәбият түгәрәкләре оештыра, кулъязма “Әл-Мәгариф” газетасын даими чыгаруны җайга сала.

Сакланып калган нөсхәләреннән күренгәнчә, бу газета асылы белән “госманлы теле”нчәрәк мәйданга куела. Моның сәбәбе бик гади булган: К.Мотыйгый Әл-Әзһәрдән госманлычага ихластан күңелен салган, шуның белән галимлеккә остарган кеше буларак кайткан. Ул анда начар укымаган. Фәннәрне бик тиз төшенеп, курсларны тиз арада узып, 1900–1903 еллар эчендә тәмам галим буларак җитлегеп өлгерә. Аның этисе, мәсәлән, Мотыйгулла Төхфәтуллин исә үз заманында анда 10 ел буена белем алган. Камилгә ул кадәр үк вакыт та кирәк булмаган.

К.Мотыйгый, Уральски шәһәренә кайтып, “Мотыйгыя”да укыта башлауга, шәһәр халкы тормышыннан бер-бер артлы берничә әсәр дә язып өлгертә. Аларны цензура комитетына юллый. Байлар тормышын көлкегә алып тәнкыйтьләүгә багышлаган ул әсәрләренә (асылда аларны тезмә һәм нәсер алымнары белән иҗат итә) басылырга рөхсәт тә ителә, алар дөнья да күрә торалар. К.Мотыйгый шулай төрле яклап танылу ала бара.

Аның иң әһәмиятле эшләреннән берсе — “Бердәмлек вә тәрәккыять комтеты”н оештыруында. “Әл-Мәгариф” газетасы һәм “Мотыйгыя”дагы әдәбият түгәрәкләре шушы комитетның Уральскидагы эшчәнлегенең нәтиҗәләре буларак та күз алдына килә. Аның эшендә актив катнашкан Г.Тукай исә К.Мотыйгыйның шәхси секретаре ролен башкара. Кулъязма газетаның нөсхәләрен күчерүдә, аны халыкка таратуда Г.Тукайның ролен аз гына да киметергә мөмкин түгел.

“Бердәмлек һәм тәрәккыять комитеты” шәһәрдә мөселманнарны мәгърифәт һәм мәдәни үсеш өчен туплау, конкрет максатлар белән хәрәкәт итүгә юнәлтү белән шөгыльләнә. Әлбәттә каршылыклар аз булмый. Татар тарихына “җәдит-кадим тартышы” буларак кереп калган, шул кысаларда гына аңлатылган иҗтимагый хәрәкәтләрнең кайсылары асыллары белән төрекләрдәге иҗтимагый-фикри алгарышларга барып тоташуы мәсьәләсе дә фәнебездә әлегә игътибардан читтә кала кебек.

К.Мотыйгый оештырган комитет һәм исеме, һәм җисеме белән “Яшь төрекләр” хәрәкәтенең 1889 нче елдан яшәп килгән “Бердәмлек һәм тәрәккыять комитеты” эшчәнлегенең бер күренеше сыйфатында бәяләнә ала. Алар сәяси, милли, иҗтимагый һәм мәдәни платформалары белән дә туры киләләр. Моны ниндидер бер вакытлы мавыгу, яисә “Яшь төрекләр” хәрәкәтен татар тормышына күчерергә омтылыш буларак кына бәяләргә ярамый. К.Мотыйгыйның, татар тормышы үзенчәлекләрен аңлап, эшен байларга, иске карашларга каршы юнәлдерүенең дә тарихи, сәяси, мәдәни әһәмияте аз булмый.

“Яшь төрекләр” үзләре Төркиядә милли иҗтимагый-сәяси хәрәкәтләрнең башында XIX йөзнең ахырларыннан тора башлыйлар. Алар “Яңа госманнар” сәяси-мәдәни оешмасына алмашка киләләр. Төп максат итеп илдәге монархияне юк итүне куялар. “Яңа госманнар” төрек тормышын европалаштыруда төп эшне башкаралар, илдә конституцион җәмгыять оештыралар, парламент төзеп, буржуазиягә үсеш мөмкинлекләре тудыралар да. Әмма аларның уңышлары озакка бармый. Башлаган эшләре туктатыла. Җитәкчеләре шагыйрь һәм язучы, актив җәмәгать эшлеклесе, журналист Намык Кемал (1840–1888) кулга алына. Югыйсә солтан булып Габдел-Хәмит II (1876–1909) тәхеткә “Яшь госманнар” ярдәме белән утырган була. Ул солтанлык тәхетендә бер ел торырга да өлгерми, “Яшь төрекләр”нең илдә солтан идарәсен юк итәргә җыенуларын ачык төшенеп, аларны эзәрлекли башлый. Үз фәрманы белән Н.Кемалны зинданга салдыра, илдә яңа идарә юк ителә, тирания урнаша һәм “золым дәвере” башланып китә. Солтан Габдел-Хәмит II төрек байлыгына кызыккан чит илләрнең тыкшынуыннан мәмләкәтне коткаруның башка юлын күрми. Әмма бу, аның сайлаган юлы, шулай ук уңышлы булмый. 1882 нче елда Франция Тунисны яулый, 1882 нче елда Бөекбритания Мисырны басып ала. Болар гына да түгел, чит илләрнең тыкшынуы Төркия казнасына, гаскәрләренә үтеп керә. Шушы вакытта Габдел-Хәмит II дини дошманлык идеясен таратуга зур ышаныч баглый башлый. Бу юлда эш җәелдерелеп, халыкларга каршы

халыклар куела. Җәмгыятьтә оешкан милли прогрессив көчләрне юка чыгару, сәяси хәрәкәтләрне бастыру һәм таркату, европалашуга каршы сәяси, иҗтимагый, икътисади, әхлакый һәм башка һәртөрле көчләрне туплау эше оештырыла. Милләтчелек һәм мөселманчылык идеяләре солтан тарафыннан иң уңай һәм үз сәясәтен ныгытуда яраклы дип табылалар.

Болар вакытлы күренеш кебек күзалланырга тиеш түгелләр. Әмма "Золым дәвере" төрекләрнең аңлы милли-мәдәни көчләренә зур зыян сала. Әдәбиятта төп геройның "үз эчке дөньясына качуы" тасвирлана башлый. Габделхак Хәмит Тархан (1852–1937), Риҗаизадә Әкрәм (1847–1913) романтик хисләр дөньясына бирелергә мәҗбүр булалар. Әмма европачылык һәм Европа әдипләренең тәэсирләреннән дә читләшмиләр. В.Гюго, А.Ламартин, А.Мюссе кебек романтик шагыйрьләрнең шигъри мотивлары төрек әдәбиятында актив чагылыш таба.

Алдынгы төрек әдипләре "Сәрвәти-фөнүн" журналы тирәсенә тупланалар. Төрек әдәбиятында заманча "яңа әдәбият" шул шартларда формалаша. Төрек укучысына Э.Золя, Г.Мопассан, бертуган Гонкурлар, Стендаль, О.Бальзак иҗатлары киң пропагандалана. Төрек шагыйре Тәүфыйк Фикрәт (1867–1917) иҗаты активлашып китә. Ул гади халыкның хис-тойгыларын ихлас буларак сурәтләүне, гражданлык пафосларында иҗат итүне төп юнәлеше итеп куя. Җәдитчелек юнәлешен тоткан яңа тип татар әдәбияты да шушы ук төрек әдипләре әсәрләре йогынтысын кичерми калмаган.

Бу яктан караганда, К.Мотыйгыйның әсәрләре дә тулы канлы гражданлык хисләренә бай булулары белән үзләренә укучыны җәлеп итәләр. Т.Фикрәт һәм К.Мотыйгый иҗатлары арасында охшаш һәм уртак мотивларны табуы авыр түгел. XIX йөзнең икенче яртысында, бигрәк тә соңгы чирегендә төрек прозасында үзәккә чыгарылган "кечкенә кеше язмышын" "тулы канлы" итеп сурәтләү соңрак та татар әдәбияты үсешенә шактый зур этәргеч биргән. Төрек әдипләре мәгърифәт һәм тәрәккыять идеалларын югары күтәрәләр, әсәрләрен

иҗтимагый эчтәлеккә коралар, психологизмга зур игътибар бирәләр, француз натуралистлары йогынтысында язалар. Тормыш материалын әдәби әсәр вакыйгасына әверелдерү алымнарын К.Мотыйгый татар әдәбиятында уңышлы башкарган, Г.Тукайга да аның иҗат манералары тәэсир итми калмаган.

“Яңа госманнар” эшен дәвам иттерүче “яшь төрекләр” хәрәкәте вәкилләренең ахырда милләтчелеккә бирелеп китүләре, сәяси мәсьәләләрне милли мәнфәгать кысаларына кайтарып калдырулары XX йөз башы татар әдәпләрен берникадәр аптыраашта калдырган, билгеле. Хәер, анысы башка мәсьәлә.

Г.Тукайның Уральски чорында язылган мәкалә-фельетоннарында “яшь төрекләр”нең фикри тәэсирләре нык сизелә. Аның “Кавказ тормышыннан” дип күрсәтелгән “Ай, бат!” (1907) хикәясе дә моны ачык күрсәтеп тора.

К.Мотыйгый оештырган Комитетның алга таба булган язмышы аерым әһәмияткә ия. Кульязма газетадан кульязма “Әл-гасрел-җәдит” (“Яңа гасыр”) журналына, аннары басма журналга күчеп, алар Рәсәйнең эчке сәяси-иҗтимагый хәрәкәтләренә кушылып китәләр. Сайлауларда эре буржуаз партияләрнең мәнфәгатьләрен яклаучылар буларак та үзләрен күрсәтәләр К.Мотыйгый оештырган “Әл-гасрел-җәдит” журналы һәм “Фикер” газетасы.

Г.Тукайның гражданлык пафосы белән сугарылган беренче шигырьләре һәм мәкаләләре дә шул матбугат органнарында дөнья күрә. Шунысы мактауга лаек: ул илдә, җәмгыятьтә, татар эчендә гаделлек урнаштыру юлларын эзләвен, сәяси дөрес юлны ачыкларга омтылышын туктатмый. Бу яктан аның аңы бик яшьли ачыла. Монда К.Мотыйгыйның һәм ул оештырган Комитетның роле зур булган, билгеле.

1905 нче елда алар Русиянең әүвәле конституцион-демократия тарафдарларына ияреп китәләр, ә 1906 нчы елның урталарыннан алдынгы революцион партияләр ягына тартылалар. Бу инде К.Мотыйгыйның да, Г.Тукайның да “яшь төрекләр” платформасыннан китү юлына керүләре хакында сөйли торган фактлар буларак бәяләнергә тиеш. Әмма ул

процесс та күп төрле фикри, иҗтимагый, сәяси, әхлакый эзләнүләр белән озатылып барылган. Халык алдында, җәмгыять каршында олы җаваплылык тоеп эш итүләре аларның әдәби-журналистик эшчәнлегендә, мәкаләләрендә, язган әсәрләрендә чагылыш тапкан. Бу яктан Г.Тукай иҗаты шактый өйрәнелгән, К.Мотыйгыйның әсәрләре бүгенге җәмәгатьчелектән әлегә читтә калып килә. Бу юлда эшлиселәребез бар әле.

*2012.*

## "Г.ТУКАЙ ЖУРНАЛИЗМЫ"

Каләм ияләре исемнәре белән бәйле андый термин, ягъни кемнең дә булса "журнализмы" дигән төшенчә әлегә фәнебездә юк. Журналистикада "журнализм" термины файдаланыла, анысы. Ул мәдәни тарихта Америка матбугаты белән бәйле барлыкка килгән.

Журналистика тарихы "журнализм"ны XIX гасырның соңгы чирегенә нисбәт итә. Әмма вакыйгалары шул ук йөзнең беренче яртысыннан башлана. 1833 нче елда Бенҗәмин Дэй (Америка журналисты) 1 цент бәяле «The Sun» газетасы чыгара башлый. Төп игътибар сенсацияләргә юнәлтелә: җинаятьләрне ачу, скандаллар һәм мистификация. Газетаны, ягъни матбугат органнарын ул шушы яңалыклары белән табышлы, кызыклы һәм, иң мөһиме, иҗтимагый яктан әһәмиятле итеп оештыра, халыкка чыгара башлый.

Бездә дә, татарда да, газеталарны дүртенче хөкүмәт органы ("четвертая власть") дип атау гадәте бар. Әмма һәр газета да андый булып өлгереп җитә алмый. Хәтта хөкүмәт тарафыннан чыгарылучы, матди яктан тәэмин ителгән матбугат чаралары да "дүртенче хөкүмәт" дәрәҗәсенә ирешә алмый интегәләр. Аларга анда юл ябылган. Юк, моны кемдер махсус, өстән кушып алай эшләми, хәер, бәлки эшли дә алмыйдыр, гаеп журналистларының, җитәкчелегенең үзендә. Моның асыл сәбәпләрен әлбәттә аңлый һәм төшенә белергә кирәк.

1907 нче елның 30 нчы декабрендә Казаннан Уральскига, дусты Габдулла Кариевкә язган хатында Г.Тукай болай дип белдерә: “Әйе, Уральскида берничә “сабый балалар” тарафыннан надан вә җаһиланә чыгарылган “Яңа тормыш” монда килеп тора. “Мәрхүмнәр!”— дим дә куям”[1]. “Үле туган” матбугат органы хакында сүз бара, әлбәттә. “Яңа тормыш”ны, югыйсә, үзен данлыклы журналист буларак таныткан һәм белдереп йөргән Камил Мотыйгый Төхфәтуллин, “Фикер” газетасының эшен дәвам иттереп, нәкъ шул елда бастырып чыгара, анда хәтта революцион эчтәлектәге мәкаләләр дә бирә. Әмма “Фикер” газетасының данын “Яңа тормыш” уза да, алыштыра да алмый. Тиражсыз калган матбугат органы яшәүдән туктый.

Ни өчен “Яңа тормыш” “Фикер” мәртәбәсенә ирешми, хикмәте нәрсәдә соң? Нәрсәгә Г.Тукай шушы газетаның журналистларын “сабый балалар” һәм “мәрхүмнәр” дип атый? “Яңа тормыш” та нигәдер “надан һәм җаһиланә чыгарылган” (монда “җаһиланә” сүзе татар халкында кулланылган “ялагай” һәм “томана” дигән мәгънәләрдә килә) газета буларак искәртелә?

Тукай тугыры һәм туры сүзле. Бу яктан бәхәс итеп булмый. Әмма аңарда ихтыяри булырга чакыру гына түгел, бәлки акыл, аң, белем тантанасы белән бергә матбугатның нинди иҗтимагый дәрәҗә тотарга тиешлеген аңлау һәм сиземләү сөйли. Тукай тупас түгел, ул хакыйкатьнең үзе кебек үк ачык, аңлаешлы. Бүгенге көндәге сыман, XX йөз башында да татар матбугат чараларының күбесе “үле туганнар”, зәгыйфь булганнар һәм шуңа күрә дә елдан-елларга ныгый, киңәя, көч ала барып яши алмаганнар.

Бөтен хикмәт тә тираж мәсьәләсенә килеп төртелә. Йә кемнең инде өенә макулатура алдыртып ятасы килсен, җитмәсә — акча түләп?

Моны 1833 нче елда ук, инде искәрткәнебезчә, Америка журналисты Бенҗәмин Дэй төшенеп өлгерә. Ә 1878 нче елда

[1] Тукай Г. Әсәрләр: Биш томда.— Т.5. Истәлекләр. Юлъязмалар. Хатлар. Мәсәлләр һәм балалар өчен хикәяләр (1902–1913).— Б.81.

дөньяда “яңа журнализм”, яки, икенче төрле аталышы белән әйтсәк — “эффектлы журнализм” барлыкка килә. Аның төп эш формасы һәм эчтәлеге төрле кампанияләр оештырудан, сенсация һәм агрессия юнәлешен мәкаләләрнең стиле итеп алудан гыйбарәт була. Вакыйгаларны мөмкин кадәр сюжетка корып бирергә омтылыш ягы да урынлы, укучыда андый язмалар чыннан да зур кызыксыну уята.

Тарихыбызга карасак, 1906 нчы елның башында Г.Тукай Уральскидагы К.Мотыйгыйның арендага алган “Тәрәккый” (“Тәрәккыйййать” — ул шушы рәвешле гүяки ике төрле исемдә, ягъни кыскартып әйтү һәм тулы исеме белән атау шәкелләрендә йөртелгән) типографиясендә хәреф җыючылыктан “Фикер” газетасына корректор, аннары мөхәррир-журналист итеп күчерелә. Моңа кадәр Бәхетҗан Каратаев җитәкләгән казакъ кадетларына хезмәт итүне максат итеп алга чыгарган, Дәүләт думасына ышаныч баглаган, аң-белем һәм мәгърифәт тарату эшенә кыйбласын төбәгән, эчтәлектә буш газета Г.Тукай аркасында тиз арада үзгәрә башлый. Әмма Г.Тукайның журналист буларак эшчәнлеге 1906 нчы елның июнь аеннан гына ирекле көч ала. Ул аңа кадәр асылда шагыйрь һәм хикәяче ролен башкара.

Шул 1906 нчы елның апрель аенда газетада “Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?” [1] дип аталган әһәмиятле мәкалә басыла. Тукайчылардан тәүдә Ф.-С.Казанлыдан башлап, ягъни «Г.Тукай әсәрләре» өчтомлыгыннан (1929–1931) алып бүгенге көнгә кадәр, бу мәкалә шиксез рәвештә Г.Тукайга нисбәт ителә. Хәер, ул мәсьәләдә бәхәс итү урынсыз булыр. Чөнки ап-ачык күренеп тора: бу мәкалә чыннан да Г.Тукай каләме белән язылган, аңардан әдиплек мәгънәләре генә түгел, хәтта “Тукай журнализмы”ның (дөресрәге, әлегә журналист буларак та тавышы ачылып килүче Г.Тукайның) барлык үзенчәлекләре сиземләнә.

Иң тәүдә игътибар ителергә тиешле хикмәте — телендә, стилендә, аның очлы, үткен булуында, эффектында. Икенчедән, фикерләр мәкаләдә төгәл атап әйтелеп бирелгән, кискен куелганнар. Ике төрле уйларга урын калдырылмаган.

[1] Фикер.— 1906.— 17 апрель.

Өченчедән, риторик сорау белән укучыга мөрәҗәгать итү ысулы файдаланылган. Дүртенчедән, нишләргә кирәклеге бәхәс ителмичә, ачык күзаллату юлы белән, төп фикер рәвешендә төшендерелгән. Бишенчедән, карар бирү, фәрман итү стиле файдаланылган.

Әлбәттә мондый үзенчәлекле билгеләрен тагын да күбрәк ачыклап, аларны киңәйтергә дә мөмкин, әмма вакланып кына китәчәкләр. Шунлыктан әлеге биш сыйфатын аерып билгеләү белән чикләнергә тиешбез. Тик шунысын онытмаска кирәк: бу мәкаләсе “Тукай журнализмы”ның башы, тәүге адымнары гына. Алга таба Г.Тукай каләме аны тагын да шомарта, тагын да эффектлырак ясый. Әмма язу — бер хәл, ә язганны ишеттерә алу — икенче. Моның өчен матбугатның да тиражлы булуы шарт.

Ул вакыттагы Уральски шәһәре кебек татарның, русның, казакъның провинциясендә гомум көндәлек (хәтта атналык яисә көнаралаш чыгарылучы аталсын) татар матбугаты оештыру өчен хәбәр табу, аны халыкка укырлык кызыклы итү бик җиңел эш сыман күз алдына килми. Тормыш иске рәвештә бара. Вакыт акрын кыймылдый, вакыйгалар бер-берсеннән әллә ни аерылып та тормыйлар: анда берәү өйләнгән, монда кемнәрдер аерылышканнар, кайсы кем кайсына нидер әйткән кебек яңалыклар белән матбугат чәчәк ата алмый, билгеле. Журналист кеше “Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?” дип лаф орырга, уфтанырга мәҗбүр.

Һәм менә халыкны кузгату өчен төрледән-төрле чаралар, җыелышлар, бәхәсле утырышлар кирәклеген Г.Тукай тоеп, аңлап алган. Мондый иҗтимагый чараларны кем оештыра ала? Әлбәттә К.Мотыйгый, аның дәрәҗәсе дә зур, сүз күтәрү ягыннан да ул аерылып тора, “серкәсенә су төшерә” торганнардан түгел. “Дәрел-мөгаллимин”, ягъни укытучылар әзерли торган яңа тип югары уку йортлары ачу, җәдитчелек, дин, яшәеш мәсьәләләре, китапханә оештыру, “Җәмгыяте-хәйрия” булдыру, татарларның үз мәдәни үсешләре өчен кирәкле программаларны төзү һәм аларны тормышка ашыручы комитетларны, идарәләрне сайлау һәм башка мәсьәләләр бер-бер артлы кузгатылып, болар белән бәйле

эшләрне, җыелышларны уздыруны К.Мотыйгый үз өстенә алып, шулар аша “Тукай журнализмы”ның эффектлы эшләвен тәэмин итә башлый. Әмма ул моны үзе аңлап-төшенеп бетердеме икән? Әллә Г.Тукайның ихтыярына буйсынганын сизенми калдымы?

Уральскида иҗтимагый мәдәни хәрәкәт тәгәрмәчләре акрын кузгалалар, әмма Г.Тукайның эффектлы мәкаләләре аларга җан өрә (юккамы XX йөз башында татарның беренче эстрада җырчыларыннан, театр артистларыннан, һәртөрле сәнгатькәрләреннән төп вәкилләре Уральски шәһәреннән?); җыелышларда сөйләнгән берәүләрнең сүзләре көлкегә алына, икенчеләре — хуплана. Г.Тукай әлбәттә үзен дөреслек ялчысы итеп күрә, әмма аның каләме шәһәрнең өлкән һәм авторитетлы муллаларын, имамнарын, байларын, сәүдәгәр-миллионерларын хәтта мыскыллау объектына әверелдерә. Аның кулында — матбугат. Без аны дорфалыкта гаепли алабыз. Әйе, журналист Г.Тукайның каләме дәрәҗәләрне санга алып тормый. Ә эффекты нинди? Аның журналистлык таланты менә шунда ачыла да инде.

Аның каләме “азына” бара. Ул Казанда һәм Оренбургта чыгучы газета-журналларны да, аларда язышкан яки журналист булган авторларны да тынычлыкта калдырмый. Бигрәк тә “Бәянел-хак”ка һәм шуның юлындагы дини рухлы матбугатка, үзләрен каләм остасы санаучы буш фельетончыларга һәр мәкаләсе саен диярлек каләм очы белән төртеп-төрттереп узуны гадәте итә. Бу исә әбүнәчеләрнең саны һәм географиясе киңәюгә китерә, газетаның тиражы саннан-санга тизлек белән арта бара. Г.Тукайның каләме аның саен тантана итә, үткенләнә, сүзе дә үтемлегә әверелә.

Шагыйрьнең басма томнарын кулга алсак, иҗат мирасының төп өлеше менә шушы Уральски матбугатына караганын күрербез. Әгәр дә вакытында Г.Тукай үз журналистик принципларын мәйданга чыгармаган булса һәм аңа моның өчен мөмкинлекне матбугат хуҗасы К.Мотыйгый бирмәсә, XX йөз башы татар журналистикасы үткенлеге, иҗтимагый аң үсешен тәэмин итүче көч үзенчәлекләре белән аерылып тормас, үз юлын тапкан матбугат чарасы

сыйфатында яшәмәс иде. Хәер, милли үсешебез дә мескенлектән чыгалмый калыр иде.

*2013.*

## МӘҖИТ ГАФУРИ ШИГЪРИЯТЕ

Татар укучысы өчен М.Гафури шигърияте һәрдаим игътибар күзендә булганлыгын, аның шагыйрьлек мәртәбәсе Г.Тукайныкы белән гүяки бердәй икәнлеген искәрткән язмалар матбугатыбыз сәхифәләрендә күренгәләп тора. Әйе, М.Гафуриның шигырьләре халык күңеленә тәэсир итми калмаган.

Шагыйрь яшәгән чорга "әйләнеп кайтсак", XX йөз башы татар матбугаты битләрендә генә түгел, бәлки "шәкерт дәфтәрләре" кебек аеруча шәхси-шәхсәни тупланмаларда да М.Гафуриның әсәрләрен Г.Тукай шигырьләре белән янәшә очрата алабыз. Моңардан чыгып кына да М.Гафуриның шигърияте татар укучысына кадерле, халык күңеленә якын булганлыгын билгеләп үтәргә мөмкин.

Әмма әдәби тәнкыйть һәм әдәбият белеме фәне, шагыйрьлек мәртәбәсеннән чыгып билгеләгәндә, М.Гафурины һичбер вакытта да Г.Тукай биеклегенә күтәрергә омтылмады. Асылда аларның икесенең дә әдәбиятыбызда үз урыннары бар, дип белде.

Шушы урыннарын ачык күз алдына китерү өчен аларның үз индивидуаль иҗат үзенчәлекләрен ачыкларга кирәк. Шунысы әһәмиятле, зур әдәбиятларда әдипләр бер-берләреннән иҗатлары белән шактый кискен аерылып торалар, аларны, хәтта бер мәктәп, бер әдәби юнәлеш вәкилләре булуларына карамастан, үзара бутау мөмкин түгел. Әсәрләреннән иҗат үзенчәлекләре шулкадәр сиземләнелә ки, затлы укучылар аларны узара бутамыйлар. Әмма, шул ук вакытта, ул әдәби үзенчәлекләре күренеп аерылып тору сәбәпле, иҗатта "иярүчеләргә" теге яки бу "әдип булып" язу мөмкинлеге дә, шул манерада "каләм тибрәтеп", әсәрләре белән укучыларны бутау куркынычы да туа. Бу хакта әдәбият галиме Н.Юзиев

“Әдәбият чыганаклары белеме” китабында дәлилле хәбәрләрен язып та чыккан иде[1]. Мәсәлән, З.Ярмәкинең шигырьләрендә Г.Тукайга гына хас манера һәм аһәңне кабатлау очраклары бар. Кайбер әсәрләре Г.Тукайныкыннан аерылмый да кебек, хәтта образларын, символларын, мәгънәләрен һәм гыйбарәләрен дә кабатлый.

Г.Тукай, шигърият мәсьәләсенә килгәндә, М.Гафурины Н.Думави белән янәшә искә ала, кайвакытта ул исемлектә З.Бәширигә дә урын таба. Дөрес, Г.Тукай шигъри осталык мәсьәләсен генә кузгатып калмаган, бәлки бу өч әдипнең шигъриятендә уртак мотивлар, мәгънә-аһәңнәр шактый булуыннан чыгып фикер йөрткән.

Хәер, бер Г.Тукай гына түгел, Г.Ибраһимов та, мәсәлән “Әдәбият мәсьәләләре” дигән 1910 нчы елда “Йолдыз” газетасында басылган зур күләмле мәкаләсендә, М.Гафурины Н.Думави, З.Бәшири, М.Укмаси белән беррәттән атый һәм: “Матбагатымызга байтак ук мәгълүм булган Гафури, Думави, Бәшири һәм Укмаси әфәнделәрнең яздыкларының дөрест һәм чын шигырь мәнзум булып-булмавы хакында кул кисеп бәхәсләшерлек урыннары гайре мөтәнаһидер”[2],— дип белдерә. Алга таба фикерләренә тагын да ачыклык кертеп, ул, С.Рәмиев мисалында аңлатып, аның белән бәйле “поэт души” терминын алга чыгара һәм шигъриятнең хис үсешенә һәм тәрбиясенә хезмәт итәргә тиешлеген дәлилли. Бу яктан М.Гафурины Н.Думави белән тәңгәл куя, Г.Тукайның алардан аерылып торуын билгели. Ә “Татар шагыйрьләре” рисаләсендә исә Г.Тукайны халыкның уй-кичерешләренә җавап таба белүче, ягъни: “Халык бөтендөнья мөселманы өчен кайгырганда — Тукаев шуны җырлады; аннан милләткә күчкәч — аның теленнән татарлык аһлары коелды”,— дип, ягъни халыкчан шагыйрь буларак билгели һәм: “Вакыты белән Гафурине дә күтәргән нәрсә — шул иде”,— дигән фикер уздыра[3]. Г.Ибраһимовның бәяләмәләреннән Г.Тукай белән М.Гафури шигъриятләренең

[1] Юзиев Н.Г. Әдәбият чыганаклары белеме (Әдәби мирасны җыйнауның, өйрәнүнең теоретик һәм гамәли мәсьәләләре).— К.: Фикер, 1998.— Б.67-76.

[2] Ибраһимов Г. Әсәрләр сигез томда.– Т.5.— Б.34.

[3] Шунда ук.— Б.134.

халыкчанлыкта шактый охшашлы икәнлеге ачык аңлашыла. Әйе, чынлыкта да ул шулай.

Г.Тукайның вафатыннан соң татар халкы М.Гафурига тукайчылыкны саклап калучы һәм дәвам иттерүче, әдәбиятыбызны Г.Тукай эзеннән алып баручы шагыйрь итеп тә караган. Әмма М.Гафури үз оригинальлеген, үз индивидуальлеген саклаган һәм үстерә дә алган. Шунлыктан бу ике шагыйрьнең иҗатын чагыштырып өйрәнми, уртак һәм аерымлы якларын ачыкламый һич мөмкин түгел. Хәер, әдәбият галимнәребез XX йөз башының кайсы гына шагыйренә бәя бирергә алынмасыннар, аны Г.Тукай белән чагыштырмый кала алмыйлар.

Г.Тукайныкы кебек үк М.Гафури шигъриятенә дә милләтнең аяныч хәленә канәгатьсезлек, халыкның киләчәге өчен чиксез борчылу хисе хас. Үз заманында бу ике әдипнең шигъриятеннән рухи азыкның микъдар дәрәҗәсен эзләп аптыраган Г.Ибраһимов та аларны хиссез һәм җансыз шагыйрьләр дип атарга ашыкмаган.

М.Гафури шигъриятенә канәгатьсезлек, чиксез борчылу хисе хас, дидек. Һәм ул хис һәм тойгылар әсәреннән-әсәренә бер агым рәвешендә күчә бара. Шунлыктан аның шигърияте күңелне арыта, үзең дә тормышка, кешеләргә карата булган ышанычыңны югалта барганыңны тоясың. Гүяки бу кешелек һәм милләт бары тик авырлык һәм газап эчендә генә җәфа чигүгә дучар ителгән. Дөрес, татар әдипләре бәхеткә ирешү юлларын ул вакытларда да күрсәтә килделәр. М.Гафури да бәхетне, әүвәле, гыйлемдә, аң-белемдә күрде, аннан соң, гади халык арасында гына табуына ышанычын тәкрарлады, ахырда, көрәшкә өндәп, хезмәт тантанасына дан җырлады.

Бу яктан XX йөз башы татар әдипләре үзара охшашлар, гүяки “игезәкләр” сыман. Моңардан чыгып әдәбиятыбызның ул чорында тәнкыйди реализм чәчәк атуын теоретиклар күптән билгеләгән иделәр инде. Тәнкыйди реализмның төп вәкилләреннән саналган М.Гафуриның ул юнәлешкә килеп керүе һәм шигъриятенең елдан-елга үсә баруы Г.Ибраһимов, Г.Халит, Х.Госман, И.Нуруллин, М.Мәһдиев һ.б. тарафыннан тәфсилле өйрәнелде, билгеләмәләр алды һәм бәяләнде. Асылда XX йөз башы татар әдипләре иҗат эшендә бердәй һәм бертөсле үсеш

юлын кичергәннәр иде. Әдәбият теориясенең ул бәяләмәләре һәм билгеләмәләре белән тулысынча килешергә кирәк, чөнки алар – хакыйкатькә туры килә.

Соңгы вакытларда галимнәребезнең иҗат методы мәсьәләләрен яки тулысынча инкарь итүләрен, яисә фәнни фикерләүдән чыгарып ташларга омтылуларын тулысынча хаталы һәм буталуларга илтүче юл дип карарга кирәк. Иҗат методларын ачыклау ул әдәби әсәрләрне дөрес аңлау һәм бәяләү мөмкинлеген бирә.

Әдәбият фәнен, гомумиләштерүләрдән тыш, аермалыкларны ачыклау мәсьәләсе дә кызыксындыра. Әдипләрнең зурлыгы иҗади бердәмлекләрендә, иҗади охшашлыкларында гына түгел, бәлки ачык һәм конкрет индивидуальлекләрендә, ягъни шәхси үзенчәлекләре булуда да. Шунлыктан, М.Гафури шигърияте дигәндә, аның иҗатына хас үзенчәлекләрнең башкаларныкына охшашлыклары, уртаклыклары да, аерымлыгы мәсьәләләре дә безне тигез кызыксындырырга тиеш.

М.Гафуриның иҗатын шактый җентекләп өйрәнгән Г.Халит аның ике үзенчәлеген ачыклап биргән иде. Алар беренчесе — 1917 нче елгы революциягә кадәрге иҗат чорына хас, ә икенчесе — совет дәверенә. Әмма аларның үзара бер-берсенә тыгыз бәйләнештә икәнлеген алдан ук искәртергә тиешбез.

“Билгеле булганча,— дип белдерә Г.Халит,— Гафури иҗатына электән үк тормышның иң гади көндәлегенә, конкрет, җанлы күренешләренә игътибар көчле иде”[1]. Бу — беренчесе. Шуның белән М.Гафуриның иҗат кредосын ачыклап, галим аның “поэзиясенә агитацион-публицистик пафос характерлы”[2] икәнлеген дә ача. Бусы — икенчесе. Г.Халит аның эчтәлеген бу рәвешле аңлата: “Яңа чынбарлыкның җиңү һәм төзү пафосы Гафури поэзиясенә бик хас сыйфат. Ул чын мәгънәсендә гражданлык һәм патриотлык пафосы иде”[3].

Дөресрәге, аның бу гражданлык һәм патриотлык пафослар белән сугарылган агитацион-публицистик шигърияте 1902 нче

---

[1] Халит Г. Мәҗит Гафури // Гафури М. Әсәрләр дүрт томда.— Т.1.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1980.— Б.29.

[2] Шунда ук.

[3] Шунда ук.

елгы “Себер тимер юлы, яки Әхвәле милләт” мәдхиясендә үк үзен ачык сиздерә һәм: “Русиягә кадәре хәл мәдех кирәк”,— дип, ягъни Русияне хәл кадәре мактарга кирәклеген белдереп язуыннан ук күренә. М.Гафуриның бу пафосының үсеш этапларына игътибар итеп, Г.Халит ахырга таба шагыйрьнең “сурәтле уй-кичерешләрнең таркаулыгыннан һәм газетчыл-информацион стиль тәэсиреннән дә азат булып җитә алмавын”[1], ягъни аның тәмам социологизм белән сугарылган пафос вәкиленә әверелүен ачыклаган иде.

Г.Тукай шигъриятендә дә пафос бар, хәтта бик көчле дип әйтергә кирәк. Шунлыктан аның иҗатында кайбер галимнәр романтизм чалымнарын да табалар. Пафос һәм романтизм югары хисләрне кузгатсалар да, аларны бердәй үзенчәлекләргә ия дип карарга ярамый. Пафос ул романтизмның да, реализмның да (әйтик, социалистик реализм) уртак күренеше буларак түгел, бәлки аерым шагыйрьләрнең әдәби сыйфаты рәвешендә дә каралырга тиеш.

Әмма Г.Тукайның пафосы бөтенләй башка. Әйе, анда да патриотик һәм гражданлык хисләре белән сугарылган пафос бар, әмма Г.Тукайда ул “минминлек” һәм “без кемлек” белән сугарылган мәртәбә пафосы да. Г.Тукайдан аермалы буларак, М.Гафурида менә шушы рухи тынгысызлык белән сугарылган пафос юк. “Без сугышта юлбарыстан көчлебез”, яки “Тарихында бер дә тапсыз көзгебез”,— ди Г.Тукай, гражданлык һәм патриотлык пафосы белән сугарылган “Олуг юбилей илә халык өмидләре”ндә.

“Минминлек”, “дөньяны беләмлек” — Г.Тукайның рухи кредосы. Аны талантының көче шундый хисләр дулкынында язарга мәҗбүр итә. Әйе, М.Гафури да Г.Тукай кебек үк затлы җәдитче (“Хисап көне” шигырен генә мисалга алу да җитә). Әмма М.Гафури, шуның белән бергә, минминлексез, дөньялыкта өмет чаткысы тапкан шагыйрь. Хәтта “Кызыл байрак” шигыре дә, башка революцион дип хаклы рәвештә аталырга тиешле әсәрләре дә гыйсьян-бунтарьлык хисе белән түгел,

[1] Халит Г. Мәҗит Гафури // Гафури М. Әсәрләр дүрт томда.— Т.1.— Б.29.

бәлки шатлык-сөенеч, рухи күтәренкелекне тану тойгылары белән сугарылганнар.

Г.Тукай иҗатына дөньяны тулысынча тәмам инкарь итү, аңа югарыдан карап, яратмыйча гына күз салу хас. Дөньялыкка мондый инкарь — борынгыдан, суфи шагыйрьләрдән үк килә торган пафос, бу — татар әдәбияты өчен традицион шигъри рух. М.Гафури да шундый ук юлдан баручы шагыйрь, әмма ул дөнья алдында баш иеп аны инкарь итә, аңа югарыдан түгел, бәлки үз заманы, үз чоры бөеклегеннән генә карый һәм бәя бирә белә. Тормыш белән бәйле очракларда шушы әдәби сыйфатлары М.Гафуриның шагыйрь буларак өстенлеген тәкрарласа, яшәеш принципларыннан чыгып караганда — бу аның көчсезлеге дә иде; моны, Г.Халит билгеләгәнчә, "шигъри талантының зәгыйфьләнүенә дә китерде" дип билгели алабыз. Әмма шуны да онытмаска кирәк, М.Гафури шигъриятенең бәян ителгән бу эчке үзенчәлекләре иҗат процессының шактый катлаулы булуын, тышкы факторларга да бәйлелектә каралырга тиешлеген искәртүне сорый.

М.Гафури мәгърифәтчелек реализмнан алып социалистик реализмга кадәр шактый тигез камил рәвештә үскән һәм бу яктан, әйтергә кирәк, дөнья күләмендә караганда — бердәнбер шагыйрь. Аның бу үсешен Г.Ибраһимов 1921 нче елда язылган "Берничә сүз" мәкаләсенең өченче бүлегендә тәфсилләп һәм зурлап бәяли, шагыйрьнең "Эшче" поэмасын иң яхшы әсәре буларак атый. Дөрес, 1930 нчы елларда ул, вульгар-социологизмга бирелеп, үзе үк бу фикерләрен юкка чыгара. Әмма монысы икенче мәсьәлә.

*Окт., 2000.*

# Г.ИБРАҺИМОВ —
# ЭКСПРЕССИОНИСТ ӘДИП

Г.Ибраһимов татар классик язучыларының берсе буларак мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында өйрәнелә. Аның иҗатының үзенчәлекләренә зур игътибар бирелә. Ул тудырган әдәби геройлар укучыларның күңелләрен яулый, сокландыра, кызыктыра. Алар беркемне дә битараф калдырмый. Әдипнең фикерләре, сурәтләгән тормыш вакыйгалары әледән-әле төрле бәхәсләр уята тора. Бу фактлар үзләре генә дә язучының иҗат мирасының тарихи һәм әдәби әһәмияте зур булуы хакында сөйли.

Г.Ибраһимовның иҗат үзенчәләре нәрсәләрдән гыйбарәт? Бу сорауга әлегә кадәр бер төрле генә җавап та юк. Әдипнең үз иҗатына бәйле 1927 нче елда Г.Толымбайга аталган хатында: “Мин — реалист мөхәррир. Беренче әсәремнән хәзергәчә шул мәсләктә бардым. Арада кайбер әсәрләремдә романтизм элементларының бераз куера төшкән урыннары булгалады (реакция чорында), ләкин боларда да төп мөндәрәҗә-нигез реализм иде”,— дип язганына игътибар юнәлтеп, М.Х.Хәсәнов, алты томлык “Татар әдәбияты тарихы”ның 3 нче томында боларны белдергән иде: “Ләкин Ибраһимовның бу сүзләренә тәнкыйть аша карарга кирәк, чөнки ул әдәбият белемендә романтизмга берьяклы, тискәре караш хөкем сөргән чорда әйтелгән; аңа вульгар социологизмның йогынтысы сизелеп тора”[1].

Мондый методологик күрсәтмәгә таянмый мөмкин түгел. Әмма Г.Ибраһимовның үзен даими рәвештә реалист буларак күрсәтүе һәм аңлатырга омтылышы аның башка язмаларында да чагылыш тапкан. Дөрес, иҗат методлары мәсьәләсе фәндә узган гасырның егерменче-утызынчы елларында гына барлыкка килгән, ул чорда реализм өстен куелып, романтизм кискен тәнкыйтьләнгән. Шул вакытларда романтизмны экияти

[1] Татар әдәбияты тарихы: Алты томда.— Т.3. XX гасыр башы.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.— Б.341.

уйдырмага корылган, хыялый һәм нигезсез, тарихи әһәмияте булмаган иҗат юнәлеше дип аңлату барлыкка килгән. Мондый вульгар социологик фикер әдәбият фәнендә дә ныклап урнашырга өлгергән.

Бу мәсьәләгә ачыклык кертеп, галим Ф.Г.Галимуллин “Г.Ибраһимовның иҗат ысулы” дигән мәкаләсендә болай дип яза: “Егерменче-утызынчы елларда иҗат методы турында сүз барганда, иң элек идеология максаты күздә тотылды. “Совет әдәбиятында романтизмны үз итәргәме-юкмы?” дигән сорау үзәк мәсьәләнең берсе булып чыкты. Романтизмны реализмнан түбәнрәк баскычта торучы иҗат ысулы дип карау булды. Реализм һәм романтизмга мөнәсәбәттә вульгар социологизм таләпләрен нигез итеп алу күзәтелде. Шундый яктылыкка куеп караганда, Г.Ибраһимов иҗатының каршылык уятуына гаҗәпләнергә кирәкме икән? Аның иҗат ысулы хәрәкәтен билгеләгәндә “романтизмнан — реализмга” дип карауның тенденциоз булуы әйтмәсәң дә аңлашыла иде”[1].

Мәкаләдә иҗат методы һәм иҗат процессы мәсьәләсе үзәккә алып тикшерелә һәм кызыклы фикерләр әйтелә. Язучыларның әдәби әсәрләрен матурлык законнарына нигезләнеп тудырулары исәпкә алынмау кискен тәнкыйть ителеп, Ф.Г.Галимуллин фәнни әһәмияте зур булган фактларны искәртә: “Утызынчы еллар башында реальлек дәрәҗәсен билгеләгәндә “чынлык эквиваленты” дигән үлчәү куллануга чакырулар булды. Әйтик, ул елларда мәсьәләгә болай якын килү очрый: “Әгәр образ уйлап чыгарылган һәм аңар чынлыкта эквивалент юк һәм була да алмый икән, димәк, ул реаль түгел һәм шуның белән логикалы да түгел”[2]. Шушы тәнкыйть ителгән вульгар социологик фикерләр озак вакытларга әдәбият фәнендә яшәп калалар.

Бүгенге көндә дә мәсьәләне шул рәвешле аңларга-аңлатырга тырышуларны күздә тоту белән бәйле Ф.Г.Галимуллинның бу мәкаләсе язылганлыгы аңлашылып тора. Вульгар социологик позицияләрдә торучылар әлбәттә

---

[1] Галимуллин Ф.Г. Эзләнү вакыты.— Казан: Мәгариф, 2005. — Б.179-180.

[2] Шунда ук.— Б.182-183.

реализм белән натурализмны бутаганнар. Шуның аркасында Г.Ибраһимов 1933 нче елда “Коммуна” газетасында, Башкортостан педагогия институты студентларының үзенә мөрәҗәгать хатына җавап буларак, “Кайбер әдәби мәсьәләләр” мәкаләсен бастырып чыгарган һәм анда болай дип белдергән: “Мин натурализмга каршы. Тормыш кисәкләрен шул көенчә, фотографияләп дөньяга ташлау юлы белән төзелгән әсәрләрнең кыйммәте юк. Минемчә, әдәби әсәрләр тормышның каты көрәшле, күп катлаулы, бай каршылыклы тирән процессларын иҗат механизмы аркылы, җанлы сурәтләрдә гәүдәләндерү, чагылдыру юлы белән язылганда гына социалистик реализмга ирешеп булачак”[1].

Г.Ибраһимовның иҗат юнәлеше мәсьәләсен, әдәби иҗат осталыгын ачыклау белән бәйле рәвештә эзләнүләр фәндә туктаусыз кабатланып тора. Аны реалист та, романтик та, натуралист та дип, кайбер әсәрләренә карата гына әйтелеп киленә. Әмма бу исә бөек әдибебезнең туры, аерым мәсләге булмаган икән, иҗат юнәлешен бер кыйблага гына төбәп алып бармаган дигән фикерләргә дә этәрә. Бу бик тә хаталы бәяләмә, билгеле.

Язучы тормыш фактларын өйрәнгәндә һәм аларны яктыртканда үзенең әйтергә теләгән фикеренә таянып эш итәргә тиеш. Ул матурлык кануннарына таянып эш итә икән, тормышны әсәрендә сурәтләп бирү ысулын да сайларга, шул сайлаган юл белән вакыйгаларны бәян итәргә хокуклы. Бары тик матурлык кануннарына хилаф китермәскә тиешле.

Г.Ибраһимовның иҗат үзенчәлекләрен галимнәр халыкара фәнни-гамәли конференцияләрдә туктаусыз чишеп баралар. XX йөз башы татар әдәбиятын әдәби-эстетик җәһәттән фәнни нигезгә салып өйрәнүче галимнәрдән булган Г.Халит бу дәвергә үзенең “Портреты и проблемы” дип аталган хезмәтендә эзлекле һәм эчтәлекле бәяләмәләр бирә, ул әдәби чорның төп үзенчәлекләрен дөрес ачыклый алган һәм күрсәткән.

“Наше литературоведение иногда представляет татарскую литературу как бы стоящей в стороне от влияния модернизма

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.5.— Б.520-521.

и декаденства”[1],— дип яза ул, шул чорда татар әдәбиятында модернизмның шактый көчле алга баруын дәлилләп чыга һәм мондый әһәмиятле фикергә килә: “Особенно в десятые годы, в годы революционного подъема, идейно-эстетические тенденции в творчестве таких демократических писателей, как Г.Тукай, М.Гафури и Г.Ибрагимова, явно свидетельствуют, что в нашей литературе были мощные зародыши романтического реализма”[2]. Алга таба бу фикерен тагын да ныгытып һәм конкретлаштырып аңлатып уза: “Характерные примеры этого выпукло отразились в творчестве Г.Ибрагимова. Такие его произведения, как “Наши дни”, “Новые люди”, “Сказание о красных цветах”, можно рассматривать как примеры романтического реализма”[3].

Г.Халитның “романтик реализм”, “синтез романтизма и реализма” дигән төшенчәләре совет чоры әдәбият белгечләренең модернизмны шулай атауларыннан килеп туган “ачышлары” иде. Моның сәбәбе бик гади, совет фәне модернизмны, ягъни декадансны (алар икесе дә бер үк күренешкә бәйле терминнар) — “сәнгатьнең череп таркалуы күрсәткече” дип бәяли иде. Мондый методология кысаларында Г.Ибраһимовның әсәрләрен ничек итеп модернистик дип атап тикшерергә мөмкин? Менә шуннан романтик реализм, романтизм һәм реализм синтезы кебек сәер мәгънәләр барлыкка килде.

Иҗат методы мәсьәләсендә шактый катлаулы проблемаларны кузгатып, иҗат процессы хакында чикләнгән һәм гадиләштереп, аңлап җиткерми фикер йөртүләргә каршы чыга югыйсә Г.Халит, әдәби иҗатның асылы иҗат методында гына булмавын аңлата, бәлки матурлык тудыру чараларын, юлларын барлауга һәм фәнни тикшерүгә чакыра, ачык итеп, “Творческий метод — не талисман” дип, мәкаләсенең исеменә үк чыгара[4]. Игътибар итсәк, аның бу хезмәте 1967 нче елда ук язылган һәм бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмаган. Әмма

---

[1] Халит Г. М. Портреты и проблемы: Избранные статьи разных лет.— Казань: Татар. кн. изд-во, 1985.— С.209.

[2] Шунда ук.— Б.206.

[3] Шунда ук.— Б.216.

[4] Шунда ук.— Б. 281- 300.

шунысы да бар, Г.Халит бу китабында асылда үзе дә иҗат методларын барлый, тикшерә, бәяли, фикерләрен алга үстереп, аларны бәхәс кыла.

Г.Ибраһимовның әсәрләре үзенчәлеген ачыклаганда да шул ук романтизм һәм реализм иҗат методлары белән бәйләнештә фикер йөртә, романтизм һәм реализм синтезы хакында сөйли. Моны әдипнең иҗатын бер иҗат методы кысаларында галимнең аңларга һәм аңлатырга омтылыш белән дә бәйләргә мәҗбүрбез.

Г.Ибраһимов иҗатын фәнни эзлекле һәм барлык яктан диярлек тикшергән галим М.Х.Хәсәнов, әдәбилек үзенчәлекләренә төп игътибарын юнәлтеп, әдипнең башлангыч хикәяләрендә экспрессионистик үзенчәлекләрнең өстенлек алганлыгын ачыклый һәм болай дип аңлата: “Ибраһимовның бу чор хикәяләрендә чынбарлык белән шәхес арасындагы каршылык реаль, объектив тормыш ситуацияләрендә түгел, ә геройның экспрессив хисләрендә, эчке кичерешләрендә, рухи омтылышларында чагыла”[1],— ди. Әмма ул да Г.Ибраһимов иҗатына хас “романтик алымнарны реалистик чаралар белән якынайту”[2] мәсьәләсенә кереп, иҗат методы проблемаларын үзенчә актыртуга алына. Хисләрнең экспрессиясе хакында сүз кузгатылып та, ул үстерелмичә, тиешенчә аңлатылмыйча калдырыла. Г.Ибраһимовның иҗатына хас бу үзенчәлек, шул рәвешле, әлегәчә чишелмәгән, фәнни яктан ачык итеп куелган хәлендә кала бирә.

Иҗат методы мәсьәләләрендә галимнәрнең бәхәсләренә керү асылда безне әллә ни кызыксындырмый. Әмма кайбер күзаллауларына карата фикерләребезне белдерми үтүне дә кулай күренеш түгел дип беләбез.

Без реализмның төп үзенчәлеген геройларны һәм вакыйгаларны авторның “читтән торып сурәтләвендә” күрәбез. Ә романтизмны геройларны һәм вакыйгаларны “эчтән торып”, ягъни әдәби герой исеменнән сөйләүне атыйбыз. Монда реализм һәм романтизмның аерым бер якларын гына алып, катлауландырмый фикер йөртергә тырыштык. Бу исә

[1] Татар әдәбияты тарихы: Алты томады.— Т.3.— Б.340.
[2] Шунда ук.— Б.341.

мәсьәләне артыгы белән гади итеп аңлау һәм аңлатуга да китерергә мөмкин. Моның шулай икәнлеген белә торып, төшенеп эш иттек. Фәнни конкретлаштыру өчен башка төрле, киң планда, чәчелеп эш итү кулай дип табылмады. Экспрессионизм төшенчәсен "хисләр ташкыны", көчле эмоциональлек буларак аңлап һәм төшенеп фикер йөртү уңышлы.

Экпрессионизм ул — әдәби-мәдәни агым, XX йөзнең беренче яртысында, бигрәк тә сәнгатьтә, эмоцияләрнең көчле чагылышын тасвирда гәүдәләндереп-сынландырып сурәтләүгә корылган була. Хис-тойгыларны бу агым мөмкин кадәр күтәренке халәткә, соңгы чиккәчә җиткерергә омтыла, шуның өчен дә хис-тойгыларны, эчке кичерешләрне, тәэсирлелекне тирән мәгънә һәм эчтәлек белән бирергә дип кирәк таба. Ә моның өчен экспрессионистик, ягъни көчле хис-тойгылы сурәтләү үзенчәлекләрен булдыру сорала. Билгеле, әдәби метод буларак, язу алымы дип тә, стиль үзенчәлеге рәвешендә дә карарга була аны. Әмма экспрессионистик алымнар романтизм һәм реализм иҗат юнәлешләренең икесенә дә хас күренеш. Әдәби геройларның уй-хисләрен дә, тышкы яктан үз-үзләрен тотышлары аша табигатьләрен дә бергә, берьюлы бирүне, әле реализм, әле романтизм планнарында язуны модернистик алымнарга хас буларак карарга тиешбез. Шулай да модернизмны, реализмнан да, романтизмнан да аерып, өченче төр иҗат юнәлеше рәвешендә аңлау-аңлатуны кабул итәргә ярамый. Хикмәте шунда: кешенең тышкы һәм эчке дөньясы гына бар, өченче дөньясы юк. Сурәтләүдә эчке һәм тышкы дөньяларның кушылма-синтезы белән эш итү — модернизмга хас. Алар шулкадәр тыгыз берләштерелә, хәтта әдәби герой да чынбарлык белән хыял дөньясын үзара бутый, аера алмаслык халәткә китерелеп тасвир ителә. Укучы да аларны аермаслык хәлгә җиткерелә. Менә шул рәвешле хис-тойгылар ташкыны әсәрнең башыннан ахырынача көч агым белән үстерелеп алып барыла. Моны экспрессионизм, диләр. Ул модернизмның, бигрәк тә аның яңачасының, неомодернизмның, сәнгати алымнарыннан берсе булып тора.

Г.Ибраһимовның “Яшь йөрәкләр” романын гына алып карыйк. Әсәр экспрессионистик планда язылган. “Яшь йөрәкләр”нең, татар әдәбият гыйлемендә кабул ителгәнчә, романтизм үрнәге булуына каршы килмибез, чөнки анда романтик хис-тойгыларны сурәтләү өстенлек итә, романтик хыял, романтик идеал аның геройларын яшәтә. Әмма вакыйгалар бу әсәрдә реалистик планда, тормыштагыча итеп тасвирланып бирелгәннәр. Менә шуның өчен Г.Ибраһимов үзен реалист язучы буларак күрә. Реалистик вакыйгалар эчендә романтик герой гаҗәеп тәэсирле ачыла, аның һәр адымы, һәр хәрәкәте хис-тойгыларны уята. Менә шушы үзенчәлеге, ягъни тормыш белән ярәшә алмавын табигый рәвештә сурәтләү экспрессионизм алымын тудыра да инде һәм әсәрдәге шул якларны барлау һәм табу “Яшь йөрәкләр” романын дөрес аңлау-аңлатуга китерә.

Г.Ибраһимов шактый катлаулы дәвердә яшәгән, И.В.Сталин чорында репрессия корбаны булган. Иҗатына үз бәяләре белән танышканда, коммунистлар хакимияте, вульгар социологизм чоры әдәби-эстетик карашларын үзгәртергә, хәтта сәгати иҗат асылларын яшерергә мәҗбүр иткәнлеген дә аңлап эш итәргә тиешбез. Аның укучылары белән ачыктан-ачык сөйләшү чоры, үз әдәби-эстетик карашларын яшерми белдерү дәвере дип бары тик XX йөз башын саный алабыз. Хәер, татар әдәбияты белемендә вульгар социологизмны нигезләгән галимебез дә Г.Ибраһимов булды, анысын да онытмыйк.

Әдипнең әдәби-эстетик карашларын ачык күз алдына китерү максатын торканда, әлбәттә аның язган әдәби тәнкыйть мәкаләләрен, әдәбиятка караган фикерләрен, әдәби әсәрләрен өйрәнү зарурлыгы туа. Шушы юнәлештә эзләнүләр алып барып, безгә бу хезмәтебездә тагын да кайбер мәсьәләләрне өстәмә рәвештә чишәргә туры килде:

Беренчедән, Г.Ибраһимовның ни сәбәпле С.Рәмиев иҗатына югары бәя бирүен ачыклау кирәк табылды, чөнки әдип нәкъ шушы эше өчен гомере буе шактый авыр тәнкыйть сүзләренә дучар була, Г.Тукайны аңламавында, тенденциозлыкта бүгенге көнгә кадәр гаепләнеп киленә. Аны

акларга яки якларга тиешлебез дигән юлга бару максатыбыз булмады. Бары тик шул бәяләмәләрен өйрәнеп, С.Рәмиев шигърияткә нигә, нинди әдәби һәм эстетик критерийлардан чыгып бәяләвен беләсебез килде. Нәкъ менә шул, ягъни “Татар шагыйрьләре” хезмәтендә Г.Ибраһимов асылда экспрессионистик алымнар хакында киң мәдәни планлы һәм әдәби-эстетик тирәнлектә фикер йөртә.

Икенчедән, Г.Ибраһимовның әдәби осталыгы нәрсәдән гыйбарәт, шуны беләсебез килсә, моңа юлны шул ук “Татар шагыйрьләре” хезмәте ача. Язучының укучыларга мәктәп дәресләреннән яхшы таныш әдәби әсәрләренә яңача, экспрессионистик алымнарын ачыклау юнәлешендә анализ ясау һәм иҗатының төп үзенчәлекләрен, асыл табигатен ачыклау, фәнни-тәнкыйди юнәлешкә караган күп санлы хезмәтләрендә аның экспрессионистик карашларга таянып фикер йөрткәнлеген, шул әдәби-эстетик агым принципларын үзләштереп, шушы юнәлештә иҗат эшчәнлеге белән шөгыльләнгәнлеген ачыклау күп белем, көч һәм вакыт таләп итә. Боларны онытырга ярамый.

Шуның өчен дә әүвәле Г.Ибраһимовның “Татар шагыйрьләре” хезмәтеннән С.Рәмиевкә багышланган беренче кисәге анализланды, әдипнең әдәби әсәрләргә карата булган бәяләү принциплары һәм таләпләре ачыкланылды. Шушы бәяләренең эчтәлеге һәм тәртибе конкретлаштырылды. Г.Ибраһимовның теге яки бу термин-төшенчәне нинди эчтәлектә файдаланганлыгы төшенелеп, аларның хәзерге терминология нигезендә атамалары бирелеп, бары шуннан соң гына нәтиҗәләр чыгару зарур дип табылды. Бары шушы эшләрне башкарганнан соң гына, алга таба әдипнең әдәби әсәрләре анализланды, алардагы хис ташкынын сурәтләү, экспрессия үзенчәлекләре ачыкланылды һәм бәяләнде.

Ни өчен болар хакында искәртәбез? Бары шул сәбәпле — әдипнең иҗат мирасын без дөрес аңлыйбызмы, хаталы аңлатмыйбызмы дигән сораулардан борчылуыбызны сиздерер өчен, алардан котылу юлында нинди нәтиҗәләргә ничек килә алганыбызны төшендерергә кирәк табылганга күрә, дибез. Юлың хаталы булса, максатыңның изге булуы да коткара

алмый, адашасың, имеш. Бу фәлсәфә никадәр дөрестер — анысы да күренер, дидек.

Г.Ибраһимов экспрессия алымнарын һәм романтик, һәм реалистик планда язган әсәрләрендә дә бик оста файдаланган. Аны чыннан да бары тик яки романтизм, яисә реализм вәкиле дип тә булмый. Хәер, ул хакта да галимнәрнең фикерләре инде әйтелгән, хезмәтебездә аларның фикерләре тагын да бер кат раслану таптылар кебек.

1

Г.Ибраһимовның "Татар шагыйрьләре" дип аталган монографик хезмәтендә әдәби-эстетик, әдәби-теоретик карашлары тулысынча диярлек бәян ителгән. Ул аны, билгеле булганча, 1912 нче елда иҗат иткән һәм 1913 нче елда Оренбургта аерым китап итеп бастырып чыгарган[1]. Бу вакытта ул танылган язучы, журналист, әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче буларак билгеле.

Шушы хезмәтендә Г.Ибраһимов татар шагыйрьләре С.Рәмиев, Дәрдемәнд, Г.Тукай иҗатларына бәйле фикерләрен белдерә һәм, аларның әсәрләрен аңлату аша, үзенең әдәби-эстетик карашларын укучыларына җиткерә. Шушы сәбәпле бу хезмәт XX йөз башы татар әдәбияты, аның мәдәни тормышы белән бәйле гыйльми тикшеренүләр өчен аерым әһәмияткә ия, әмма, моңа да карамастан, галимнәр аны мөмкин кадәр читләтеп үтәргә тырышалар, авторның фикерләрен кабул итәргә яки аңлатырга алынырга теләмиләр. Моның сәбәбе бик гади, әлбәттә. Хезмәттә Г.Тукаебызның шагыйрьлеге мәсьәләсе ачыктан-ачык куелган, шик астына гына булса да алынсын иде, юк шул, турыдан-туры белдерелеп-аталып инкарь ителгән. Г.Ибраһимов ни өчен шулай эшләгән? Моның җавабы табылырга тиеш иде. Югыйсә ул башка хезмәтләрендә андый фикерен кабатламый.

"Татар шагыйрьләре"н Г.Ибраһимов турыдан-туры С.Рәмиев иҗаты белән бәйләнештә башлап китә һәм үзенең күңеленә, "татар шагыйре" дигәч тә, аның исеме килүен

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.5.— Б.553.

беренче сүзләреннән үк белдереп куя[1]. Ул аның хәтта иң аз язганлыгын һәм халыкта иң аз мәгълүм булганлыгын да яшермичә әйтеп уза. “Гавам аны укый алмый; укыганнар эчендә аны тәкъдир итүчеләр дә бик аз”[2],— ди ул. Димәк, Г.Ибраһимов бу хезмәтендә С.Рәмиевнең халык арасында шагыйрь буларак танылмаганлыгын да яхшы белеп һәм аңлап эш итә, шунда ук, моның сәбәпләрен искәртүне үз өстенә алып, китап бастыручы наширларның зәвыксызлыгы аркасында шушы хәлнең килеп чыгуын ассызыклап уза. Әмма аның фикере “шигырь нәрсә ул” һәм “шагыйрь кем ул” дигән сораулар тирәсендә бөтерелә. Аларга җавап эзләп юлында хезмәтнең язылуы авторның һәр сүзеннән диярлек аңлашылып тора.

Безгә дә С.Рәмиевнең халык арасында танылу-танылмау мәсьәләсе, Г.Ибраһимовча фикер йөртсәк, әллә ни әһәмиятле түгел. Шуңа күрә аның хезмәтендәге һәрбер читкә алып куела барылган тезисны тикшерүгә алынмыйча, авторның әдәби-эстетик карашларын ачыклауны үзәккә куярга тиешбез.

Бу җәһәттән иң тәүдә калку итеп алга Г.Ибраһимов боларны чыгара: беренчедән, С.Рәмиевне ул “безнең шагыйрьләремез эчендә чын вә куәтле”[3] дип атый, ягъни аның чын шагыйрь икәнлеген дә, көчле шагыйрь булуын да ассызыклап белдереп куя. Димәк, алга таба ул моның сәбәпләрен, шагыйрьлек хикмәтен ачыкларга һәм ачарга тиеш булып чыга. Икенчедән, “шигърият ягыннан караганда иң алгысы вә иң куәтлесе улып”[4] торганлыгына ышанычын белдерә. Моны без С.Рәмиевнең татар шигъриятенең авангард вәкиле икәнлегенә төшендерүе буларак аңларга тиешбез.

Г.Ибраһимов фикеренчә, С.Рәмиев калган барча татар шагыйрьләреннән дә шигъри яңалык ягыннан алда бара һәм бу алдынгылыгы бик көчле бер алдынгылык булып чыга. Беренче тезиста да, икенчесендә дә ул “куәтле” сүзен куллана. Монда һичбер кабатлану юк икәнлеген аңларга кирәк. Беренчесендә

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.5.— Б.74.
[2] Шунда ук.
[3] Шунда ук.— Б.75.
[4] Шунда ук.

куәтлелек мәсьәләсе С.Рәмиевнең чын шагыйрь икәнлегенә карый, икенчесендә исә аның авангардлыгының дәрәҗәсен билгеләмәк максаты тора. Өченче тезисын Г.Ибраһимов бу рәвешле билгели: “Аның язганнары үз бабында иң беренче урынны алып”[1] тора, ди.

Монда бигрәк тә “үз бабында” дигән терминны аңлау-аңлату зарурлыгы килеп туа. Аны шагыйрьлек белән бәйләргәме, әллә шигърилеккәме, әллә шигъриятъ алдынгылык тотугамы? Бәлки Г.Ибраһимовның әдәби-эстетик карашларын ачыклау аша гына “үз бабы” төшенчәсен аңлатып биреп буладыр? Һәрхәлдә мәсьәлә менә шушының белән бәйле кебек аңлашыла.

Дүртенчедән, Г.Ибраһимов С.Рәмиевнең шигырьләре халык тарафыннан ирексез ятланылып, телләрдә дога урынына сөйләнелеп йөртелә дигән фикерне дә ассызыклап уза[2]. Димәк, аның төшендерүенчә, чын шигырь ул ирексез рәвештә хәтердә калырга тиеш. Әгәр дә шигырь укылуга онытыла, хисләрне кузгатмый икән, ул чын шигырь була алмый.

Г.Ибраһимовның шушы дүртенче тезисын без һәммә төрле шигырьгә бәйле рәвештә төп эстетик канун буларак алга чыгара алабыз. Әдәби әсәрнең ни кадәрле талантлы була алуы яки алмавы аның укучы күңеленә үтеп керә алу-алмавына бәйле икән. Телләрдә дога итеп сөйләнелеп йөртелә торган әсәрләр генә чын, зәвыклы булып чыгалар. Моны халык телендә әйтелеп йөртелә торган “новязчивость”, ягъни “бәйләнчеклек” белән бәрабәр куяргамы, юкмы? “Бәйләнчек көйләр” безне, бер тапкыр колакларыбызга кергәч, озак вакытлар аптыратып-йөдәтеп бетермиләрме? Бәлки монда Г.Ибраһимов ялгышкандыр, ул “бәйләнчек шигырьләрне” чын шагыйрь дип хата белән атагандыр?

Аның шигырь хакында, шигъри сүзнең куәте турында искәртеп, “телләрдә зикер вә вирд унынына йөртелмәктәдер”[3] дигәнендә әлбәттә тирәнрәк мәгънәләр ята, бу сүзләре белән ул шигырьнең илаһилыгы хакында сүз алып бара. Алга таба

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.5.— Б.75.
[2] Шунда ук.
[3] Шунда ук.

шушы хезмәтендә бу тезисын тагын да киңрәк итеп ачып бирә. Без аңа әйләнеп кайтырбыз әле.

Хезмәтенең тәүге сәхифәләрендә шушы фикерләмәләрен белдерә-белдерә килеп, санап узганнан соң, Г.Ибраһимов ачыктан-ачык болай яза: “С.Рәмиев бервакытта да гавам һәм гомум тарафыннан, әллә кем шагыйрьләр кеби, тәсдикъ һәм тәкъдир ителәчәк адәм түгел”[1],— ди. Димәк, С.Рәмиевнең башка шагыйрьләр кебек халык тарафыннан чын шагыйрь буларак кабул ителмәячәген һәм халыкта танылу алмаячагын Г.Ибраһимов ачык аңлап эш итә. Моның белән ул үзенең әдәби-эстетик карашларының асылын төгәл ачыклап та куя: халык арасында танылу һәм халык тарафыннан кабул ителү анынча чын әдиплек түгел әле.

Ә тарих, мәдәни үсешебез бу сүзләрендә хаклыкның күләме шактый зур икәнлеген көннән-көнгә дәлилләп тормыймы? С.Рәмиевнең шагыйрь буларак мәртәбәсен югары куеп буламы? Бүгенге татар укучысы аны бөтенләй дә белми, диярлек. Әгәр дә Г.Ибраһимов “Татар шагыйрьләре”ндә аның урынын шулай өстә дип күрсәтмәсә, әдәбият тарихыбыз сәхифәләренә иҗатының монографик планда өйрәнелүе дә икеле. Бу рәвешле уйларга бирелергә дә хакыбыз бар кебек. Әмма Г.Ибраһимовның бәясе белән дә килешми мөмкин түгел. С.Рәмиевнең шагыйрьлеген һәм чын мәгънәсендә шагыйрь булуын берничек тә юкка чыгарырлык түгел.

Әгәр дә Г.Ибраһимов шулай ди икән (ә ул чыннан да моны ачык белдерә), ул вакытта нәрсә соң чын әдиплек, чын шагыйрьлек? Ни өчен аның тарафыннан С.Рәмиев “чык һәм көчле шагыйрь” аталды? Нигә дип Г.Тукайның “моңлы сазында” ул шагыйрьлек күрмәде? Автор үзенә-үзе каршы килмиме? Бу халыкка, гавамга каршы атылган зәһәрле кайнар ук түгел идеме? Әллә бер тендинциозлык, мин-минлек, мин кемлек кебек галәмәтләрдәнме?

Безнеңчә, бу проблеманы чишә алсак, Г.Ибраһимовның әдәби-эстетик карашларын да тулысынча төгәл һәм нигезле ачарга мөмкинлек туачак.

---

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.5.— Б.75.

С.Рәмиевнең халыкта танылу алмавының сәбәбен Г.Ибраһимов шагыйрьнең артыгы белән “үзенчә”, артыгы белән мөстәсна-аерымлы, артыгы белән “оригинальный” язуыннан чыгып аңлата, бары тик югары зәвыклы, сизгер күңелле өстен катлам вәкилләре генә аны кабул итәчәген, төшенәчәген аерым билгеләп ассызыклый[1]. “Туң, тупас һәм калын табигатьләр, шулай ук үзләрен һәрбер адымда салкын гакыл, коры мантыйклар рамкасына тыгып йөрергә өйрәнгән “бөекләр” дә аны, әлбәттә, талант дип танымаслар һәм танымыйлар”[2],— ди ул. Шактый төгәл әйтелгән. Зәвыкларны алыштырып булмый.

Г.Ибраһимов “туң, тупас, авыр табигатьле” дигәнендә әлбәттә хис-тойгыларга бирелмәүче кешеләрне күздә тотып фикер йөртә, “салкын гакыл, коры мантыйк рамкаларында” йөрүчеләрне рационалистлар, исәп-хисаплылар буларак аңларга кирәк. Аларны автор “бөекләр” дип атый, ягъни әдәбиятка карата өстән караучылар, аны кирәксез һәм файдасыз дип белүчеләр күздә тотыла монда.

Шунда ук кызыклы фикер уздырыла: халык танымаса — танымасын, әмма С.Рәмиев аңа карап кына бөек шагыйрь булудан туктамый[3], ди ул. Димәк, халыкта танылу алу чын шагыйрьлекнең күрсәткече түгел икән әле.

Нәрсә соң ул вакытта чын шагыйрьлек?

Сорау бу юлы да Г.Ибраһимов тарафыннан җавапсыз калдырыла. Әмма ул алга таба, укучыларына мөрәҗәгать итеп, әдәбият белемендә XIX гасырдан үстерелеп килгән культура-тарих фәнни мәктәбе вәкиле, рус галиме, әдәби тел өлкәсендә шигърият-поэтика белгече Д.Н.Овсянико-Куликовский хезмәтендә язылган фикерләргә игътибар юнәлтә, аңардан укучының шигырьне аңлау һәм кабул итүенә бәйле аңлатмаларны ала. Алардан бу чыга: шигырь яратучылар үзләре дә кечек шагыйрь булырга тиешләр, рухында шигырь яшәмәгән кеше шигырьне аңламый, шигырьне төшенүе өчен, аның үз күңелендә дә шул шигырьнең чаткысы балкырга

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.5.— Б.75.
[2] Шунда ук.
[3] Шунда ук.

тиеш, әгәр дә рухында шигырьнең орлыгы юк икән, никадәр галим аталмасын, әдәбиятның кирәклеген һәм мәгънәсен таный алмаячак. Шулай итеп, бу сүзләргә бәйле, “чын шагыйрьне күңелләрендә шигырь уты булучылар гына таныйлар” дигән мәгънә чыгара алабыз. Бу, әлбәттә, субъективлык. Ә хис-тойгылар алар шундый субъектив нәрсәләр, алар кешесенә, ягъни аның холкы-фигыленә, күңел халәтенә һәм башкаларга да бәйле. Аз гына бер тәэсир дә кайсы-кемдә көчле бер тәэссорат тудырырга мөмкин. Була тагын да шундыйлар, аларга, таш яуса да — барыбер. Димәк, бу фикерләмәдә бернинди мантыйсызлык, хакыйкатькә хилаф итү юк. Аның белән килешергә кала.

Г.Ибраһимов, бу аңлатмага таянып, С.Рәмиевнең татар халкында шагыйрь сыйфатында танылмавының сәбәбе укучыларының тупас табигатьле булуларыннан килгәнлеген белдереп куярга кирәк таба. Ул моның белән тагын да С.Рәмиевнең заманнан алда барганлыгын, авангард шагыйрь икәнлеген, киләчәктә аны аңлаучы һәм чын шагыйрь буларак кабул итүчеләр барлыкка киләсен төшендереп ала. Болар, шулай ук, әлегә әдәбиятны аңлау-аңламау, кабул итү һәм кабул итмәү, укучының әзерлеге мәсьәләләрен искәртүдән генә, ягъни зәвык мәсьәләсен ачыклаудан гыйбарәт фикерләмәләр булып кала бирәләр. Әмма Г.Ибраһимов әдәби әсәрнең асылы хискә корылганлыгын, бигрәк тә шигырьнең эчтәлеге хис белән бәйле икәнлеген ачыклап, нигезләп уза. Хискә коры мантыйк, күңел тупаслыгы каршы куела. Әдәби әсәрне коры мантыйклы һәм тупас күңелле, ягъни зәвыксыз кешеләр генә аңламый икәнлеге ачыкланыла.

Шулай итеп Г.Ибраһимов әдәби әсәрнең талантлы булуын аның хис-тойгыга бәйләнешле икәнлегеннән чыгып бәяләргә кирәклеген ачык итеп аңлатып бирә. Тупас, коры мантыйкка корылган әсәрләрне тупас, зәвыксыз кешеләрнең генә кабул итүен, чын әдәби әсәрләрне аларның аңламавын төшендерә.

Шушы рәвешле фикерләрен алга таба үстереп, әдип шул ук вакытта С.Рәмиевтән дә “түбән һәм тупас нәрсәләр”[1] таба,

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.5.— Б.76.

әмма шагыйрьне аклап, аларны “вакытлы бер тәэсир илә”[1] язылганнар дип атый. Шул әсәрләр исемлегенә ул “Уку”, “Муллалар эше”, “Хатыннар галәме”, “Театру” дигән шигырьләрне кертә, аларны хәтта “әкәмәтләр” дип атый[2]. Шуннан соң гына С.Рәмиевнең, кеше буларак, тормышын, дөньяга карашын, әхлак һәм идеалларын, нинди тәэсир астында язуын белмәвен дә искәртеп куя. Болар белән Г.Ибраһимовның һәртөрле әдипнең иҗатын яхшы күзаллау өчен аның биографиясен, әхлак принципларын, иҗат процессын өйрәнү кирәклеген инкарь итмәвен ассызыклап киткәнлеге аңлашылып тора. Әмма мондый, ягъни тарихи-биографик юл белән иҗатка бәя бирү кайбер әдипләр белән бәйле зарур да түгеллеген ачыклый[3]. Шуннан соң гына шагыйрьнең әсәрләрен аңлатуга, шуның белән үзенең әдәби-эстетик карашларын бәян итүгә керешә.

С.Рәмиевнең шигырьләре — “тугрыдан-тугры үз рухының көзгесе”[4], дип белдерә Г.Ибраһимов, укучы алдында субъективлыкны өстен чыгарып. Монда әдәбиятның тормыш көзгесе дә булуы әлегә исәпкә алынмый. С.Рәмиевнең чын мәгънәсендә шагыйрь булуын шигырьләрне “үз иркеннән башка, үзеннән-үзе” китереп чыгаруында, “хезмәт куәтен” сарыф итмичә генә язуында күрә Г.Ибраһимов. Моны шигырьләрен укыганда ук аңларга, күрергә мөмкин икәнлеген төшендерә[5]. Чын һәм көчле шагыйрь шушындый булырга тиешлеге укучыга аңлатыла. Ул сүзләргә ышана башлыйсың. Шушындый рухи стимул бирүче көчнең башкаларга сер булуын, ягъни әдипнең талантына бәйле икәнлеген ул яхшы төшенеп фикер йөртә.

Г.Ибраһимов, кабатлана-кабатлана, С.Рәмиевнең шигырьләре үз иркеннән башка, ягъни “ирадәсез” туалар дип белдерә. Моның белән ул шагыйрьнең күңелендә шигырьнең илаһи бер тәэсир аркасында барлыкка килүе хакында сөйли. Шулай итеп, С.Рәмиевнең шигырьләре күңеленнән, рухыннан

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.5.— Б.76.
[2] Шунда ук.
[3] Шунда ук.— Б.77.
[4] Шунда ук.
[5] Шунда ук.

кайнап чыгып барлыкка килүен төшендереп узып, Г.Ибраһимов аларга хезмәт куелмау мәсьәләсен дә ача, моның белән бергә тәнкыйть сүзләрен дә әйтә. Бу инде шигырь техникасы мәсьәләләрен кузгатуы да, поэтик яктан әсәрләрне эшләү-эшкәртү кирәклеген төшендерүе дә.

“Аның һәрбер сүзе йөрәгенең әллә кай җиреннән кайнап, рухының төбеннән, эчке нокталарыннан ялкынланып килеп чыга” [1] ,— дип белдергәннән соң, Г.Ибраһимов бу яктан кызыклы гына аңлатма да биреп уза: “Хәяттә булган бер вакыйга, бер күренеш тәэсире илә аның йөрәген ут ала, рухына ялкын тулып, күңеле ашкына; шуннан соң ул, шигырь чыгаруны уйламастан, үзен-үзе оныткан хәлдә, кулына каләм ала да язарга тотына. Шуннан соң аның укучының рухын да ялкынга әйләндерер дәрәҗәдә куәтле булган шигырьләре туа: килеп чыга “Таң вакыты”, килеп чыга “Авыл”, килеп чыга “Дөньяга”, “Ул”, “Пәйгамбәр” һәм башкалар”[2].

Бу шигырьләрнең барлыкка килүендә куәтле илһам көче тәэсиренең зур булуы әдипне сокландыра. Шунысы әһәмиятле, С.Рәмиев ясалма язмый, аның күңелендә шигырь үзеннән-үзе, аерым вәзенгә салынган килеш барлыкка килә. Ул моңа кадәр татар укучысы укып өйрәнгән гаруз белән дә, халык иҗатына хас силлабик шигырь үлчәмендә дә әсәрләрен кормый, бәлки әлегә барлыгы сизелмәгән-күрелмәгән, ишетелмәгән, әдәбиятта булмаган яңа төр һәм яңа тип үлчәмнәрне таба, алар ашкын бер көч белән ургылучы саф чишмәне дә, шашкын булып агылучы давылны да, кинәт тынып калган дөньялыкны да хәтерләтәләр. Нәкъ менә шушылар аның шигырьләрен сихри һәм тәэсирле итәләр. С.Рәмиевнең хис ташкыны белән язылган шигырьләреннән көчле кайнарлык, шашыну, хәтта “җенләнү” кебек үзенчәлекләргә дә тап буласың. Болар — хис ташкыны, дидек.

Г.Ибраһимовны да шушы хиссилек кызыксындыра. Әмма бу субъектив хис ташкынын объектив дөньяның, тормыш чынбарлыгының шагыйрь күңеленә тәэсире тудыра. “Хәяттә булган бер вакыйга, бер күренеш тәэсире илә аның йөрәген ут

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.5.— Б.77.
[2] Шунда ук.— Б.78.

ала”,— дип аңлата Г.Ибраһимов. Моның ахыры шигырь туу белән тәмамлана. Моны без “әдәби-эстетик танып белү” буларак беләбез. Әдип объектив башлангычның ролен бер дә киметми, әмма шагыйрьләрнең үзенчәлекләрен, чын мәгънәсендә шагыйрь булуларын аларның субъектив, эчке, рухи-мәдәни потенциальләрендә, хисне тасвирлый белү куәтләрендә күрә.

Алга таба Г.Ибраһимов, фикерләре дәлилләп, С.Рәмиевнең шигъриятенә хас үзенчәлекләрне бәян итә һәм ике төп билгесен аерып чыгарып, тасвири рәвештә күрсәтеп уза.

Аның беренчесе моңардан гыйбарәт: “Сәгыйтьнең бу тәэссораты, бу ялкыны артык куәтле таша, күңел чыдамсыз һәм гайре табигый ашкына, шу дәрәҗәдә ки, рухның ул куәтле, хәтта тиле ашкынуын, ниһаятсез куәтле изтирабны[1] икенчеләргә ачык әйтеп бирергә сүз җиткерә алмый, тел аларны матурлап, табигый ясап чыгарырга өлгерә алмый”[2]. Болар белән Г.Ибраһимов С.Рәмиев шигырьләренең хисси тәэсир аркасында тууларын, шул рәвешле бик тә хисле барлыкка килүләрен раслый. Һәм ул хаклы. С.Рәмиев шигырьләре көчле хис ташкынының агышы белән тәэсирле. Хәтта бер хис ташкынын икенчесе алыштырып килә. Бу ташкын киң җәелеп һәм ургылып ага. С.Рәмиевнең шигырьләрен укыганда сулыш кысыла, ә хис агымы һаман көчәя бара.

Бу исә экспрессивлык күренеше. Ул күренешне “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге” болай дип төшендерә: “Экспрессивлык — сәнгатьлелек, тәэсирлелек, тәэсир итүчәнлек”[3]. Бу аңлатма белән Г.Ибраһимовның фикерләмәсе үзара туры киләләр.

Димәк, С.Рәмиев иҗатына, Г.Ибраһимов бәяләмәсенә нигезләнеп фикер йөртсәк, көчле экспрессия хас икән дигән нәтиҗәгә килергә тиешбез. Тагын да шунысын искәртик, Г.Ибраһимов үзе дә язучы, әдип, димәк, С.Рәмиевкә бәя

---

[1] Изтирабны — дулкынлануны.

[2] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.5.— Б.78.

[3] Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: Өч томда / Төзүчеләре — *Абдуллин И.А., Вахитова С.Б., Газизова Ф.М. һ.б.*— Казан: Татар. кит. нәшр., 1981.— Б.564.

биргәндә ул үзенең әдәби-эстетик карашларыннан да чыгып эш йөртә.

Моңа гына карап С.Рәмиевне экспрессионист шагыйрь булган икән дип бәяләргә ашыкмыйк. Татар әдәбияты тарихында ул романтизмның башлангыч вәкиле буларак бәяләнә һәм аның әсәрләр тупланмасын барлап, җыйнап, өйрәнеп бастырып чыгарган зур галим Ш.Г.Садретдинов бу хакта болай дип язган: “Сәгыйть Рәмиев — XX йөз башы татар демократик әдәбияты үсешендә тирән эз калдырган әдипләрнең берсе. Татар әдәбиятында романтизмның башлап мәйданга чыгуы аның иҗаты белән бәйләнгән”[1].

Бу фикер белән тулысынча, бәхәссез килешергә була, чөнки романтизм ул, “Әдәбият белеме сүзлеге”ндә аңлатылганча, “бигрәк тә матур әдәбият өлкәсендә ачык гәүдәләнде. Романтизм язучылары реаль чынбарлыкны үзләренең таләпләре һәм тойгыларыннан, максатларыннан чыгып сурәтләргә, кеше образларын да тормыштагыча түгел, бәлки үзләре уйлаганча күрсәтергә омтылганнар”[2]. Галим А.Әхмәдуллин редакциясендә чыккан “Әдәбият белеме сүзлеге”ндә исә “татар әдәбиятының барлык чорлары өчен дә романтизм юлдаш”[3] дип аңлата. Д.Ф.Заһидуллина да шушы ук фикерләргә таяна һәм: “Романтизм әдәбиятны кешеләргә яшәеш нигезләре хакында сөйләүче, белем-мәгълүмат бирүче дип карый. Сәях образы — мәңгелек буйлап сәяхәт итүче, шушы мәңгелектә үз урынын эзләүче герой өчен тарихи-географик чикләр, бу һәм теге дөнья, өн һәм төш, хакыйкать һәм хыял арасында чикләр җуела. Үткәнне — тарихны идеаллаштыру, экзотик материалга мөрәҗәгать итү, авторның субъектив позициясе ачык билгеләнү, фәлсәфи һәм лирик чигенешләр ясау күзәтелә”[4],— дип яза. Әдәбият теоретигы

---

[1] Татар әдәбияты тарихы: Алты томда.— Т.3.— Б.172.

[2] Әдәбият белеме сүзлеге / Төзүчесе — *Гыйззәтуллин Н.* — Казан: Татар. кит. нәшр., 1958.— Б.142.

[3] Әдәбият белеме сүзлеге / Төзүче-редакторы — *Әхмәдуллин А.Г.* — Казан: Татар. кит. нәшр., 1990.— Б.157.

[4] Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге / Төзүче-авторлар — *Заһидуллина Д.Ф., Әминева В.Р., Ибраһимов М.И. һ.б.*— Казан: Мәгариф, 2007.— Б.165.

Ф.М.Хатипов романтизмны иҗат методы буларак түгел, бәлки иҗат тибы сыйфатында (әдәби иҗат агымы дисәк тә мөмкин) карый һәм: “Романтизм — ул художникның хәятне үзенчә күрү җирлегендә туган үзгә бер дөнья”[1],— дип, фикерен тагын да конкретлаштыра. Әдәбият теоретигы В.Е.Хализев исә романтизмны бары тик романтика чикләрендә генә күзаллый, әдәби агым яки әдәби иҗат методы төшенчәләрен кире кага, романтизм, ягъни романтиканы “авторның эмоциональлек тибы” кысаларында тикшерә, идиллия һәм сентиментализм белән бер яссылыкка куя[2]. Аның фикеренчә, идиллия белән язылган әсәрләр шатлыклы дулкынлану көче белән сугарылалар, сентиметализмда башкалар хәленә керергә омтылыштан туган хиссилек өстенлек алса, романтикага анысы да, монысы да хас, әмма аңарда төрле каршылыклар, борчылулар, авторның “үз эченә чумуы” күзәтелә[3]. Шулай итеп, романтизмны бер төрле галимнәр иҗат тибы буларак, икенчеләре иҗат методы дип, өченчеләре “авторның эмоциональлек тибы” рәвешендә карыйлар. Безнең фикеребезчә, әдәбиятта романтизмның реализмнан аермасы шунда, ул геройны һәм вакыйгаларны “тыштан торып”, “тышкы яктан күзәтү юлы белән” түгел, бәлки “эчтән торып”, “эчке үзгәрешләрен барлау рәвешендә” сурәтли, бу мәгънәдә иҗат юнәлеше яки иҗат принцибы саналырга тиешле. Реалист әдип геройларны һәм вакыйгаларны читтән күзәтүче ролендә тасвирлап яза, эчке дөньяны тышкы сыйфат үзгәреше һәм күренешләр ярдәмендә ача, ә романтик әдип, киресенчә, геройларны һәм вакыйгаларны “эченә кереп” сурәтли, шуның белән хакыйкатьнең чын асылын төшенүенә инанып эш итә. Болар исә төрле стильләрне, эмоциональлек үзенчәлекләрен барлыкка китерәләр. Шулай итеп без романтизмны эчке дөнья аша тышкы дөньяны ачу дип атасак, реализмны тышкы дөньяны сурәтләтү ярдәмендә эчке дөньяны төшенү дип

[1] Хатипов Ф.М. Әдәбият теориясе: Югары уку йортлары, педагогия училищелары, колледж студентлары өчен кулланма.— Казан: Мәгариф, 2000.— Б.243.

[2] *Карагыз:* Хализев В.Е. Теория литературы: Учебник.— 3-е изд., испр. и доп.— М.: Высш. шк., 2002.— С.89–92.

[3] Шунда ук.

белдерәбез. Шушы фикерләмәдән чыгып, С.Рәмиевне берничек тә романтизмның гына вәкиле дип, бер генә төрле бәяләп куя алмыйбыз. Аның иҗаты берничек тә романтизм кысаларына гына сыеп бетә алмый. Ул романтик та, реалист та. Димәк, берсенең генә вәкиле түгел, аның иҗатында алар икесе дә бергә, бөтенлек хасил итеп яшиләр.

Г.Ибраһимов дөрес бәяли, С.Рәмиевнең шигъриятенә көчле хис ташкыны, тәэссорат-эмоциональлек, экспрессия хас, бу фикерен һичничек читләтеп үтеп булмый. XX гасыр башында модернистлар үз язмаларында, “хисле кеше” теориясен калку итеп алга чыгарып, “тәэсирле шагыйрь”нең бөеклеген, аның гына чын шагыйрь була алуын раслый иделәр [1]. Әмма Г.Ибраһимов тормыш дөреслегенең иҗат өчен стимул булуы хакында сүз алып бара. Чыннан да, хакыйкатьне күрергә, аның үзенчәлекләрен тоярга һәрбер кеше дә сәләтле түгел. Әлегә сүз бары шул хакта гына бара. С.Рәмиевнең тоя белүе Г.Ибраһимовны кызыксындыра. Аның кайнар хисләнүен дә ул дөрес таный.

“Язгы ташкында су ничек үзенең мәгъруф юлыннан читкә, һәртөрле юлсызлыкларга китә, Сәгыйтьнең шигърияте дә шулай,— дип белдерә Г.Ибраһимов, С.Рәмиевнең иҗатына хас төп үзенчәлекләреннән булган икенче билгесенә игътибарын юнәлтеп һәм шигырьләрендәге хис ташкынының дәрәҗәсен билгеләп.— Ягъни анлар да, артык тиле куәт белән ашкыну тәэсирендә генә язылганга, юлсызлыкка китәләр” [2]. Сүз, әлбәттә, иң беренче чиратта, рифма һәм ритм бозылу хакында бара. Бу урынлы әйтелгән бәя.

С.Рәмиевнең шигырьләренең төзелеше ул вакыт өчен татар укучысына бөтенләй дә билгеле булмаган калыпка корылганнар. Шагыйрьнең моңа кадәр укучыга яхшы таныш саналган силлабик һәм гаруз шигырь төзелешләренә бөтенләй дә каршы килгән, эчке хис ташкынына корылган һәм сулыш кысылырлык дәрәҗәгә җиткерелеп язылган әсәрләре әдәбиятта яңалыкка омтылуы белән дә бәйле булганнар. Г.Ибраһимов моны ясалма омтылыш дип исәпләми, бәлки

---

[1] *Мисал өчен, карагыз:* Бальмонт К. Горные вершины.— М., 1904.— С.94.
[2] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.5.— Б.78.

шигъри табигатенчә әдипнең шушы рәвешле иҗат иткәнлеген төшенә һәм аңлатып бирә. Шул сәбәпле ул чын шагыйрьнең асылын аның әсәрләрендәге хиснең ялкынлы да, язгы ташкын кебек тә булуыннан күрә. Әдәбиятның хисләр белән эш итүе, хисләрне кузгатуы белән күңелгә үтеп керүе турында гомум билгеле фикерләрне раслап тормаска да мөмкинбез. Әмма хиснең экспрессив формаларда бирелүенә Г.Ибраһимовның игътибар иткәнлегенә без монда аерым тукталып китәргә тиешбез. Ул, бу яктан караганда, үз заманы өчен бөтенләй дә яңача фикер йөртүче буларак күзаллана.

Хиснең яки хисләрнең көчле дулкын рәвешендә шигырьдә һәм гомумән дә әдәбиятта бирелүенә Г.Ибраһимовның төп игътибарны юнәлтүе, М.Х.Хәсәнов билгеләп үткәнчә, "дидактизмга каршы көрәш белән кирәгеннән артык мавыгып китеп"[1] язуыннан килә. Монда, "дидактизм" дигәндә, татар әдәбиятында урта гасырчылыктан ук бик тә актив файдаланылган үгет-нәсыйхәт биреп язу күздә тотыла. Әдәбиятның, бигрәк тә шигъриятнең дидактик формаларга корылуы электән, бигрәк тә суфичылык әдәбиятына хас хикмәтләрдән үстерелеп килгәнлектән, бернинди үзгәрешсез татар әдәбиятында һаман да яшәп кала баруы, коры фикер әйтү һәм шул фикерләрнең бер әсәрдән икенчесенә күчә-күчә кабатлануы әдәби-эстетик торгынлыкка китергән, билгеле. Әдәбиятта дидактизмның алга чыгарылуы, димәк, ул аның үсештә торгынлык чорына килеп керүе дигән сүз дә әле. Шушы мантыйк нигезендә фикер йөртсәк, С.Рәмиевнең хискә корылган шигырьләр язуы тулысы белән яңалык рәвешендә Г.Ибраһимов тарафыннан кабул ителгән, шунлыктан әдип мондый шигъриятне алдынгы, авангард буларак күзаллаган.

Әмма шигырьнең, әдәби әсәрнең хискә корылуы ул әле мәгънәсезлеккә борылуы дигән сүз түгел. Моны Г.Ибраһимов яхшы аңлап эш итә. "Шунлыктан,— дип яза ул,— аның шигырьләре мәгънә, хис һәм шигъриятнең артык голүвияте[2], артык тирәнлеге ягыннан ничаклы кыйммәтле булсалар, тел вә

---

[1] Хәсәнов М.Х. Галимҗан Ибраһимов // Татар әдәбияты тарихы: Алты томда.— Т.3.— Б.345.

[2] Голувияте — бөек уйлары, югары фикерләре.

ләфыз җәһәтеннән караганда шул дәрәҗәдә түбән һәм кимчелекле булалар"[1]. Димәк, С.Рәмиевнең шигырьләре тел һәм сүз ягыннан караганда бик тә түбән һәм кимчелекле икәннәр. Әмма мәгънәдә, хистә һәм шигърилектә бик тә югары кимәлдә язылганнар.

Шигъри теленең табигый булмавын бәяләп, Г.Ибраһимов бу яктан С.Рәмиевне Дәрдемәнд һәм Г.Тукай белән бөтенләй дә якын куярлык түгел икәнлекне аерым басым ясап искәртеп уза [2]. Аның шушы белдергәненә татар әдәбияты тарихы фәнендә бөтенләй дә диярлек игътибар ителми үтелә. Моның ачык сәбәбе дә бар. Укучы Г.Ибраһимовның С.Рәмиевне мактавыннан тәмам хәйранга кала, шуның аркасында аның тәнкыйть сүзләренә игътибар югала. Аннары, тагын да бер сәбәбе, безнең фикеребезчә, Г.Ибраһимовны аңларга омтылудан бигрәк, аның фикерләрен акларга тырышу да әдәбият фәнебездә нык тамыр җәйгән. Югыйсә, "Татар шагыйрьләре"н тәртип белән укыганда, барысы үз урыннарын ала баралар түгелме соң?

С.Рәмиевнең татар шигыренә яңа рух, яңа көч бирүе хакында фикер йөртеп, Г.Ибраһимов хискә корылган әдәбиятны дидактикага, ягъни үгет-нәсыйхәт тезгән әсәрләргә каршы куя, дидек. Әгәр дә аның әдәби әсәрдә хис белән үтә игътибарлы һәм сак эш итәргә тиешлеге хакында әйтелгән тәнкыйть сүзләре урынлы булуга әйләнеп кайтсак, ул шушы фикерләре белән С.Рәмиевне күкләргә чөя дип бер дә әйтә алмыйбыз. Җитмәсә ул аның күп кенә әсәрләрен "шигырьләре рәтеннән юк итәргә кирәк"[3] икәнлеген алдан, сүзе башында ук белдереп куя.

Г.Ибраһимов фикере буенча, С.Рәмиевнең шигырьләре "табигый агымлы" түгелләр[4]. Шушы бәясен биргәндә әдип "аның нәзымнары" дигән терминын куллана. Билгеле булганча, ул шигырь белән нәзымны үзара каршы куя. Нәзым дигәндә тезмә белән язу күздә тотыла, аны һәрбер белемле

---

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.5.— Б.78.
[2] Шунда ук.
[3] Шунда ук.— Б.76.
[4] Шунда ук.— Б.79.

кеше төзи, тезеп яза ала, әмма шигырь дигәндә, ул йөрәктән, кешенең белемле-белемсез булуына бәйсез рәвештә, хис ялкыны буларак, бары тик чын шагыйрь тарафыннан гына тудырыла ала.

Тел һәм сүз җәһәтеннән "табигый агымлы" шигырь нинди була соң ул? Моңа Г.Ибраһимов С.Рәмиевнең "Авыл" һәм "Сызла, күңлем!" кебек шигырьләреннән мисаллар китереп җавап бирә: "Нәкъ көлә, нәкъ елмая, нәкъ юри бәгъреңне өзә" кеби бик гаҗаиб, ят, шуның илә бәрабәр, теләнгән мәгънәне аңлатуда искиткеч муаффәкыятьле[1] булган, яки "Сызла, сызла, сызла, күңлем, сызла бер туктамыйча — сызла айлар, сызла еллар — сызла төн йокламыйча" кеби, рухның чын мәгънәсе илә аңлату өчен әллә никадәрле сәхифәләр кирәк булырлык изтираб[2] вә халәте әләмне[3] бер-ике җөмлә илә гаҗаиб дәрәҗәдә ачык һәм тулы аңлаткан мисрагълар[4] очрый"[5],— ди ул. Димәк, Г.Ибраһимов фикеренчә, тел җәһәтеннән "табигый агымлы" шигырьләр, беренчедән, гаҗәпләндерерлек дәрәҗәдә булырга, ят, ягъни кабатланмаган, тәүге тапкыр әйтелгәндәй тоелырга, шулар белән бергә теләнгән мәгънәне отышлы итеп җиткерергә тиешләр, икенчедән исә, рухның-җанның дулкынлануын-сыкрануын бер-ике җөмлә белән ачык һәм тулы сөйләп-аңлатып бирсеннәр. Башка төрле әйткәндә, шигырьгә "табигый агым" кабатланмас сокландыргыч мәгънә һәм хисне ачык, тулы чагылдырып бирү өчен хезмәт итә икән. Аңлашылып тора, Г.Ибраһимов мәгънә һәм хис бергәлеген туктаусыз үзара бәйләнештә тота, хис агымының мәгънә бөтенлегенә хилафлык китерергә мөмкин икәнлеген С.Рәмиевнең "нәзымнары"на бәйле сөйләп бирә.

"Урманның сикәлтәле юлыннан начар арба өстендә барган адәмнең гәүдәсе ни-нәрсә хис кылса, Сәгыйтьнең бәгъзе бер шигырьләрен укыганда да чын татар, зәвыклы сизгер татар теле шуны тоячак"[6]. Г.Ибраһимовның С.Рәмиев шигырьләренә

[1] Муаффәкыятьле — уңышлы, отышлы.
[2] Изтираб — дулкынлану.
[3] Халәте әләмне — күңел сыкрануын.
[4] Мисрагълар — шигырь юллары, строфалар.
[5] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.5.— Б.79.
[6] Шунда ук.

карата әйтелгән бу фикере зур әһәмияткә ия. Ул аның әсәрләренә хас төп җитешсезлекне төгәл тотып алган һәм аңлатып биргән.

Шушы юлларны укыганда Г.Ибраһимовны С.Рәмиевнең шигырьләренә тәмам мөкиббән киткән дип әйтеп булмавын төшенәсең. Күренеп тора, ул аларны шактый каты итеп тәнкыйтьли.

Шигырьләренә җитешмәгән шул "табигый агым" С.Рәмиевкә әсәрләрен бары тик хис-тойгы стихиясенә бирелеп иҗат итүеннән килә, билгеле. Г.Ибраһимов моны төгәл аңлатып бирә, фикерләрне дәлилсез сөйләми, мисалларны мул китерә. Аларны хәтта, мисал итеп алганда, азмы-күпме тәртипкә китерүләре, төзәтүләре хакында да искәртә әдип һәм, "күрәсез, боларны укып барганда тел "табигый акмый", әле анда, әле монда барып терәлгәндәй, төртелгәндәй була"[1] дип, С.Рәмиев шигырьләрендә рифма-ритм мәсьәләсенең хәл ителми калдырылуына уфтана. Әмма "табигый агымлы" шигырьләрен дә әдип күрми үтми, алар исәбенә "Көлсеннәр", "Таң вакыты" (аның да башы белән ахырын гына), "Авыл", "Пәйгамбәр", "Дөньяга" шигырьләрен кертә[2]. Шулардан соң, кабат нәтиҗәгә килеп, үзенең әдәби-эстетик карашларын конкретрак белдереп куюны кирәк таба һәм кабат "нәзыйм" һәм "шагыйрь" төшенчәләренә килә.

Нәзыйм дип ул сүзләрне тезмәгә салучыларны, ягъни тезмә белән язып "шигырь ясаучыларны" атый, "яздыклары чын вә куәтле шигърият белән тулган"нарны шагыйрь дип билгели[3]. Димәк, Г.Ибраһимов фикеренчә, тел җәһәтеннән караганда камил һәм матур тоелган шигырьләр алар асыллары белән нәзымчылыктан, шигырь төзи белү осталыгыннан килә, ә чын шагыйрьдә исә сүзләр камил һәм матур булып та бетмәскә мөмкиннәр, әмма алар шагыйрьнең йөрәгеннән кайнап чыгалар, аның хис-тойгылары белән өртелеп туалар. "Сәгыйть начар нәзыйм булыр,— ди ул,— мин аңа карышмыйм, хәтта

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.5.— Б.79.
[2] Шунда ук.— Б.79-80.
[3] Шунда ук.— Б.80.

тәсдыйкъ итәм, әмма аның яздыклары чын вә куәтле шигърият белән тулган"[1].

Г.Ибраһимовның төп тикшерү объекты, үзе белдергәнчә, "зарурәте шигърия", ягъни "шигъриятнең асылы". Аның нинәрсә икәнлеген тәнкыйди фикерләре белән янәшәдә туктаусыз кузгатып бара ул. Аны әле аңларга теләү, әле белгәнен төшендереп бирү омтылышы били. Кайвакытта алар зур мәсьәләгә әверелә һәм Г.Ибраһимов әдәби тасвир ярдәмендә сурәтләүләргә дә күчәргә мәҗбүр була.

Укучы алдында "Шагыйрь кем?" "Шигырь нәрсә?" кебек сораулар конкрет, ныклы итеп куела. Боларга җавап бирү эшенә керешеп, Г.Ибраһимов бу тезисны алга чыгара: "Бездә шигырь белән нәзымны[2], шагыйрь белән нәзыймны һаман бутыйлар"[3],— ди. Шуннан соң гына шигырь нәрсә һәм нинди булырга тиешлекне төгәл аңлатып бирә: "Безнең рух вә хыялымызга тәэсир итәчәк, хиссиятемезне, тәэссоратымызны кузгатачак һәрбер нәрсә — шигырь"[4]. Димәк, шигырь ул, Г.Ибраһимов таныганча, рухыбызга һәм хыялыбызга тәэсир итә, бу — беренчедән, ә икенчедән, хисләребезне һәм тойгыларбызны кузгата. Бер фикер тирәсенә җыеп әйткәндә, шигырьне хис-тойгыларга корылган булырга тиеш, шигырь гомумән дә хисләрне тасвир итүдән тора дип әйтә алабыз. Әмма бөтен әдәбият-сәнгатьнең хис-тойгыларны сурәтләүгә корылуын исәпкә алсак, Г.Ибраһимовның фикерләрендә әллә ни яңалыкны тапмабыз. Әгәр дә инде татар әдәбиятының дидактик юнәлештә иҗат итүне урта гасырлардан бирле яшәтеп, үстереп килгәнлеген, башка төрле, ягъни чын, хис-тойгыларны сурәтләүгә корылган сәнгати әдәбиятны татар укучысы танымавын һәм бидгать, бозыклык, шайтаный гамәл дип санавын искә алсак, әдипнең ул фикерләренең тарихи-мәдәни яктан әһәмиятләре гаҗәеп югары икәнлеген дә төшенербез. Хәер, дидактик шигърият кысаларында талантлы шагыйрь тарафыннан язылган әсәрләр кайсы укучыны

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.5.— Б.80.
[2] Нәзымны — тезмәне.
[3] Шунда ук.
[4] Шунда ук.— Б.81.

дулкынландырмый калдырырлар икән, дибез. Дөрес сорау. Моңа да нәкъ Г.Ибраһимовча җавап бирергә кирәк: тәэссоратсыз әсәр талантлы була алмый.

Монда һичбер теоретик хата күренми. Шигъри әсәргә анализ биргәндә, без аны хис берәмлекләренә таркатабыз, шул хис берәмлекләрен аңлатуыбыз исә шигырьне төшенүебез дигән сүз.

Билгеле булганча, чәчмә әсәрләр, ягъни эпос-дастан төренә караган әсәрләр хисне сюжетта тасвирлауга корылалар, драма төренә караган әсәрләр исә хисне драматик ситуацияләрдә тудырудан гыйбарәт булалар. Әмма ни өчен прозаик, чәчмә әсәрләр язучы Г.Ибраһимов шигърилеккә игътибар итә соң? Ул да булса бик гади, аны прозада хисне бирү юллары кызыксындыра. Моны әдип шигырьләрне өйрәнү аша ачып бирә аласын аңлап эш итә.

"Шигырь телдән яки гакыл вә зиһеннән түгел, бәлки адәмнең рухыннан, күңеленнән, хыял вә хисеннән туа"[1],— ди ул. Димәк, Г.Ибраһимов фикеренчә, шагыйрь акылга һәм зиһенгә таянмый, бәлки хисләренә таяна. Ә хисләрнең чыганагы — күңел, кешенең рухы. Монда тагын да хыял хакында әйтелә.

Моңа кадәр без дә хыял мәсьәләсенә аерым игътибар бирмәскә тырыштык. Сәбәбе гади иде: әдипнең шигырьне хис-тойгыларга бәйләп каравын төгәлрәк төшенү өчен башка юл күренмәде. Инде хыял мәсьәләсен киңрәк карый алабыз.

Хыял дигән вакытта күп очракта романтиканы, романтизмны күздә тоталар. "Татар теленең аңлатмалы сүзлеге" аның ике мәгънәсен бирә, беренчесе — романтизм төшенчәсенә бәйле, диелә, икенчесендә: "Берәр нәрсәгә карата эмоциональлек, күңел күтәренкелеге тудыра торган, кешене алга әйдәүче хисләр, фикерләр һ.б."[2], диелә. Романтизмга аңлатма биргәндә, өченче мәгънәсе буларак, болай дип язылган: "Романтиклык, чынбарлыкны идеаллаштыру, хыялга (тойгыга, хискә) бирелү хәле"[3]. Болардан аңлашылганча,

---

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.5.— Б.81.

[2] Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: Өч томда.— Т.II.— Б.598.

[3] Шунда ук.

романтика-романтизм ул әле хыял гына түгел, бәлки чынбарлыкны идеаллаштыру да икән. Димәк, чынбарлык идеаллаштырылган вакытта гына романтика барлыкка килә. Болардан романтизм әсәрләре чынбарлыкны идеаллаштыруга корылган булырга тиешләр икәнлеге конкрет аңлашыла башлый. Ә чынбарлыкны безнең хыял һәм теләкләребез генә идеаллаштыруга сәләтлеләр. Язучының зиһене һәм акылы реаль тормышның дөреслеген аңламый һәм төшенми калмый. Әмма ул да, шушыны аңлавыннан китеп, тормыш дөреслегеннән читләшә, аны идеаллаштыру юлына баса ала. Моның өчен аңа үзенең рухи теләк-омтылышлары ярдәмгә килә, бигрәк тә идеология басымы дәвере буларак тарихка билгеле Совет (коммунистлар) чорында эшнең шушылайрак торганлыгы яхшы мәгълүм. Әмма тормышны ничек идеаллаштырып була соң? Әлбәттә күңел дөньясын сурәтләү аша, чөнки күңел, рухи дөнья, камилме ул, түгелме,— барыбер дә идеал дөнья. Тик күңел дөньясы белән тышкы чынбарлык, нинди генә камил рухи дөньяга ия булмыйк, барыбер дә үзара туры килеп бетмиләр. Өметләр акланмый калырга мөмкин, хыял канатлары да каерыла. Мондый вакытта хис-тойгылар тумыймы? Туа, билгеле. Димәк, хыялга бирелү, хыял дөньясы ул турыдан-туры бары тик романтик дөнья, романтика күренеше генә дә түгел.

Хыял төшенчәсенә шул ук “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге” дүрт төрле аңлатма бирә: “**1.** Чынбарлыкта булмаган, ләкин уйда, күңелдә фантазия белән туган нәрсә. **2.** Чынбарлыкта яши дип күз алдына китерелгән нинди дә булса образларның уйда, күңелдә барлыкка килү процессы. **3.** Күңел теләгән һәм бик мавыктыргыч уй, фикер турында: теләк, өмет; омтылыш. **4.** Тормышка, гамәлгә ашмаслык, тормышта булмаган берәр нәрсә турында буш уй; уйдырма”[1].

Әмма әдәбият аллегорияләр һәм символлар, образлар белән эш итә. Әгәр дә С.Рәмиев “Таң вакыты” шигырендә хатаның тамыры тирәндә булуны, зур булып үсеп китеп, яфраклары коелмый каплап торулар хакында яза икән, бу бит хыялый агач түгел, бәлки борынгыдан килгән татарның хатасы

[1] Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: Өч томда.— Т.III.— Б.376.

хакында образлы-символик фикерләүнең нәтиҗәсе. Монда без аны агач кебек итеп күз алдына китерә алабыз. Бу яфрагын да какмыйча каплап торучы, тамырларын тирәнгә җибәргән хатаны, ягъни наданлыкны, кояш яктысыннан каплап торучы агач кебек итеп аллегорик күзаллаудан барлыкка килгән символ-төшенчә буларак кабул итәбез. Һәм хыял дияргә хакыбыз бармы? Әллә бу хыяллаумы?

Хыяллау сүзен шул ук “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”, бер генә төрле итеп, “уйлау, күз алдына китерү” [1] дип төшендерә, ә хыяллануны “**1.** Хыялга бирелү. **2.** Акылын җую; зиһене, акылы зәгыйфьләнү”[2] дип белдерә, икенче аңлатманың гади сөйләмгә хас аңлау тәртибендә икәнлеген дә ассызыклый.

Болардан чыгып, Г.Ибраһимовның хыял хакында әйткәннәрен без хыяллау белән, ягъни уйлау һәм күз алдына китерү белән бәйләргә тиешбез. Әгәр дә хыялга бирелү хакында сүз барса, ул очракта без хыялның чикләрен ачык күз алдына китермичә, реаль дөньядан тәмам аерылып, фантастик өметләргә бирелеп, саташуга кадәр җитүне истә тотарга тиеш булачакбыз. Андый хыяллануны шайтаный хыял дияргә мәҗбүрбез.

Шагыйрьнең хыялы — уйлау һәм күз алдына китерүдән гыйбарәт икәнлеген Г.Ибраһимов үзе болай итеп аңлатып бирә: “Әнә сызылып таң ата. Әнә дөньяны нурына, җәмаленә хәйран итеп кояш чыга. Әнә бөтен дөньяны матурлыгы, лятафәте[3] кашында сәҗдә иттереп яз килә. Менә су өстләрен һәм дөньяның ярты ягын алсу-кызыл, ләкин гаҗаип мөәссир[4] утка күмеп кояш бата. Әнә сулар, асыл чәчәкләр, әнә матур болыннар, таулар, урманнар. Әнә табигатьнең җәмаленә гыйшкыннан чыдый алмыйча сандугач сайрый башлый. Әнә моң, мөәссир музыка уйный. Әнә җәмал вә голүвияте [5] кашында мең мәртәбә сәҗдә итәргә риза булган синең җанашың, үзенең озын керфекләрен сузып, ялкынлы күзләре илә сиңа сөеп карый да бөтен дөньяны онытгырачак рәвеш илә

[1] Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: Өч томда.— Т.III.— Б. 376.
[2] Шунда ук.
[3] Ләтавәте — гүзәллеге.
[4] Гаҗаиб мөәссир — бик тә тәэсирле.
[5] Җәмал вә голувияте — чибәрлек һәм күркәм уйлары.

бер елмая. Көннәр кичә, син аның илә үпкәләшәсең, аерылышасың-аерыласың... Бер адәм шул таңнар, шул табигатьләр, шул җанашларны күрә, рухында ялкын, дулкын күтәрелә — моң, мөтәәссир... Тота да шул ялкынны, шул тәәссерне, шул табигый сәвекъ илә[1], матурлап язып чыгара. Шуннан килеп чыга шигырь"[2],— ди.

Әдип хыял һәм хис бердәмлегенең шигырьгә ничек әверелүен һәм аңа кагылышлы ни-нәрсәләр әйтергә теләгәнен менә шушы нәсере ярдәмендә сурәтләп аңлатып бирә. Монда да, хыял дигәндә, шулай ук күз алдына китерү, уйлау хакында сүз бара, ул хыяллау төшенчәсенә туры килә.

Әмма хыяллау сүзе әдәби телебездә бөтенләй диярлек кулланылмый һәм тел табигатебезгә ят кебек тоела. Хыялга бирелү дигәнебез уңайлырак та, табигыйрәк тә сыман. Хыял дип без, Г.Ибраһимовтан аңлашылганча, уйланган, күз алдына китерелгән тәэсирле вакыйга-күренешне атарга тиешбез.

Әдип әдәби хыял һәм иҗатта аңарга таяну турында тагын да бер "икенче төрле" нәсер бирә: "Күрәсең адәмнәрнең хәзерге яисә тарихи хәятләреннән бер вакыйга, бер күренеш. Бу ни белән булса да сиңа охшый, сиңа йә шатлык, йә кайгы вә яки башкача бер тәэсир бирә. Син тотасың да шул тәәссерең, шул дулкының тәэсире астында шул вакыйга, шул күренешне матурлап, гүзәлләп тасвир кыласың. Шул тормыштан алынып, кәгазьдә җанлы, тере бер тасвир, бер күренеш килеп чыга. Ул йә матур, йә ямьсез — ничек кенә булса да, укучының хыялына яңа бер галәм китереп, каршысына җанлы ләүхә бастыра, һәм үзе мөәссир дә, куәтле дә була"[3].

Бу юллардан аңлашылганча, сүз гадәти хыял хакында гына бармый. Әдип әдәби иҗатта этәрүче хыял турында фикер йөртә. Шушындый әдәби хыялны ул "менә бу да шигырь була"[4] дип белдерә. Әдәби хыялның ничек кәгазьгә әдәби әсәр буларак төшүе процессына җентекләп бирелеп тормый. Әмма аның әсәр туудагы роленең әһәмиятен ачык күзаллап яза.

---

[1] Табигый сәвекъ илә — табигый дәрт белән.
[2] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.5.— Б.81.
[3] Шунда ук.— Б.81-82.
[4] Шунда ук.— Б.82.

Г.Ибраһимовтан аңлашылганча, тормыш факты әдипнең күңеленә тәэсир итәргә, шул тәэсир вакытында әдәби хыялы кузгатылырга, ягъни әдәби күзаллавы барлыкка китерелергә тиеш. Шушы әдәби күзаллау иҗат процессында, әдәби әсәр тууда төп рольне башкара. Шагыйрь бу әдәби күзаллавы аркасында тәэсирләнә, ягъни күңелен хисләр белән баета һәм шушы күзаллавын кәгазьгә төшерә, шулай әдәби әсәр туа.

Г.Ибраһимов әдәби хыялның чикләрен әдәби әсәр тудыра алу көче белән генә дә, әдәби әсәрнең барлыкка килүе белән генә дә чикләми, мәсьәләне тагын да алга таба үстерә. Әдипнең әдәби иҗатта төп максаты, аның фикеренчә, әсәр язуда гына түгел, бәлки "укучының хыялына яңа бер галәм китереп, каршысына җанлы бастыра"[1] алуда. Димәк, әгәр дә язылган әсәр укучының күңеленә, хисләренә тәэсир итә алмый, аның хыялында тасвирланган күренешләрне барлыкка китерми, сурәтләнгән вакыйгаларны җанландыра-сынландыра алмый икән, андый әсәрне шигырь дип булмый, ул нәзым гына. Бөтен хикмәт тә әдәби хыялның хисләргә тәэсир итә алу көчендә. Аннары, әдәби әсәрнең яңа бер дөнья тудыруы, тудырырга тиешлеге хакында да ул дөрес әйтә.

Чын шагыйрьләр буларак Пушкин, Лермонтов, Байрон, Гёте исемнәре китерелә. Г.Ибраһимов аларның табигатьтәге-тормыштагы вакыйга-күренешләрдән тәэсирләнеп, шул тәэсир белән күңелләрендә матурлык тойгылары һәм изге уйлар туып, шулар аркасында "шигъри ят кайнаган"[2] әсәрләрен иҗат иткәннәрен яза. Хикмәт әдәби хыялда гына да түгел, бәлки шул хыялның гүзәллегендә һәм изге, бөек уйлар белән тулы булуында да икән. Әгәр дә әдәбиятта кемнеңдер шагыйрьме-түгелме икәнлеген бәяләргә кирәк булса, менә шушы әдәби хыялының дәрәҗәсенә, аңарга тулган гүзәллек һәм изге, бөек уйларга, хис-тойгыларга әсәре баймы-юкмы икәнлегенә игътибар итәргә кирәклеге хакында искәртеп, моны Г.Ибраһимов тәнкыйтьнең бердәнбер үлчәве буларак билгеләп үтә. Шуның белән ул әдәби тәнкыйтьнең төп бәяләү принцибын төгәл ачыклый һәм: "Шул үлчәүне кулга тотып,

---

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.5.— Б.82.
[2] Шунда ук.

Сәгыйтьнең шигырьләре эченә кереп китәбез",— ди. Димәк, әдәби әсәрне ул яңа мәгънәләр тудырудан, укучыда изге хисләрне тәрбияләвеннән башка күз алдына да китерми. Шулай итеп әдәбият, Г.Ибраһимов аңлаган һәм аңлатканча алсак, тормыш чынбарлыгын яңа әдәби дөнья иҗат итүе аша чагылдыра, шулай матурлык тудыра һәм кешенең хис-тойгыларын тәрбияли.

Әдип, һәрбер шагыйрьнең табигате матурлыкка дан җырлаудан, матурлык алдында тез чүгүдән гыйбарәт икәнлеген искәртеп, С.Рәмиевтә мондый сыйфат "бик тирән куәт илә бар" [1] дигән фикерләмәгә туктала. Шагыйрьнең шигырьләре, аларда күтәрелгән һәртөрле темаларның укучыны тәэсирләндерүе мәсьәләсе аны даими җәлеп итә. Моны шагыйрьнең табигатькә һәм табигыйлеккә, матурлыкка соклануыннан күрә. "Бу җәмал, бу күрек аның рухын шулкадәрле югары, якты, киң галәмгә ашыра ки, аның бу мәүзугъта [2] язган шигырьләрен укыганда, үзең дә, бер генә минутка булса да, рухның күтәрелүен, каршыңа матур күренеш килеп, шуннан күңелеңә шатлык йөгергәнен сизенәсең"[3],— ди. Моның дәлиленә мисал итеп С.Рәмиевнең "Авыл" шигыре алына, аның шигъри юллары анализлана. Әдип бу әсәрнең укучы күңеленә көчле тәэсир ясау сәбәпләрен тикшерә, әдәби хыял ярдәмендә тасвир тудыра алуына, ул тасвирның бик тә гүзәл килеп чыгуына, шушы матурлык хисләрне кузгата алуга әһәмият бирә һәм мондый шигырьнең "тиңдәшен табарга мөмкин түгел" [4] дип нәтиҗә чыгара. Г.Ибраһимов бу шигырьне, фәнни нигездә караганда дип, "идиллия"гә ачык мисал буларак та бәяли. "Мин үләм" шигырен дә шундыйлар исәбеннән саный.

Шушылардан аңлашылганча, С.Рәмиевнең иҗатын Г.Ибраһимов "идиллия" белән бәйли, бер генә тапкыр да аны романтик шагыйрь буларак бәяләми. Әдәбият теоретигы В.Е.Хализев идиллияне, авторның эмоциональлек тибы

---

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.5.— Б.82.

[2] Мәүзугъта — темага.

[3] Шунда ук.

[4] Шунда ук.— Б.83.

буларак, сентиментальлек һәм романтика белән бәйләнештә карый[1]. Бу хакта инде искәрткән идек. “Идиллическое в литературе составляет не только сравнительно узкую область изображения жизни безмятежной, созерцательной и счастливой,— дип яза ул,— но и безкрайне широкую сферу активной, действенной устремленности людей к упорядочиванию и гармонизации их собственной жизни, без чего реальность неминуемо скользит в сторону хаоса”[2].

Әдәбиятта романтикага килгәндә, В.Е.Хализев аны болай дип аңлата: “Романтикой принято называть умонастроение, с подъемом чувства личности, полной душевного бытия, верой человека в собственные безграничные возможности, с радостным предчувствием осуществления самых высоких, сокравенных желаний и намерений”[3].

Димәк, идиллия дигәндә, бәхет-бәхетлелек тою хисе күздә тотыла, романтика дигәндә исә, аңардан аермалы буларак, шатлык-сөенеч хисе әйдәүчегә әверелә. Беренче очракта хисләр гармониягә омтылу белән бәйле булса, икенче очракта, романтикада, хисләр шәхеснең үз көченә ышануы һәм изге хыялын тормышка ашыруга омтылышы шатлык-сөенеч тойгысына әверелдерелә. Шулай итеп, бәхет гармониясе идиллия әсәрләренә хас булса, хыялны тормышка ашыруга омтылышлы шатлык-сөенеч стихиясе романтиканы барлыкка китерә. Асылда идиллия төшенчәсе булдырган-булган белән канәгатьлек итүдән бәхет тойгысы уянуны аңлата, романтика дип көрәш һәм җиңү пафосын, тантанасын кичерүдә рәхәтлек хисе тууга бәйле тойгыларга әйтелә.

“Әдәбият белеме сүзлеге”ндә идиллия терминының әдәби жанр буларак төшенчәсе алына, аны антик чор грек шагыйрьләре көтүчеләргә һәм гади кешеләргә багышлап язганнар, “табигатьнең гүзәллеген һәм авыл кешеләренең табигать кочагында тыныч һәм җай гына гомер кичерүләрен тасвирлаганнар”[4], диелә. Романтикага килгәндә, аны шушы ук

---

[1] Хализев В.Е. Теория литературы.— Б.89-92.
[2] Шунда ук.— Б.90.
[3] Шунда ук.— Б.91.
[4] Әдәбият белеме сүзлеге / Төзүче-редакторы - *Әхмәдуллин А.Г.*— Б.55.

сүзлек болай дип аңлата: “Художестволы иҗатта уй-хыялларны, дәртле омтылышларны, идеалларны раслауга юнәлдерелгән рухи күтәренкелек, югары *пафос*”[1]. Болардан да шул ук бәхет гармониясенең идиллия булуы, хыялларны тормышка ашырырга омтылышның романтика икәнлеге ачык аңлашыла.

Шушы фикерләмәләрдән чыгып, романтик әсәрләргә рухи омтылыш хас, идиллия әсәрләренә канәгатьлек белән яшәү хисе төп үзенчәлек дип әйтә алабыз. Димәк, идиллия белән язылган шигырьләрдә лирик герой булганы белән канәгать итсә, шушы бәхет гармониясен урнаштырырга һәм сакларга омтылса, романтик әсәрләрдәге лирик герой үз көченә ышана һәм хыялын тормышка ашырырга җан ата булып чыга. Аның берсе булганы-барына риза, икенчесе үзгәрешләргә ашкына, гыйсьянчы.

Г.Ибраһимов исә, шулай итеп, С.Рәмиев шигъриятен идиллия белән бәйләп, аның лирик героен да барына, булганына риза буларак бәяли түгелме соң? Димәк, ул аңарда романтиклык та, романтизм да күрми булып чыга.

Г.Ибраһимовның С.Рәмиев хакында тәфсилләп бәян ителгән фикерләреннән чыгып, без шундый нәтиҗәләргә килергә мәҗбүрбез: беренчедән, ул, мәгънәле һәм җитди фикерләмәләр төзеп, “Татар шагыйрьләре” хезмәтендә шигырьнең төп корылмасы итеп хисне һәм аның үзгәрешен билгели, икенчедән, хыял турында сөйләгәндә, ул әдәби хыял, ягъни әдәби күзаллау хакында яза, өченчедән, С.Рәмиев шигырьләренең идиллиягә корылган булуын ачыклый.

Алга таба фикерләрен ул мондый тезис белән дәвам итә: “Шагыйрь, әгәр дә ул чын мәгънәсе илә шагыйрь булса, шөбһәсез, хиссият колы” [2],— ди һәм хисләрнең сыйфаты хакында сөйләүгә күчә. Аларны Г.Ибраһимов ачыга һәм татлыга бүлә. Бу хисләр шагыйрьдә яки нәфрәт, яки шатлык тудыралар, ягъни аның мөнәсәбәтен барлыкка китерәләр, ди.

Беренче хис итеп Г.Ибраһимов мәхәббәтне ала. Мисалга Йосыф һәм Зөләйха гыйшкы китерелә, һәр шагыйрьнең үз

[1] Әдәбият белеме сүзлеге / Төзүче-редакторы - *Әхмәдуллин А.Г.*— Б.158.
[2] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.5.— Б.84.

Зөләйхасы булуы искәртелә, шушы мәхәббәт аның өчен “хәят чишмәсе” [1] булып тора, илһам чыганагы санала, ди. Шагыйрьнең мәхәббәтен Г.Ибраһимов: “Сөйгән яр”, “сөю-сөелү” мәсьәләсенең шигырьдә бик еш очравына мода яки гадәт дип түгел, табигать теләве, шагыйрьлек бәласе дип карарга тиеш”[2], дип аңлата. Илһам чыганагы буларак, сөйгән ярының матурлыгы, аңа карата булган хисләренең илаһи гүзәллек белән тасвир ителүенә мисаллар дөнья әдәбиятыннан китерелә. С.Рәмиевнең “Ул”, “Бер кеше” шигырьләре дә шулар исәбенә кертелә. “Ул” шигыренең русчадан тәрҗемә ителсә дә оригиналыннан күпкә яхшырак килеп чыгуы әйтелә. Шигырьләргә аерым-аерым анализ ясалып, шушы рухтагы башка әсәрләре барлыгы да искәртелә. “Перчатка” шигыре тикшерелә, мондагы күз алдына китерерлек дәрәҗәдә эшләнелгән оста тасвирлар мактала.

Икенче хис итеп Г.Ибраһимов аһ-зарны ала. Аның тормыштан канәгать булмаудан тууын аңлатып уза. С.Рәмиевтән “Дөньяга”, “Минем төн” шигырьләрен мисалга китерә. Төп игътибарны хиснең көчле бирелүенә һәм аның ясалмалыкмы-түгелме икәнлеген ачыкларга кирәклеген төшендерүгә юнәлтелә. Шигырьнең ясалма түгеллеген белү өчен шагыйрьнең аны “үзе хис кылган рәвешчә чыгаруы”[3]на бәйләп бәяләү юлы барлыгын да искәртә.

С.Рәмиев шигырьләрендә зар-интизар гына түгел, хәтта нәфрәтнең дә яшерелмичә сурәтләнелүе әйтелә. Моңа мисал буларак Г.Ибраһимов “Дөньяга” шигырен китерә һәм: “Ул дөньяга да, адәмнәр өстенә дә “ләгънәт күле” сибә, аларны ачы, усал сүзләр илә каргый, хурлый”[4],— дигән фикер уздыра. Кабат аһ-зар хисе мәсьәләсенә кайтып, Г.Ибраһимов нәфрәт хисен аһ-зар белән бәйли, аларның бер-берсенә күчүләрен ачыклый. С.Рәмиев шигырьләрендәге лирик геройның үз-үзен аһ-зардан, нәфрәттән юатуын дөньядан үч алуга омтылышына нисбәттә карый.

---

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.5.— Б.85.

[2] Шунда ук.

[3] Шунда ук.— Б.90.

[4] Шунда ук..

Г.Ибраһимов алга таба тукталган асыл фикерләрендә С.Рәмиевнең шагыйрь буларак мөстәкыйльлегенә, башкаларга иярмәвенә, халыктан һәм мохиттән үзен өстен куюына игътибар итә. Аның хакында: “Дөньяның бөтен гадәт, әдәп вә низам дип йөртә торган нәрсәләренең һәммәсеннән аша сикерә, дөньяга хөррияте шәхсияне ниһаясез югары вә мөкаддәс урынга куеп, үз хисе вә үз уена башка булган һичбер нәрсә илә хисаплашмый торган адәмнәрдән бередер”[1],— дип язып, хөр күңелле, үзенчәлекле шагыйрь булуын дәлилләп аңлата, фикерләренә дәлилгә “Мин” шигыреннән бер куплетын мисал итеп китерә. Моның татар халкы өчен көтелмәгән, табигый булмаган хәл икәнлеген дә әйтеп узуны кирәк таба: “Шундый куәтле бер сүзне күңеле төшкән, рухы үлгән, йөрәге хәлсезләнгән безем кеби татар халкыннан берәүнең әйтә алуы, чыннан да, уйланмаган, өмид ителмәгән бер гаҗибәдер”[2],— ди.

С.Рәмиевнең идеалист шагыйрь булуына Г.Ибраһимов аерым туктала. Әмма фикерен киңәйтүне, мәсьәләне төшендереп аңлатып узуны кирәк тапмый. Ахырда “Таң вакыты” шигыренә кабат килә һәм аның эчтәлеген ачыклау эшенә керешә. Татар халкы таң вакыты кебек бер дәвердә яшәгәнен билгеләгәч, Г.Ибраһимов, шушы чорны (XX йөз башын, әлбәттә) “безнең халыкның гасырларча дәвам кылган йокысыннан, өстен каплаган кара төннән яңа дөньяга, якты кояшлы мәдәният галәменә чыгарга торган заманы”[3] буларак белдерә. Шагыйрь белән тулысынча килешеп, бу уяну дигәннәренең инде мәгърифәтле анадан яңадан туугa бәйле, ягъни татар халкының уянуын мәгърифәткә омтылышыннан күрә. С.Рәмиевкә багышланган фикерләрен шуның белән тәмамлый, алга таба Дәрдемәнднең шигырьләренә күчүче яңа бүлекне ача.

Шулай итеп Г.Ибраһимов С.Рәмиевнең шигырьләренең хис ташкынына корылганлыгына, аларда әдәби хыял-күзаллау көчле булуга төп игътибарын юнәлтә. Бу исә әдипнең үз

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.5.— Б.92.
[2] Шунда ук.
[3] Шунда ук.— Б.93.

әдәби-эстетик карашларын да ачыкларга ярдәм итә. Аның карашында С.Рәмиев идеалист, идиллия шагыйре булып гәүдәләнә. Хис ташкынына килгәндә, аларның арасыннан Г.Ибраһимов мәхәббәт хисе, һәм тормышка нәфрәт белән өртелгән аһ-зар хисен аерып чыгара. Шушылар белән С.Рәмиевнең кабатланмас, баш бирмәс рухлы, алдынгы фикерле шагыйрь икәнлеге ачыла. Аның баш бирмәс рухлы булуыннан ул гыйсьянчылык һәм романтик омтылышлар күрми, болар хакында сүз дә алып бармый.

Ә безнең XX йөз урталарыннан татар әдәбияты фәне С.Рәмиевне гыйсьянчы, романтизм вәкиле шагыйре дип белгеләп хаталанмыймы?

Г.Ибраһимовның С.Рәмиев иҗатында романтиканы күрүе хакындагы хаталы фикер әдәбиятыбыз белемендә урнашып калуның сәбәбе “Татар шагыйрьләре” хезмәтенә ясалган аңлатмаларга да бәйле. “Ибраһимов, татар тәнкыйтендә беренче буларак,— дип яза, мәсәлән, М.Х.Хәсәнов том артындагы “Искәрмәләр” өлешендә,— Рәмиев һәм Дәрдмәнд поэтик талантының романтик үзенчәлеген ачып бирде”[1].

Мөгаен С.Рәмиевнең гыйсьянчылыгын, хөр рухлы шагыйрь булуын ассызыклавы аркасында Г.Ибраһимовның фикерләре шулай кабул ителгәндер? Әмма хөр рух, рухның тантанасы идиллиядә юкмыни?

Бәлки без С.Рәмиевтә гыйсьянчылык күреп ялгышмыйбыздыр? Әмма Г.Ибраһимов С.Рәмиев иҗатында гыйсьянчылыкны да күрми, ул хакта хәтта сүз дә алып бармый, бәлки “хөррияте шәхсия” турында гына искәртә, гадәт, әдәп һәм тәртип кануннарыннан үз рухын өстен куюын яза.

С.Рәмиевнең лирик герое иҗтимагый кануннарны ватмый, җимерми, аңарга бөтенләй омтылмый да. Ул бары тик аларның “хөррияте шәхсия” каршында чүп кенә булуларын раслый, шуңа күрә дә “Мин” шигырендә:

“Мин!” димен мин, “мин” дидисәм,
Миңа бер зур көч кирә,

[1] Хәсәнов М.Х. Галимҗан Ибраһимов // Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. — Т.3.— Б.347.

Аллалар, шаһлар, кануннар
Булалар бер чүп кенә,—

дип белдерә.

Монда Аллаһыга каршы сүз әйтелми, билгеле, бәлки ирекле шәхес рухының бөеклегенә, тантанасына дан җырлана.

Г.Ибраһимов шуның өчен дә бу мәсьәләне аерым алып, конкретлаштырып, С.Рәмиевне идеалист дип атый. Идеалист шагыйрьгә гыйсьянчылык билгеләмәсен тагып буламы икән?

С.Рәмиев шигъриятенең хис ташкынына корылганлыгы мәсьәләсенә кире кайтып, моның сәбәпләрен искәртеп үтми мөмкин түгел.

Аңарда хис ташкыны эчке экспрессия тудыра. Моны Г.Ибраһимов дөрес төшенеп алган. Әмма бу экспрессия, хисләрнең ташкыны, романтик планда бирелмәгән, бәлки идиллия, ягъни хөр рухның өстенлегенә бәйле канәгатьлек тойгысына корылган. С.Рәмиевнең лирик герое менә шушы хиссият дөньясына чума һәм аның кысаларында яши, шуңа күрә дә ул, мәсәлән, “Пәйгамбәр”дә: “Бөтен җиргә мәхәббәт орлыгын сач!”,— дип, шигырен чакыру белән тәмамлый, ә “Таң вакытында”: “Тугъ яңадан мәгърифәтле анадан... Бул кеше, үзең тырыш... Хата ул коры өмид Алладан!”,— дип белдерә. Болар үгет-нәсыйхәт түгел, болар — шигъри шигарь! Монда Аллаһыга каршы сүз әйтелми, бәлки Аллаһыдан өмет итеп утырмыйча, үзеңә тырышырга кирәклек хакында сүз бара. Болар барысы да С.Рәмиевнең лирик героена рухи хөрлек хас булу хакында сөйли торган аерым дәлилләр. Менә шушы рухи хөрлек һәм аның дөньяда урнашуы шагыйрьгә чын бәхет буларак тоелалар.

“Идиллические ценности и воля к их воплощению широко и многопланово запечатлены русской литературой XIX в.”[1]— дип белдерә В.Е.Хализев. Рух хөрлеге шушы идиллик кыйммәтләрнең асылы булып тора да инде. ХХ йөз башы татар әдәбияты өчен бу үзенчәлекләрнең бик тә хас булганлыгын да әдәбият тарихыннан яхшы беләбез.

[1] Хализев В.Е. Теория литературы.— Б.90.

Г.Ибраһимов XX йөзнең беренче чирегендә яшәп иҗат иткән иң көчле һәм данлыклы классик әдипләребезнең берсе, татар әдәбияты үсешенә иң зур өлеш керткән язучы. Болар һичшиксез бәхәссез. Шулар белән бергә, инде аңлашылганча, әдәби иҗатка ул ныклы теоретик һәм тәнкыйди әзерлек белән килде. Аның үз фикере, үз максатлары, үз әдәби-эстетик карашлары тудырылган һәм җитлеккән иделәр. Шуларга таянып ул “Татар шагыйрьләре” хезмәтен яза алды һәм анда үзенең дә язучы буларак үзенчәлекләрен, әдәбиятны аңлау һәм әдәбиятка нәрсәләр алып килгәнлеген, алга таба алып киләчәген ачык итеп бәян итте. Фикеребезне кабатлап шуны ассызыклыйбыз: *Г.Ибраһимов әдәби-эстетик карашларында хис ташкынына корылган, ягъни экспрессионистик алымнарга нигезләнгән, әдәби күзаллауга таянылган, идиллия стихиясеннән гыйбарәт әсәрләргә өстенлек бирде, бигрәк тә мәхәббәт хисенең матурлыкны тоярга ярдәм итүен, аһ-зар итүнең дөньяга нәфрәт белән карарга өйрәтүен мактап чыкты, шушы сыйфатларны С.Рәмиев шигъриятеннән табып, аны әдәбиятта үрнәк буларак тапты.*

Әмма аның шушы әдәби-эстетик карашлары башкалар тарафыннан яклау таптылар дип әйтеп булмый. Ул бу фикерләмәсе белән, шул ук вакытта, татар шагыйрьләренә биргән бәяләрендә чикләнгәнлек тә күрсәтте. Төп сәбәбе — татар әдәби-эстетик традицияләрен исәпкә алмавыннан, артыгы белән яңалыкка, яңача язарга, татар әдәбиятын өр-яңа, кабатланмас, үзенчәлекле итеп күрергә тырышуыннан килде. Г.Ибраһимов хәтта халыкчанлыкның әдәби-эстетик мәртәбәсен өстен чыгармавы белән дә шик уяткан иде. Бу бигрәк тә Г.Тукай иҗатына мөнәсәбәтендә чагылды. Ә, югыйсә, Г.Тукай шигъриятендә дә хис ташкыны, әдәби күзаллау, идиллия күренешләре, мәхәббәт хисе, дөньяга аһ-зар итү кебек сыйфатлар җитәрлек иделәр. Әмма Г.Тукай традицион шигъри формаларга үзенең иҗатында өстенлек бирде, аның шигъри образлары һәм символлары да гадәттәгечә һәм традицион иделәр. Бу исә Г.Ибраһимовка искелеккә, мәдрәсә гыйлеменә таянып яту кебек аңлашылды. Мондый

чикләнгәнлек аның алга, алгарышка омтылышлары, иҗат интереслары белән януы аркасында да булды, билгеле. Аның шулай булуы инде, заманалар узгач, шиксез аңлашылып тора.

Г.Ибраһимов татарның бөек әдипләреннән берсе буларак формалашты һәм беренче әсәрләреннән үк хис ташкынын сурәтләргә омтылучы экспрессионист язучы сыйфатында күп кенә классикларыбыздан аерылып тора башлады. Дөрес, ул әле татар әдәбиятында социалистик иҗат методын нигезләүчеләрдән дә иде. Әмма бу вакыйгалар аның башка иҗат дәверенә карыйлар, без исә аның икенче, ягъни 1910–1912 нче елларны эченә алган язучылык чорыннан әллә ни ерак китәргә уйламыйбыз.

Тагын бер тапкыр кабатлап, галим М.Х.Хәсәновның сүзләрен искә төшереп үткәндә, урынлы булыр: “Ибраһимовның бу чор хикәяләрендә,— дип язган иде ул 1970-80 нче елларда,— чынбарлык белән шәхес арасындагы каршылык реаль, объектив тормыш ситуацияләрендә түгел, ә геройларның экспрессив хисләрендә, эчке кичерешләрендә, рухи омтылышларында чагыла”[1].

Г.Ибраһимовның 1910 нчы елда язылган һәм басылып чыккан “Яз башы” хикәясендә үк хисләр ташкыны шактый катлаулы итеп сурәтләнелә. Аның тәүге әдәби әсәрләреннән берсе санала. Әдипкә ул вакытта бары тик 22–23 яшьләр генә булган. Ә әдәби осталык белән язылуына килгәндә, бүгенге укучыны да хәйранга калдырырлык.

Бу хикәясендә Г.Ибраһимов кешенең эчке дөньясы белән тышкы чынбарлыкны каршы куя, хиснең фикергә, фикернең хискә күчешенә төп игътибарын юнәлтә, әсәренең идеясен шушы катлаулы кичерешләрне раслауга нигезләп төзи. М.Х.Хәсәнов әсәрнең тирән психологизмга корылуын раслап яза[2], хисләр ташкынның көче анда чыннан да психологик яктан чишелә.

“Яз башы” хикәясендә вакыйгалар мәдрәсәдән җәйге ялга кайткан авыл шәкертенең хис-тойгылары мул итеп сурәтләнү-

---

[1] Хәсәнов М.Х. Галимҗан Ибраһимов // Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. — Т.3.— Б.340.

[2] Шунда ук.

гә корылган. Анда, асылда, өч вакыйга бар: беренчесе — малайның укуда өлгереш билгеләрен әнисенә күрсәтеп, аны сөендерүенә, кичерешләр эчендә ананың шатлык яшьләре күрсәтеп куануларына бәйле, икенчесе — шушы шәкертнең авыл балалары белән урамда төрле уеннар уйнап рәхәтләнүләре хакында, өченчесе — аларның авылдан өч чакрым гына ераклыкта булган күлгә балыкка барулары, кармак салулары, ахырда, яңгыр астында калмаска дип, авылга йөгерүләре, елан һәм аждаһалар хакында сөйләнелгән хәбәрләрдән артыгы белән хисләнеп, төп геройның (авыл шәкертенең) аңны югалтуы турында. Хисләр тыныч кына, салмак агымда һәм куанычка төреп бирелә, күренешләр идиллия белән өртелеп башланып китәләр. Вакыйгалар барышында шушы рәхәтлек тагын да камилләшә, мавыктыргыч күренешләргә әверелә бара. Шәкертнең уй-тойгылары, бигрәк тә балык каптыру күренешләрендә, тагын да мәгънәле канәгатьлек ала. Малай кешегә гүяки дөньяда башка төрле рәхәтлек була да алмас төсле: янында дуслары, ул туган авылында, рәхәтләнеп ял итә. Укулары да бик яхшы билгеләргә тәмамланган, моңа әнисе дә куанган. Герой үзе дә идиллиягә бирелгән. Балык каптыру вакыйгалары да аны хисләргә күмә. Җитмәсә, күңеленә тагын да дулкынландырулар салып, малайлар төрле әкиятләр, мифик затлар турында риваятьләр сөйләүгә күчәләр. Бу — аларның стихиясе. Герой — ышанучан. Ул әлегә юкны бардан аера белми. Димәк, яшүсмер дә түгел. Мәдрәсәдә белем алып кайткан, дини ырым һәм хорафатларга тәмам ышанган бала башка төрле була да алмагандыр?

Менә шушы сыйфатлары, җитмәсә артыгы белән хисләнүләре аны харап итә дә инде. Язучы бу фактны шундый оста итеп тасвир кыла, укучы да геройның хис-тойгыларына иярә, төрле кичерешләргә бирелә. Бары тик оста каләм иясе генә мондый вакыйгалардан тәэсирле әсәр барлыкка китерә ала.

Шәкерт, әсәрдә сурәтләнелгәнчә, һушына килгәнендә, рус кешесе кыяфәтле врачның әйткән сүзләрен искәрә: “Хыялдан

нинди бәлаләр туа бит”[1],— ди ул. Шушы сүзләрне авторның укучыга җиткерергә теләгән төп фикере дип тә кабул итә алабыз. Аңлашылып тора, хыялга бирелүе Салих исемле шушы шәкертнең артыгы белән хисле булуыннан килә. Аның акылы саташып авыруы хакында автор бер сүз дә әйтми.

Хикәянең ахырында вакыйгаларны болай тәмамлавы белән Г.Ибраһимов үзенең әдәби-эстетик карашларына каршы киләдер сыман. Әмма, шул ук вакытта, врачның сүзләре аша әдип хыялланукa, хыялланудан юләрләнүгә кадәр җиткерүче хис-тойгыларны сурәтләгәнлеген дә укучыга хәбәр итә түгелме?

Билгеле, Салих, әгәр дә күңеле хис-тойгыларга бай булмаса, тормыш вакыйгалары, авылга кайтуы, әнисенең сөенүе, дус малайлары белән рәхәт уеннар уйнап, тәмам рәхәтлек белән тулмаса, бәлки көчле хыялга һәм кичерешләргә дә бирелми калыр иде. Әмма малай таш йөрәкле түгел, ул уйчан, фикерле, күз алдына китерү сәләте дә көчле. Аңа моның өчен каралып килгән һәм яшен ташларын атучы яңгыр болыты да, күл буенда шаулаган камышлар да, җил белән тузан-туфрак күтәрелү күренешләре дә ярдәм итәләр.

Г.Ибраһимов шушы табигать детальләрен Салихның күзаллавын сөйләр өчен бик оста файдалана. Әүвәле бер вакыйгадан икенчесенә геройның яңара барган хис-тойгылары, тәмам бергә җыелып, хыялый хис ташкынына күчәләр. Вакыйгаларны әдип үзара шундый да яраштырып һәм бөтен итеп кора, укучының хис-тойгылары баштарак аяз күкнең зәңгәрлеге кебек сыек кына тоелсалар да, алга таба куера барып, ташкын сыман ургылып килүче болытның үзенә әверелгәндәй булалар. Бу чыннан да тирән психологизмны барлыкка китерә. Әсәрнең вакыйгалары хис-тойгылар эченә күмелеп кала. “Яз башы”ның эчтәлегеннән, сурәтләнелгән вакыйгалар барышыннан бигрәк, аңардан алган тәэссорат өстен чыга. Әсәрнең болар психологик экспрессионизм алымы белән язылганлыгын раслап торалар. Вакыйгаларның агышыннан бигрәк, хисләрнең кайнаган ташкын итеп

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.1.— Хикәяләр (1907–1929).— Казан: Татар. кит. нәшр., 1974.— Б.64.

тасвирланып бирелеше көндәлдә уңай хисләрне уятырга сәләтле.

Хыялга бирелү, хис-тойгылар эчендә яшәү Салих исеме белән бирелгән геройның характерлы сыйфатымы, әллә авторның позициясеме? Әлбәттә автор позициясе. Г.Сәгъди, мәсәлән, Г.Исхакыйның язучылык осталыгы артуда аның рационализмнан сентиментализмга күчүен төп сәбәп итеп дәлилләп аңлатып биргән[1]. Бу факт язучының нинди эмоциональлек юнәлешен сайлап алуы хакында ачык сөйли. Г.Ибраһимов да, беренче карашка, нәкъ менә сентиментальлекне, хисләрне сурәтләү юлын үз иткәндер кебек. Бу аның өчен әдәби сүз буларак аңлашылган, әлбәттә. Әгәр дә ул иҗат иткән дәверне исәптә тотсак, татар әдәбияты шул чорларда бер әсәрдән икенчесенә күчеп килгән фикерләрдән, тормышны рационалистик юл белән сурәтләп бирүдән уза алмый аптырагандыр кебек. Асылда бу хәл публицистик стиль белән әдәби әсәрләр тудыру аркасында шулай килеп чыккан.

Әдәби стиль исә сурәт барлыкка китерүгә юнәлтелә, ә аның өчен хис-тойгыларны оста итеп тасвирлый белергә кирәк. Г.Ибраһимов кайсы эмоциональлек юлын сайлаган соң? Сентиментализмнымы, әллә идиллиянеме?

Сентиментализм үзе XVIII йөз ахыры, XIX гасыр башында европа әдәбиятында һәм сәнгатендә яши, төп әдәби алымнарның берсе була. Әмма шул чордан соң да ул үзенең әдәбиятта көчен һәм әһәмиятен югалтмый, бәлки, сентиментальлек буларак, геройларның бигрәк тә хис-тойгыларын сурәтләүдә ышанычлы психологик алым сыйфатында сакланып кала. Татар әдәбиятында аның барлыкка килүе һәм яшәү тарихы өйрәнелеп, ачыкланылып җиткән күренеш түгел. Сентиментализм һәм рационализм дигәндә, асылларында берникадәр шул ук романтизм һәм реализм арасындагы аерманы күрәбез. Әмма сентиментализм һәм романтизм, рационализм белән реализм араларында тигезлек билгесе куярга мөмкинлек юк. Шулай ук сентиментализм белән сентиментальлек тә бер үк төшенчәләр түгелләр. Хис-тойгыга бирелү реализм методы белән тудырылган геройларга да хас була ала.

[1] Сәгъди Г. Татар әдәбияты тарихы.— Б.125.

Аны без, геройның хис-тойгыларга бирелүен сурәтләүне, реалистик әсәрдә "әдәби чигенеш"нең уңышлы бер төре буларак кына кабул итәбез. Сентиметализмда геройның эчке хис тойгылары тәэсирле һәм ачык чагылыш ала.

Г.Ибраһимов та "Яз башы" хикәясендә сентиментальлекне шулкадәр мул куллана, ул хәтта әсәрнең төп нигезен хасил итә башлый кебек. Әмма әсәрнең әдәби тукымасы сентиментализмга корылмаган. Хикәясен автор Салих авызыннан сөйләтә. Аның герое, әнисе күзләреннән тамган сөенечле күз яшьләренә нисбәттә, "боларның нидән һәм ни өчен килгәнен миңем белмәсә дә, эчем сизә иде"[1], ди. Шушы рәвешле автор күңел дөньясын акылдан өстен куя.

Ул С.Рәмиевнең шигъриятенә анализ ясаганда да нәкъ шушы хакта фикер йөртеп: "Шигырь телдән яки гакыл вә зиһеннән түгел, бәлки адәмнең рухыннан, күңеленнән, хыял вә хисеннән туа"[2],— ди Г.Ибраһимов. Монда сүзнең шигырь хакында гына түгел, бәлки гомумән дә нәфис әдәбият белән бәйле барганлыгы аңлашылып тора. Тагын да шунысы бар, әдипнең әдәби-эстетик карашлары "Татар шагыйрьләре" хезмәте язылганга кадәр үк формалашып җиткән һәм әдәби иҗатында чагылыш тапкан булган. Язучылык осталыгы да үсә барган. Хаталары да күренә.

Мәсәлән, "Яз башы"нда, шәкерт Салих авызыннан вакыйгаларны "сөйләтеп" барганда, Г.Ибраһимов әдәби мантыйкта ялгышлык ясый. Әсәргә егет кешеләргә хас хисләр килеп керә: "Бу киң вә дулкынлы үлән диңгезенең нәкъ уртасыннан назлы кыз йөреше кеби боргаланып-боргаланып аккан елга үзенең көмештәй ялтыраган төсе белән бөтен тирә-якның күркен әллә ничә кат арттырып җибәрә"[3].

Малай кеше елганың агышын кызлар йөреше белән чагыштырып фикерли белми, билгеле. Бу урында автор башкача, каз-үрдәкләр яисә сыгылмалы кармак сабы, яки

---

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.1.— Хикәяләр (1907–1929).— Б.52.

[2] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томада.— Т.5.— Б.81.

[3] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.1.— Б.55.

боргаланып киткән авылга таба илтүче сукмак, юл белән чагыштырудан сурәт ясый алган булыр иде.

Хикәянең үзендә дә башка андый "әдәби ялгышу" очрамый, әсәрнең башыннан ахырына таба хис һаман да көчәя бара, тойгылар яңгырашы арта. Үзәк нокта булып балык каптыру вакыйгаларында барлык хис-тойгылар җыелып төйнәлер сыман аңлашыла. Әмма автор вакыйгаларны тагын да алга алып китә. Игътибар итсәк, хиснең, мәсәлән, бер төенләнешен Г.Ибраһимов ничек итеп бирә: "Кармакның суга китүе белән, барлык тәнем кайнап, эчем әллә нинди бер кызу белән тулганын тойдым"[1]. Бу инде сентиментальлек тә, идиллия дә түгел, монда эчке бер хисләр киеренкелеге, экспрессия бар.

Г.Ибраһимов хикәянең башыннан ахырынача менә шушы рәвештә тойгы-хисләрне киеренке итеп сурәтләп-сурәтләп ала да, әдәби чигенешле берничә җөмлә кертеп, укучыны беразга тынычландырып куя, аннары тагын икенче бер яклап хисләрне ялкынлы халәткә күтәрттерә, кабат "йөрәккә сулыш алу" мөмкинлеген бирә. Салихның хисләре өчен куану, бәхеткә ирешү тойгысы укучыны биләп ала. Балык каптыру вакыйгасына корылган бүлекчәдә генә дә шушындый кискен үзгәрешле дүрт үзәк бар. Героеның эчке кичерешләрен генә түгел, автор башкаларның эш-хәрәкәтләрен сурәтләүдә дә әдәби экспрессив детальләрне оста файдалана. Мәсәлән (вакыйга Апрай исемле малай белән бәйле бара): "Ул, су кырыена үләнгә төшкән балыкның өстенә егылып, тотарга маташа, үзе бизгәк кебек калтырый, кабалана иде..."[2].

Монда да сурәтләнелгән хисләр динамикасының көчен тоябыз. Балыкның малай кулыннан читкә сикерүе дә, Апрайның аңа кабат ташлануы да, дулкынланулары да күз алдына килә.

Экспрессив детальне әлбәттә тулы текст эчендә укырга кирәк, ул вакыйгаларның динамик барышында тагын да тәэсирле яңгыраш ала. Моның сәбәбе бик гади: экспрессия сурәтнең өзлексезлеген, эчтәлек агышының катлаулы һәм тизләнештә булуын таләп итә.

---

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.1.— Б.57.
[2] Шунда ук.— Б.58.

Г.Ибраһимов шушы “Яз башы” хикәясендә хис-тойгыларны тәэсирле итеп сурәтләп килә-килә дә, иң тәэсирле ноктасына китереп җиткергәндә, вакыйгалар барышына хыялый, мифик-әкияти юха, аждаһа турындагы хәбәрләрне кертә. Алар чыннан да вакыйга эчендә вакыйга күренешен алалар, хикәяне тагын да мәгънәлерәк һәм катлаулырак итеп баетып җибәрәләр. Асылда алар Салихның һәм аның иптәш малайларының хыялында башкалардан ишетү аркасында гына барлыкка килгән күзаллаулар. Әмма көннең үзгәрүе, яшенле яңгыр, җил, куе камышлар шул хыялый дөньяны малайның тойгыларында “реальләштерә”. Хис-тойгыга бирелүчән Салихның “күз алдында” (дөресрәге, күңел күзе алдында) хыял белән хис, бергә кушылып, “чынбарлыкка әвереләләр”. Малай, йөгереп барган җиреннән куркып, аңын җуеп җиргә егыла.

Монда автор хис-тойгыларны бирүне шундый да экспрессив алымнар белән алып бара ки, картиналар укучы күңелендә дә тиз-тиз, динамик алышыналар, хисләр куера, йөрәкне ялкынсыта. Сәнгатьнең тәэсире нинди көчле булуын укучы менә шушы урында тулысынча сизә.

Әгәр дә бу хикәя сентименталь генә булып калса, аңарда мондый экспрессив вакыйга урыннары очрамас, очраганда да бу рәвешле ачылмас иде. Салихның әнисе белән икесе арасында барган сөенечле вакыйгалары асылда сентиментальлек һәм идиллия белән чигелсә, монда инде хәл башкача тора. Эчтәлек үстерелеше идиллик экспрессия планында алып барыла.

Хикәянең соңгы бүлеге хис белән хыял берлегенең тормышчан, ягъни кеше табигатенә хас, реаль тормыш чынбарлыгына турыдан-туры бәйләнешле икәнлегенә дәлил хезмәтен үти. Без һәммә нәрсәне үз теләгебезгә, күзаллавыбызга бәйле рәвештә кабул итәбез һәм аңлыйбыз икәнлеге беленә. Шушы фикерләмә нигезендә хәтта, ялгышлык итеп, бу әсәр чыннан да реализм методы белән язылган дигән фикергә дә килергә мөмкинбез. Әмма анализыбызның нәтиҗәсе башкача килеп чыга: Г.Ибраһимовның “Яз башы” хикәясе бәхет һәм рәхәтлек тойгысы белән өртелгән хисләр ташкыны агышында язылган, ягъни идиллик экспрессионизм үрнәге булып тора.

Әдипнең шушы ук 1910 нчы елда язылган “Диңгездә” хикәясе дә “Яз башы”на тартым сыйфатларга ия. Монда инде вакыйгаларны ул өлкәннәр белән бәйле рәвештә алып бара, ягъни төп геройлары бала-чагалар түгел. Әсәрдә сурәтләнгән диңгез күренешләре, җилкәнле көймәнең киерелеп йөзүе, башкалары — хис-тойгыларны авторга бер юнәлештә “җыярга” мөмкинлек бирә. Әдип шул хисләрне сөйләп килә-килә, укучыны көймәдәге мөселман карты Нуретдин Фәрраш белән таныштыра, аның изге картлардан булуы күзаллана башлый. Юлларында бернинди хәвеф булмастыр сыман. Көн дә чалт аяз, табигать тә матур. Идиллик сурәтләр монда тәмам өстенлек ала.

Әмма көймә давылга эләгә. Мәхшәр башлана. Автор шушы вакыйгалар эчендә Нуретдин Фәррашның намазга тезләнүен төп экспрессив күренеш буларак тасвирлый.

Хис-тойгыларның тәэсирле рәвештә үстерелүе алга таба да дәвам итә. Давыл үзе үк хисләр ташкынын көчәйтүгә хезмәт итә башлый.

Көймә һәлакәттән имин котыла. Әсәрдә, композицияне ныгытуга бәйле әлбәттә, Гаптулла хаҗи вакыйгалары да сөйләнеп алына. Әмма аларда экспрессив детальләрнең азлыгы сизелә.

Г.Ибраһимов, романтизм методына хас рәвештә, төп героен илдәге җәмгыятьне, буржуаз тормыш-яшәешне кабул итмәүче буларак күрсәтеп хикәясен тәмамлый. Көймә урынга килеп җиткәч, пассажирлар шатланышып шаулашалар. Әсәрнең төп герое: “Ярга якынлашып, андагы поездның вәхши акыруын ишетү, корымнар, төтеннәр белән буялып беткән завод моржаларын күрү белән җаным кысыла, йөрәгемдә бер әрнүле пошыну уяна, эчемдә нидер җимерелә, нидер югала”[1],— дип үзен хис итә.

Монда да шулай ук экспрессионистик рәвештә ике төрле хисне капма-каршы куеп сурәтләү алымы файдаланылган. Бу факт исә экспрессионизм белән романтизмның үзара ярәшүен белдерә түгелме? Гомумән дә экспрессионизм романтик планда да, реалистик планда да яши ала.

---

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.I.— Б.81.

Г.Ибраһимовны фән дөньясында реалист язучы дип атау кайдан килә дигәндә, реаль вакыйгаларга, реаль тормыш чынбарлыгына таянып, шуның нигезендә әдәби картиналар, образлар, хәтта фикерләр тудыру осталыгыннан булуына инде тукталып узган идек. Шул ук вакытта сәбәпне, хис-тойгылар экспрессиясен сурәтләвенә игътибар бирүебездән чигенеп, Г.Ибраһимов әсәрләренә, галим Г.Халитча әйтсәк, реализм һәм романтизм синтезы хас, бу исә татар әдәбиятының XX йөз башында "тизләнелгән үсешенә" бәйле дип тә аңлатырга мөмкинбез[1].

Әдипнең иҗатындагы үзгәреш үзенчәлекләренә тукталып, үз вакытында М.Х.Хәсәнов болай дип белдергән иде: "Бу үсеш берьяклылыктан әдәби камиллеккә, романтик һәм реалистик чараларның органик берлегенә, романтизм белән реализм синтезына ирешүдән гыйбарәт иде"[2].

Геройларының эчке дөньясын ачуы белән Г.Ибраһимовны, 1910–1912 нче еллар иҗатына бәйле рәвештә, галимнәр бертавыштан диярлек асылда романтизм вәкиле дип игълан иттеләр[3]. Бу раслауларының нигезе юк, болар хакыйкатьтән ерак дип әйтеп булмый. Чынлыкта алар бары тик каршылыклы һәм тулы түгел иделәр. Шуңа күрә дә бу күрсәтмәләр кысасында Г.Ибраһимов әсәрләрен анализлау өстәмә авырлыклар, аңлашылмаучылык, асылсыз фикерләмәләр тудыра килде.

Экспрессионизм һәм экспрессионистик эзләнүләр белән бәйле тикшергәндә, әдипнең иҗат үзенчәлекләре тагын да ачылып китә һәм аңлашыла башлый түгелме? Әсәрләрен идиллик экспрессионизм юнәлешендә иҗат итүен аңлау шактый төгәл һәм тулы фәнни күзаллау тудыруы бәхәссез.

Г.Ибраһимовның 1911 нче елда язылган "Йөз ел элек" тарихи хикәясе исә реалистик планга куелып иҗат ителгән романтизм әсәре. Ни өчен реалистик планга куелып? Чөнки тормыш вакыйгаларын һәм геройларны тышкы халәтләренә бәйле ача автор. Ә ул вакытта нигә романтизм әсәре дибез?

---

[1] Халит Г.М. Портреты и проблемы: Избранные статьи разных лет.— С.198–237.

[2] Хәсәнов М.Х. Галимҗан Ибраһимов // Татар әдәбияты тарихы: Алты томда.— Т.III.— Б.341.

[3] Шунда ук.— Б.18–20.

Чөнки тарихи әсәрләр билгеләмә буенча романтизм, аның да регрессив романтизм дип аталган өлкәсенә карыйлар. Монда реализм һәм романтизмның синтезы ачык күренеп тора. Бу механик, ясалма синтез түгел, органик рәвештә туган күренеш. Дөрес аңларга тиешбез, тормыш хакыйкате эчке халәтне сурәтләү аша тасвирлаган романтизм әсәрендә дә, тышкы күренешләрне бәянләүгә корылган реализм әсәрендә дөрес һәм тулы килеш ачыла ала. Хикмәт язучының талантына бәйле, иҗат методына түгел.

Г.Ибраһимовның әлеге хикәясендә Уфадан туксан чакрымдагы Карлыман авылы халкы сурәтләү объекты итеп алына. 1810 нчы елларда бу авыл Югары Күл исеме белән йөртелгән. Моңа кадәрге чорларда исә анда зур мәдрәсә булып, данлыклы Хатип хәсрәт шунда белем биргән. Инде имамлык эше аның улы Садыйк муллага калган. Ә ул, әтисеннән аермалы буларак, гыйлемдә маһир кешеләрдән түгел икән.

Вакыйгалар шушы эзлеклелектә сөйләнеп алына. Укучыда мондый хәбәр биреп куелу бернинди хис тә уятмый әлегә.

Һәм менә Садыйк мулланың капка төбенә кешеләр Урыс Пәкри (Әбүбәкер Сәлимов дигән кеше бу) белән ат көтүчесе Салих картның хатыны Камиләне зинада тоттык дип алып киләләр. Эш, инде караңгы төшү сәбәпле, иртәгәге көнгә калдырыла. Шуның белән әсәрдә сюжет төенләнеше барлыкка китерелә. Вакыйганың ничек дәвам итәсен, нәрсә белән бетәсен белергә теләү хисе уяна, әсәр кызыктыра башлый.

Бу авыл халкының надан һәм ялкау булуын Г.Ибраһимов белдереп тә һәм сөйләп тә узуына карамастан, үз-үзләрен тотышларын да, кыланышларын да вакыйга тасвирларында ачып бирә бара. Шушы рәвешле публицистик алым белән әдәби стиль берлеге дә тудырыла.

Авылның усал ирләре чибәр, яшь хатын Камиләне, кызганып та тормыйча, кыйнап ук ташлыйлар. Мондый мәрхәмәтсезлек укучыда аһ-зар хисе белән бәйле нәфрәт тойгысы уята. Наданлык, томаналык өшәндерә. Нәфрәт тойгысын автор беренче тапкыр шушы әсәрендә ача, моңа кадәр аны игътибарыннан читтә калдыра килә. Җәмгыятькә карата тәнкыйди әсәр булдымы, дөньялыкка бәйле нәфрәт

тойгысы өстен чыгарыла дигән сүз түгел әле бу. Әмма Г.Ибраһимовның талантлы каләме үзен яңа яктан күрсәтә. Монда сүз әлбәттә иҗат манерасы хакында бара.

Урыс Пәкри белән Камиләгә нинди максаттан чыгып гаеп тагуларын автор искәртми. Берсенең Урыс аталуы, икенчесенең яшь һәм чибәр булуы сәбәп идеме — төшендерелми, әмма халыкның үтә дә тинтәклеге һәм кабахәтлеге шактый сиздерелә. Укучы күңелендә наданлыкка карата нәфрәт тойгысының уянуы өчен болар да җитә. Автор шушы авыл халкының ахмак гамәл кылуларын көчле бер нәфрәтләнү белән яза ки, вакыйгаларны да шуның белән бәйле кискен һәм киеренке итеп сурәтли. Хикәянең "1810 нчы елның 30 нчы май көне иде"[1] дип башланып китүе дә тарихилык һәм документальлек төсмерен арттыра, Стәрлетамак өязендәге авыл булуы һәм башка хәбәрләр, хәтта авылның исеме үзгәрү факты да әсәрдә, тарихилык белән бергә, реаль чынбарлыкка, хәтта документаль дөреслеккә бәйләнеше барлыгына ышанычны ныгыталар. Шунысы әһәмиятле, геройларның эчке дөньясы, уй-кичерешләре әсәрдә бөтенләй дә исәпкә алынмый, аларның психологиясе, характерлы сыйфатлары, вакыйгаларга катнашулары, нәрсә һәм ничек дип әйтеп сөйләүләре, үз-үзләрен тотышлары — барысы да эш-гамәлләрен сурәтләп күрсәтү аша ачылалар. Болар хикәянең реалистик планда язылганлыгы хакында сөйли торган үзенчәлекләре. Әмма шунысына да игътибар итик: автор сурәтләгән каһарманнарның бирелеше эчке бер динамика һәм экспрессия белән алып барыла, шул сәбәпле әсәр тәэсирле картиналар ярдәмендә вакыйгаларны укучының күз алдына китереп бастыра. Бу исә хикәянең сәнгатьчәлеген тагын да көчәйтә. Моңардан чыгып без экспрессия алымнарының төрле булуын, уңышлы сәнгати чара икәнлеген ассызыкларга тиеш булабыз. Ул гына да түгел, шушы тарихи хикәясе белән Г.Ибраһимов үзен реалистик пландагы язучы итеп тә күрсәтеп ала. Димәк, без аны яки романтик, яисә реалист язучы дип кенә, бер генә яклы алып һәм шул бәяләмәбезне алга куеп раслау юлына бара алмыйбыз икән. Тагын да шунысын ассызыкларга тиешбез: әдипнең реалистик планда язылган

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.1.— Б.82.

шушы әсәренә дә эчке экспрессия хас, монысын инкарь итү мөмкин түгел.

Әдәби әсәрдә эчке динамика булса һәм геройларның эш-хәрәкәтләрендә аңлашылып бетмәгән, мантыйкка сыеша алмаган сыйфатлары артыгы белән бар икән, моны без “экспрессия күренеше” дип атыйбыз. Кеше психикасы, аңыннан, акылыннан аермалы буларак, мантыйкка буйсынмый. Билгеле, ул аның хәтта аң-белеменә дә карамый, хикмәт хис-тойгыларына һәм рухының куәтенә бәйле. Экспрессионистик әсәрләр дә менә шул күңел тәэссоратын яктыртуга бар көчен юнәлтә, алары да сәнгатьчәлекнең рухияткә бәйле булуы сәбәбеннән килеп туа. Шулай итеп хис ташкыны күңелне “борчучы” көчкә әверелдерелә, зиһенне, фикерне кузгатырлык итеп эшләнелә.

Реалистик пландагы әсәр өчен тәэсирлелек, экспрессия уңышлы алым түгелме икәнлеген Г.Ибраһимов “Йөз ел элек” хикәясендә гүяки тәҗрибә кылып карагандыр кебек. Шушындый ук әдәби тәҗрибә мисалы дип “Сөю-сәгадәт (Карт шагыйрь тәэссораты)” фәлсәфи хикәясен дә атарга була.

Монда төп герой Ризаның яшьлеген, анда калган мәхәббәтен сагынып хатирәләргә чумуы бәян ителә. Әдипнең бу әсәрендә вакыйгалар бөтенләй юк диярлек, булганнары да фәлсәфәләр, уй-фикерләр эчендә югалып, төссезләнеп кала. “Сөю-сәгадәт”тә төп элемент — тәэссорат. Г.Ибраһимов шуны экспрессив хис үсешендә бирергә омтыла. Әмма монда хис һәм фәлсәфә берлеге хис һәм хыял булып уңышлы рәвештә үрелеп-әверелеп китә алмаганнар. Вакыйгаларда кискен күчеш һәм үзгәрешләр динамикасы җитенкерәмәү хис-тойгыларның әсәр буенча үсешен тәэмин итеп җиткермиләр. Әмма бу инде рационалистик фикер, дидактик акыл бирү түгел, бәлки сентименталь, хәтта идиллик хатирәләрдән гыйбарәт фәлсәфә коруга кайтып кала торган хикәя дә кебек аңлашыла. “Сәгадәт”, ягъни бәхет сүзен әсәренең исеменә чыгаруы белән автор аның идиллик хикәя булырга тиешлеген расларга тырышмыймы дигән фикер дә уянмый калмый. Чыннан да, геройның хатирәләре никадәр нәзберек сентиментальлеккә корылмасыннар, алар шул ук вакытта идиллик экспрессия

стихиясендә дә тасвир ителгәннәр. Шунлыктан бу хикәяне сентиметаль әсәр дип кенә бәяләргә ашыкмыйк.

Әдипнең үзе өчен генә түгел, әдәбият тарихында да “Сөю-сәгадәт”нең әһәмияте шунда ки, ул бераз соңрак язылачак “Яшь йөрәкләр” әсәре белән бик күп яклап аваздаш, шушы зур романга эчке агымы белән нык якын торган хикәядән санала ала.

“Мөмкин булып та, шул көннәрнең сәгадәтен, аның бөтен хәятемдә тоткан урынын, мәгънәсен аңлата алсам, үземне мәсгуд санар идем”,[1]— дип белдерә әсәрнең төп герое сүзләре белән автор. Бу — Г.Ибраһимовның үз омтылышы, максаты да. Тойгы-хисләрне тәэсирле итеп укучы күңеленә күчерә алуга ирешүдән гыйбарәт ул.

“Романтик геройның рухи дөньясын сурәтләве белән Ибраһимов кеше кәйфиятенең җанлы хәрәкәтен, хисләр көрәшен күрсәтте,— дип белдерә М.Х.Хәсәнов.— Татар прозасын лирик психологизм, бай әдәби буяулар, гадәттән тыш көчле характерлар һәм ситуацияләр белән баетты”[2]. Шушы фикерләре белән бәйле рәвештә М.Х.Хәсәнов Г.Ибраһимовның романтизмына берьяклылык кына хас булуы турында да яза, моның сәбәбен реализм белән бәйләнеше ерак булудан күрә, “Татар шагыйрьләре” хезмәтен, “Яшь йөрәкләр”не гомумән дә 1910–1912 нче елгы иҗатын моңа мисал итеп атап күрсәтә[3].

Әмма Г.Ибраһимов реализмга таба “Йөз ел элек” тарихи хикәясе белән күчеш ясамадымы дигән сорау туа. Башка кайбер әсәрләрен дә, мәсәлән, “Казакъ кызы”н, “Карак мулла”ны, “Карт ялчыны” шул ук исемлеккә кертеп карап булмыймы? Әллә әдипне әсәрләре реализм яки романтизм чаралары белән язылганлыгы ул вакытларда бөтенләй борчымаганмы?

Мондый сораулар урынсыз кебек. Г.Ибраһимов әдәби әсәрләрендә һәм романтизм, һәм реализм алымнарын яхшы белеп, тоеп язган әдип сыйфатында күзаллана. Әмма ул әдәби-эстетик кредосына әверелгән экспрессионизм өчен реалистик

---

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.1.— Б.120.

[2] Хәсәнов М.Х. Галимҗан Ибраһимов // Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.1.— Б.19.

[3] Шунда ук.

планда яки романтик планда гына, ягъни аларның берсендә генә иҗат итү — максатка ирешүдә мөмкинлекләрен чикләү икәнлеген дә яхшы төшенеп эш иткән. Бу хакта әдип үзе ничек дип аңлата: “Шигырь телдән яки гакыл вә зиһеннән түгел, бәлки адәмнең рухыннан, күңеленнән, хыял вә хисеннән туа”[1]. Алга таба ул моның механизмын да аңлатып бирә: “Бер шигырьнең камил шигырь булып чыгуы өчен шагыйрьнең бер нәрсәдән тәэссоры һәм шуны укучыга тәэсир итәчәк рәвештә шигъри сүзләр эченә салуы лазем”[2]. Һәм ул үзе нәкъ менә шушы юл белән әсәрләрендәге геройларын, картиналарны тасвирларга омтыла. Бу каһарманнар үзләре дә бер-бер вакыйга яки хәбәрдән тәэсирләнәләр, хискә биреләләр. Язучы аларның шушы хисләрен әсәрләрендә үтемле итеп бирә, моның өчен экспрессионистик сурәт тудыру ысулын сайлап ала. “Яз башы” һәм “Диңгездә” хикәяләрендә бу рәвешле язуы уңышлы барып чыкканына инде тукталып узган идек, ә менә “Уты сүнгән җәһәннәм” әсәренең исеменнән үк хикәянең шушы алым белән язылуын дәгъвалаганы күренә.

Әдипнең бу әсәре “сызлану фәлсәфәсе”нә корылган, экспрессионистик хис буларак Садыйк мулланың үз тормышы, яшәеше белән канәгать түгеллеген табигать күренешләре, җил, яңгыр, караңгы төн һәм мәгънәсез яшәеш хакында хәсрәт чигүенә бәйле уйлар өермәсенең ташкынлы агышын сурәтләүдән гыйбарәт. Романтик планда язылган әсәрләрендәге идиллия бу әсәрендә бөтенләй юк дәрәҗәсендә, аның урынына аһ-зар, сызлану һәм шулар белән бәйле барлыкка килгән нәфрәт тойгысы шактый өстен чыгарыла. Әдәби сурәттә тирәнәйгән саен әдип идиллиядән читләшә бара.

Г.Ибраһимов хикәяләрендә сюжетларның нигезен реаль дөнья һәм геройның күңел халәтләре арасындагы каршылыклар тәзи (М.Х.Хәсәновның моңа тартым фикерен инде искә алып узган идек), тормыш чынбарлыгы итеп алынган вакыйгаларының туктаусыз үзгәреше рух хиссиятенә тәэсир итүеннән герой тирән кичерешләргә бирелә, бигрәк тә хыялга тө-

---

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.5.— Б.81.

[2] Шунда ук.

шүе аның эчке кайнарлыгын тудыра. Бу, үз чиратында, әлбәттә психологизмга китерә.

Күңел дөньясы сентиментальлектән, идиллиядән һәм романтикадан гайре яши алмый. Ул аның хасияте. Менә шуңа күрә дә Г.Ибраһимов әсәрләре романтизм иҗат методы белән язылганнар булып аңлашыла. Әмма алар асылда экспрессионизмга корылганнар, романтик яки реалистик планда иҗат ителгәннәр.

Экспрессинизм ул — әдәбиятлар үсешендә XX йөзнең беренче чирегенә хас әдәби-сәнгати юнәлеш, дидек. Бердәнбер хакыйкать, чынбарлык дип бары тик кешенең шәхси рухи дөньясын гына таный, менә шул чынбарлыкны сурәтләүне сәнгатьчәлек дип саный, тойгы-хисләр эчендә яшәүне ул дөрес, мактауга лаеклы тормыш дип атый[1].

Г.Ибраһимовның “Уты сүнгән җәһәннәм” хикәясе дә, аерым алганда Садыйк мулла нәкъ шушындый планда сурәтләнелә. Аның сызлануының төп сәбәбе яшьлек хыялларының тормышка ашмавыннан булса, шушы тәэссоратына этәргән чынбарлык вакыйгасы да бар, ул — мәдрәсәдә укыган чорында аңарда самавырчы малай хезмәтендә генә торып та, ахырда зур белемнәргә ирешкән, “урыс түрәсе” рәвешендә килеп керүче, алтын күзлекле, европача киемле, элек Тубал кушаматы белән йөртелгән, инде хәзер үзенә бары тик исеме белән генә мөрәҗәгать иттерер мәртәбәгә ирешкән Гыйльман Каһиров.

Садыйк муллага малайлар, өенә йөгереп кереп, урыс түрәсе килде дип, Гыйльман хакында хәбәр бирәләр. Ул аны каршы алырга чыгарга мәҗбүр. Түрә дигәннәрендә элеккеге самавырчысы Тубалны, ягъни Гыйльманны танып алуыннан әсәр вакыйгаларында хис көчеше барлыкка килә. Күрше авыл баеның балаларына җәен дәресләр бирергә сүз беркетүенә бәйле юлга чыгып, ат башы тотучы һәм бер иптәше белән бергә яхшы тарантаста Гыйльманның узып барышы икән.

Менә шул очрашудан соң Садыйк мулла йокысын югалта, тынычлана алмый. Гыйльманнан көнләшү хисе түгел, бәлки дөньяның аяусызлыгы, яшьлек хыялларыннан баш тартырга

[1] Словарь иностранных слов и выражений / Автор-составитель — *Зенович Е.С.*— М.: Олимп; “Издательство” АСТ-ЛТД, 1997.— С.556.

мәҗбүр ителүе сызландыра аны. Һәм ул кешеләр өчен тормышта ике төрле яшәү юлы бары икәнен төшенә: аларның берсе — ихтыяр белән, көрәшеп, юл ярып; икенчесе — язмышка, тәкъдиргә буйсынып. Садыйк мулла үзенең ихтыярсызлыгына хәйран итә, юкса ул мондый гына кеше буласы түгел икән.

Г.Ибраһимов, шушы рәвешле төшендереп, укучы күңелендә көрәш, үз язмышы өчен җаваплыклык хисләрен уятырга омтыла. Әмма әсәренең тукымасына җәелдерелгән сызлану фәлсәфәсе моңа ирек бирми.

Хикәянең герое коры сызланудан, тормышнына, язмышына буш борчылудан узмый. Тойгыландырган фәлсәфәсе дә сүнә. Аңарда хыяллану гына бар, яшәешкә, батырлыкка илтүче, ихтыярга таяндыручы романтик рух юк.

Алда Садыйкны тыныч йокысы көтә икәнен белдерә автор. Язучы нәкъ менә язмышка, тәкъдиргә буйсынучанлыкны, тормышта реалист булуны йоклаганлык итеп күрсәтә. Әсәрдә тасвирланган бу халәт җәһәннәмгә эләгү сыман бер хәлдер кебек аңлашыла башлый. Садыйк мулла дөньялыкны караңгы, “уты сүнгән җәһәннәм икән” дигән фикергә килә. Тормышта ихтыярга таянып, хыялларны тормышка ашырырга омтылып яшәргә кирәк икән, шул вакытта гына ул “җәһәннәм”нән котыласың дигән уй укучы күңеле аша, аның акылын яктыртып уза.

Хис-тойгы — кеше күңелен кузгату көченә ия. Ул уйга, фикергә, һич югы — хыялга этәрә. Экспрессионизм вәкилләре нәкъ менә шуңа игътибар иткәннәр дә. Алар, хис-тойгы ярдәмендә “сызлану фәлсәфәсе” тудырып, аңардан котылу юлын эзләргә, әдәби геройларының язмышын кабатламыйча яши белергә укучыларын өйрәтергә кирәк тапканнар. Экспрессионистлар, хисне иң көчле дәрәҗәгә җиткереп, укучыны “шок халәте”нә китерергә омтылганнар, моның өчен алар төсләрне саташтыру, формалардан баш тарту юлына да барганнар, реаль дөньяның “чын йөзе” аны без кабул иткәнчә, тойганыбыздагыча дип аңлатканнар, тормыш дөреслеге ул — кешенең хисләренең чагылышы гына, дигәннәр[1].

---

[1] Краткий словарь по эстетике: Кн. для учителя. /Под ред. *Овсянникова М.Ф.*— М.: Просвещение, 1983.— С.197–198.

Әдәбиятта экспрессионистик ысулларны файдалану, аның да яңа чараларын эзләп табу һәм куллану ягыннан Г.Ибраһимов үз чоры әдипләренең иң көчлеләреннән берсе булуы белән аерылып тора. Бу яктан караганда да аның эшчәнлеге мактауга лаеклы. Әдипнең тормыш чынбарлыгын “контраст буяулар”да аңлатырга алынуы, яшәеш перспективасын эзләве, хис төенләнешен реаль вакыйгаларга бәйли белүе һәм шуларның әдәби ысулларын, чараларын табуы татар әдәбияты үсешенә зур этәргеч ясады дип хаклы рәвештә белдерә алабыз. Ул экспрессинистик алымнарны романтик планда язылган әсәрләрендә куллана башлап, реалистик планда сурәтләүдә дә бик оста файдаланды. Моның белән алдынгы әдипкә әверелде.

Г.Ибраһимовның 1911 нче елда язып тәмамлаган “Карак мулла” һәм 1912 нче елда иҗат иткән “Карт ялчы” хикәяләре чын мәгънәсендә реалистик әсәрләр булып торалар. Нәкъ шушы 1912 нче елда ул “Татар шагыйрьләре” хезмәтен дә басмага әзерли. Аларда аның шул ук эстетик карашлары төп урынны алганлыгын бу факт үзе генә дә катгый раслап тора. Әдәби-эстетик карашларын ул конкретлаштырган, тагын ачык күзаллап һәм аңлап иҗат итүгә керешкән.

“Карак мулла”да Г.Ибраһимов Тимри язмышын сурәтли. Ул караклар нәселеннән булып, гәүдәле, таза беләкле егет, читкә мәдрәсәгә китеп, анда “укымыйча да белеп”, белем алуда өлгерлек күрсәтә, әмма караклык аның канында икән, киемсалым урлауда фаш булып, укуыннан куыла. Авылларына кайта. Белеме бар дип аны әүвәле мәзин итәләр, аннары карт хәзрәт муллалык эшен дә тапшыра. Әмма халык арасында караклар белән бәйләнеше хакында сүзләр таралып, ул указыннан баш тартырга мәҗбүр.

Хикәядә беренче экспрессионистик, тәэсирле вакыйгалар Тимринең шәкертлектәге караклыгы фаш булу белән бәйле сурәтләнелеп, мәзин-муллалык хәлләре сөйләнелгәндә тагын да көчәйтеләләр.

Бу хикәянең икенче өлешен мукшы бае белән татар бае Сафа арасында барган ярышу алып тора. Автор моны татарларга һәм мукшыларга (мордваларга) бәйле бер милли иттифакый ярыш буларак сурәтли. Мукшы баеның акбүз биясе сабантуй-

ларда өстен чыга, әмма Сафада андый чабышкы юк. Һәм менә аның бәхетенә базарга чегәннәр ат сатарга киләләр. Арада бер тай да була. Ат тануда даны чыккан Гәрәй карт Сафа байга аны сатып алдырта.

Атлар турында язганда Г.Ибраһимовның каләме сабырсызланучан, аның сүзләрендә тәэсирлелек, экспрессив динамика бермә-бер арта. "Ул тайдан кечек, чандыр, аз итле, бераз бөкрерәк аркалы, ләкин гаҗиб дәрәҗәдә сөйкемле һәм җанлы бер ат чыга. Ул болай бертөрлерәк кенә, әмма җигеп, яисә менеп чыксаң, шундый матур йөри, бөтен кешеләр исләре китеп карап калалар. Үзе торганы ялкын, шул дәрәҗәдә ки, тик дилбегәне генә тотып өлгер. Ул кузгала, шул арада әллә кая очкан була"[1].

Бу тай ярышта мукшының акбүзен ике чакрымлап артта калдыра. Бәйрәм татар ягына күчә. Мукшы бае менә шушы тайны урларга Тимрине яллый. Алар, очраклы килеп чыккан каравылчы картны үтереп, тайны бикле сараеның түбәсе аша чыгарып, авыл башындагы таугa алып менеп суялар. Вакыйгаларның бу рәвешле кискен рәвештә үзгәреш алуы көтелмәгәнлек тәэсирен уята.

Г.Ибраһимов сюжет борылышларын сурәтләгәндә тәэсир көчен катлауландырып һәм үтемле итеп бәян итә белә. Мәсәлән, ат урлау турында язганда ул Сафа байның ике олы этен дә искә ала, аларга "ришвәт" буларак, ягъни алдап ашатырга, каракларның симез башмак сыерны акыртып суюларын искәртә, каравылчы картның маңгаена Тимри шайкасындагы Гомәр кистән белән җибәрә, миләрен чәчрәтә һ.б. Бу картиналар вакыйганың тәэсир көчен арттыралар, авторның ваклап сөйләп алҗытмавы исә шул ук урыннарны экспресссив һәм динамик агышлы итә. "Карт ялчы" хикәясендә дә андый өлешләр җитәрлек.

Г.Ибраһимов, әдәби чигенеш ясап, каһарманнарының нәсел-нәсәбен сөйләп чыгуны да хикәяләрендә оста файдалана, алар укучыны яңа тәэссорат-кичерешләр күтәрелешенә җай гына әзерлиләр.

---

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.1.— Б.141.

Карт ялчы Шаһи (Шаһибәк) Өлкән авылындагы ярлы гаиләдән, бала чагыннан ятим калып, Байморзада ялчылыкта эшли, аннары Әхми байның әтисенә яллана, соңрак аның усал һәм кешелексез малае хезмәтендә кала. Шаһиның әнисе Миңлегөл үлеп, әтисе читкә чыгып киткәч, баланы бабасы Шәмси карт белән әбисе Гайни карчык бишек яшеннән үстергәннәр. Алар бик тә сабыр, Ходай биргәненә рәхмәтле булып, фәкыйрьлектә яшәгәннәр.

Вакытлар узган. Инде Шаһи үзе дә тәмам картая, көчсезләнә.

Яңгырлы көз көне басудан көшел ташыганда шушы Шаһи карт белән хикәянең төп каһарманы Сәфәр, атлары йөкләрен тартып Ямanташ тавына менә алмыйча тукталганга, кырда кичлек ясап, кунарга мәҗбүр булалар. Автор тормыш картиналарын тәэсирле итеп тасвирлап, вакыйга эчендә вакыйгалар биреп, экспрессионизм алымнарын реалистик әсәр тудыруда оста файдаланып, шушы юл белән укучының тойгыларын үстереп килә-килә, хакыйкатьнең асылын ачыклап бирүгә ирешә. Аның реалистик планда язылган әсәрләренә тормыштагы күренешләргә карата күңелдә нәфрәт уяна, мондый яшәешнең мәгънәсезлеге хис агышы белән тагын да көчәйтелә. Суфиларча тормыш корган өлкәннәрнең тәрбиясен күргән Шаһи бөтен гомерен коллыкка багышлаган. Ул — Хода биргәнгә ризалык тотып яшәүче.

Шуны да искәртү урынлы булыр: нәкъ менә шушы 1912 нче елда Г.Ибраһимов “Яшь йөрәкләр” романын да тәмамлый. Аны да ул экспрессионизмның барча әдәби-эстетик алымнарын файдаланып яза. Әсәренең төп каһарманнарыннан булган мирза кызы Мәрьямнең язмышы вакыйгаларга бай түгел, аның бөтен барлыгы хис-тойгыларында тупланган. Ул үзенең дөньялыкта яшәвен дә, Зыяга карата мәхәббәтен дә тәмам аңлап бетерер дәрәҗәдә түгел. Хәтта Фәхригә кайчан, ничек кияүгә бирүләрен дә, аны үтерүен дә ачык кына төшенми. Һаман да хисләр дөньясында яшәве хәтта Зыяның кемлеген, ниндилеген танyга да китерми. Дөрес, ул вакыт-вакыт дөнья тормышына “кайта”, әмма алар Мәрьямнең асылына хилафлык кына китерәләр. Бөтен барлыгы романнар укудан, Зыяга

мәхәббәттән генә торган бу кыз хисләр дөньясында йөзәргә генә сәләтле. Ул хис-тойгылар аның һәр хәрәкәтендә, һәр төсчалымында чагылыш таба.

Зыяның да бөтен барлыгы һәм яшәеше хис-тойгыларында. Ул тормыш чынбарлыгыннан шактый югарыда. Катлаулы хис-тойгыларын сурәтләп бирү өчен автор музыкага булган мәхәббәтен алгы планга чыгара. Аның бар белгәне, барлык тойгылары, хис иткәннәре музыка белән бәйле. “Татарның табигате бүтән һичбер халыкныкына охшамаган кебек, ул тарихы, язмышы белән дә бөтенләй башка рәвештә тора. Шуңа күрә аның музыкасы да, бәлки, башка һичбер кавемнекенә охшамас, һәм охшамавы табигый дә... Бер халыкның язмышы вә табигате белән аның музыкасы арасында нинди дә булса бер якынлык, мөнәсәбәт булмавы мөмкин түгел. Чын милли музыка — халыкның йөрәгендә булган тойгыларының тудырган җимеше, җанының аһы-зарларыдыр. Татарның асыл табигате бөек, җаны мәртәбәле, йөрәге бик хәссас булып, икенче яктан, язмышы бик агыр, тарихының соңгы сәхифәләре баштанаяк көенеч вә хәсрәт илә тулыдыр”[1],— дип фәлсәфә кора Зыя, үзенең дусты Госманны да аптыраштa калдырып, үз халкын эчтән тоеп, бөеклеген төшенеп. Ул һәммә нәрсәгә музыка аша карарга, хакыйкатьләрне музыкага бәйле уйларга, дөреслеккә шул юл белән бәя бирүгә сәләтле. Аңа хәтта тормыш һәм андагы яшәеш кызыклы да түгел. Мәрьямгә булган мәхәббәте дә музыка кебек. Ул моны яхшы тоя. Музыка аны сокландыра, яшәтә, хисләндерә. Зыя шушы музыка белән бәйле хәлендә азгынлыкка да, һәлакәткә дә бара. Үлеме дә музыкага бәйле була. Солдат хезмәтеннән ялга кайткач, ул моңа кадәр күңелендә йөрткән, әмма аның ни рәвешле, нинди булып чыгасын белмәгән хәлдә музыка коралында, скрипка-саз-сызланда, уйнап җибәрә, көчле хис-тойгылар эчендә йөрәге бу рәхәтлекне күтәрә алмый. Егет үлә. Шул рәвешле Г.Ибраһимов хис экспрессиясен һәлакәт мизгеленә кадәр үстерә.

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.2.— Яшь йөрәкләр. Казакъ кызы.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1975.— Б.185.

Әсәрдәге Җәләш (Җәлал, Җәлалетдин) мулла да дуамаллыгы, үз дигәненчә генә яшәргә-эшләргә омтылуы белән экспрессив герой буларак сурәтләнелә. Ул әле азгынлыкка бирелә, әле Зыяны хәрби хезмәттән алып калу теләге белән шашына. Эшләре барып та чыгарга тиеш була, әмма тормыш аны да ега. Җәләш муллага, шушы атлар, хатыннар, исереклек, балалар белән "җенләнгән" кешегә, тормыш чынбарлыгыннан качып хаҗга китеп котылу, кире әйләнеп кайтмау гына "тынгылык" бирә. Автор аны даими хисләр ташкыны эчендә яшәүче герой итеп тасвирлый. Әсәрдә "яшерен шагыйрь" дә, башкалар да бары тик хис-тойгылар сөремендә тормыштан читләшеп, рух дөньясына китеп яшәүчеләр буларак күзаллаланалар.

Бары тик Сабир гына аларча түгел. Ул мондый хисле-тәэссоратлы, суфийана дәрәҗәдәге кешеләр арасында яши алмыйча, гомерен читтә уздырырга мәҗбүр. Дөньяны башкача хис итә. Ул тормыш реальлегендә тора. Шунлыктан бердәнбер диярлек тәкъдири герой буларак тоела. Әтисенең йортына кайтып, ахырда авыл тормышы белән яши башлый, үзе кебек эшчән кызны хатынлыкка ала.

"Яшь йөрәкләр" романы вакыйгаларга ярлы, әмма анда хисләр һәм тойгылар, рухи омтылышлар шактый тирән итеп сурәтләнелеп бирелгән. Әсәрне сентименталь ноталарга корылган дип әйтеп булмый. Монда да хисләр идиллиясе өстен чыгарыла. Геройлар асыллары белән үзләренең күңел дөньяларында гына яшиләр, шуның өчен дә әсәрнең башыннан ахырына кадәр алар үз дигәннәренчә генә булырга омтылалар, бернинди йола һәм кануннарны санга алмыйлар. Мулла булуына карамастан, Җәләш тә вакыт-вакыт эчеп, исереп йөри, йортына кайтмыйча аптырата. Аның күңелендә улларын шәһәрдәге олы һәм бай мәхәлләләрнең имамнары итү, халык алдында түрдә йөрү һәм йөртүдән генә гыйбарәт хыял. Шуны тормышка ашырам дип байлыгын да, вакытын да кызганмый. Боларны Г.Ибраһимов экспрессив эмоциональлек белән тасвир итә. Бу хыял — романтик хыял. Менә шуның буш булуын аңлый бару Җәләш мулланы юк итә. Аңа бу, өмет-

хыяллары акланылмаган, чикләрен табалмый аккан тормышыннан качып китүдән гайре башка юл калмый.

Әдипнең 1910–1912 нче елларда иҗат иткән хикәяләре кебек үк, “Яшь йөрәкләр” романы да классик сюжет төзү осталыгына нигезләнеп түгел, бәлки тәэссорат, лирик хисләрнең үсешен, кичерешләрнең барышын тасвирлауга корылып язылган. Әсәрләренең кайсылары реалистик планда, кайсылары романтик юнәлешне алда тотып язылганнар. Һәммәсенең уртак ягы — Г.Ибраһимовның экспрессионистик алымнарны таба һәм файдалана белүендә чагыла.

Болардан чыгып без язучының бу чорда экспрессионизм вәкиле булуын белдереп нәтиҗә ясарга мәҗбүрбез. Экспрессионист буларак эстетик карашларын тормышка ашыруы белән бергә ул нәкъ менә шушы елларда “Татар шагыйрьләре” хезмәтен яза. Аның шушы әдәби тәнкыйть әсәре бүгенге көндә дә татар әдәби фикеренең иң гүзәл үрнәге буларак хаклы рәвештә санала ала.

Хикмәт безнең экспрессионизмга мөнәсәбәтебезгә дә бәйләнмәгән, башкада да түгел. Хикмәт “Татар шагыйрьләре”нең үзендә. Ул, беренчедән, катгый эстетик-әдәби карашлар нигезендә язылган, икенчедән, автор үз фикерләрен дә бәяли белеп бәян итә, өченчедән, татар әдәбияты үсешен һәм тарихын, шулар белән бергә әдәбият теориясен яхшы белеп һәм күзаллап фикер йөртә. Безгә аның хакыйкатьне ачу принциплары кызыклы, алар бүгенге көндә дә Г.Ибраһимовның әдиплек үзенчәлекләренә кайта-кайта бәя бирергә ярдәм итәләр.

XX йөз башы татар әдәбияты үсештә шактый катлаулы юнәлешләрдә бара. Ул чор язучылары, шагыйрьләре, драматурглары эзләнүчән булулары белән татар әдәбияты тарихының башка дәверләре әдипләреннән аерылып торалар. XX гасыр башы татар әдәбияты үсешенә, андагы иҗат юнәлешләренә, чараларына, ысулларына бер генә төрле караш тудыруга, бәяләүгә каршы килгән Г.Халитнең сүзләренә инде тукталган идек. Ул чыннан да хаклы. Бу дәвер татар әдәбиятының шактый катлаулы чор булуын истә тотып, авторларның әдәбиятка зур әзерлек һәм җитлеккән зәвык белән килүләрен дә аерым ассызыкламый мөмкин түгел.

Г.Ибраһимовның иҗаты моңа ачык дәлил булып тора. Анализлаган материаллар боларны ачык күрсәтәләр.

* * *

“Татар шагыйрьләре” хезмәтендә беренче тезис итеп Г.Ибраһимов чын шигырьнең күңелгә үтеп керә алу көченә ия булуын, хәтердә калу үзенчәлеге барлыгын искәртә. Моның сәбәбе әлбәттә шигырьнең рухи куәт белән тууына да, шигырь камилиятендә язылуына да, шигырь сыйфатында төзелүенә дә, шигыйранә хисләр ташкыны булуына да бәйле. Г.Ибраһимов, боларга мисал рәвешендә алып, бер укылуда хәтергә сеңүче шигырьләр хакында сүз алып бара.

Әдипнең икенче тезисы — “тупас нәрсәләр”, ягъни тупас әсәрләр “вакытлы бер тәэсир” аркасында туалар. Әдәбиятта тупас сүзләр, тупас формалар, тупас эчтәлек булмаска тиешлеген ассызыклап, Г.Ибраһимов андый шигырьләрне С.Рәмиев иҗатыннан сызып ташлавы хакында белдерә. Бу да әдипнең әдәби-эстетик кредосы ныклык хакында сөйли торган факт булып тора.

Өченче тезис итеп ул шигырьнең “рух көзгесе” булырга тиешлеген алга чыгара. Язучы, шагыйрь башкача яза да алмый. Үзе бер төрле, әсәре икенче рәвешле булу бары тик ялган гына тудыра, андый әсәр хакыйкатьтән ерак тора. Кеше дөньяны, чынбарлыкны хисләре белән танып белә, димәк, экспрессионистик фикерләмә буенча, тормыш дөреслеге менә шул хисләрдә инде. Моның асылы модернизмның һәм формализмның нигезен хасил итүче, XIX йөзнең соңгы чирегендә Европада киң җәелеш һәм үсеш алган “хис итү теориясе”нә барып тоташа[1]. Г.Ибраһимов бу хакта белгәндерме-юкмы, кистереп әйтеп булмый, әмма ул дүртенче тезисын, нәкъ аңардан хәбәрдар кебек, болай дип ачыклый: “Ул шигырь язмый, шигырь чыгармый, бәлки аның шигырьләре шагыйрьнең үз иркеннән башка, үзеннән-үзе килеп чыгалар”[2].

---

[1] Краткий словарь по эстетике: Кн. для учителя.— Б.27.
[2] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.5.— Б.77.

Бишенче тезис итеп Г.Ибраһимов шагыйрьне “рухи бер сәбекъ астында гына иншад итә ала”, ди, ягъни “рухи стимул, этәргеч аркасында гына шигырь барлыкка килә ала”[1] дип белдерә. Бу рухи этәргечнең тормыш икәнлеген ачыклый, “күңелне кайнатып җибәрүенә” игътибар итә һәм алтынчы тезис буларак С.Рәмиев иҗатына мондый бәяләмә бирә: “Аның һәрбер сүзе йөрәкнең әллә кай җирләреннән кайнап, рухның төбеннән, эчке нокталарыннан ялкынланып килеп чыга”[2]. Моңа дәлилләр итеп С.Рәмиевнең шигърияте тезмә калыпларга гына сыеп бетмәвен мисалларда китерә. Шигырьнең “табигый агымы” бозылуының сәбәпләре дә менә шул хиснең артыгы белән күплегеннән килә икәнлеге төшендерелеп бирелә.

С.Рәмиевнең шигырьләрендә Г.Ибраһимов, шул рәвешле, хис ташкыны көчле булуын яклый, әдәби күзаллау буларак хыялга төп игътибар бирелүне өстен чыгара, мәхәббәт һәм нәфрәт тойгы-хисләренең уңышлы бирелешен аңлата һәм шигъриятен идиллия кысаларында язылган дип белдерә.

Аның бу фикерләре С.Рәмиевнең шигырьләре экспрессиягә корылганлыгын раславына турыдан-туры бәйле. Г.Ибраһимов татар әдәбияты фәнендә “Татар шагыйрьләре” хезмәтендә экспрессионизм теориясен барлыкка китерә һәм аның үзенчәлекле сыйфатларын аңлатып, төшендереп бирә. Болар аның әдәби-эстетик карашлары тәмам формалашып җиткәнлек хакында ачык сөйләүче фактлар.

Г.Ибраһимовның бөтен максаты татар әдәбиятын югары сыйфатлы әсәрләргә баету белән бәйле икәнлеге тәнкыйтенең таләпчән булуыннан ук аңлашылып тора. Нәкъ менә шушы кимәлдән чыгып ул С.Рәмиев, Дәрдемәнд, Г.Тукай шигъриятенә бәя бирә. Аерым С.Рәмиев иҗатын тикшергәндә, аның шигъриятендә хиснең тирәнлеген таный, әмма шигырьләренә әдәби эшләнеш җитмәвен дә ассызыклый.

Инде тәмам ачыклый алдык кебек: Г.Ибраһимовның С.Рәмиев шигъриятенә өстенлек бирүенең төп сәбәбе — аларның икесенең дә иҗат принципларының үзара туры килүенә бәйле.

---

[1] Шунда ук.
[2] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда.— Т.5.— Б.77.

Моңа төшендерерлек шактый гына дәлилләр белән очраштык түгелме?

Дөрес, аларның икесен дә әдәбият тарихы фәнендә галимнәр романтизм вәкилләре буларак бәялиләр. Әмма бу әдипләрнең ул иҗат методы кысаларына гына сыеп бетмәүләрен дә игътибарсыз уздырып җибәрү мөмкин түгел. “Карак мулла”, “Карт ялчы” хикәяләрен генә алып карасак та, аларның реалистик планда иҗат ителүләре шик тудырмый. Ул әсәрләрдә экспрессионистик алымнарның шактый уңышлы файдалануын инкарь итү мөмкин түгел. “Яшь йөрәкләр” кебек роман жанрында язылган әсәрен алып анализлаганда да шундый ук нәтиҗәләргә килергә мәҗбүр булабыз. Тагын шунысы бар: модернистлар романтизмны өстен күргәннәр, реализмны, натурализм белән янәшә куеп, хәтта сәнгатькә, сәнгатьчәлеккә санамаганнар. Әмма Г.Ибраһимов ул юлга бармый, реализмны читкә какмый. Бу яктан аның әдәби-эстетик карашлары тагын да кызыклырак һәм мавыктыргычрак кебек тоела.

Г.Ибраһимов хисләрне мөмкин кадәр тулырак тасвир итәргә тырыша. Шушы яктан ул роман жанрын кулай күреп сайлап ала һәм аның төрле юнәлешләрдә, күләмле итеп тормыш картиналары тудырырга мөмкинлек бирүен уңай файдалана.

“Яшь йөрәкләр”дәге Зыя да, Мәрьям дә, Җәләш мулла да хисләр эчендә яшәүчеләр итеп биреләләр. Бу геройларның эчке дөньясын автор төрле яклап ача. Алар әле хис-тойгылар кайнарлыгына биреләләр, әле кинәт суыналар. Аларда мәхәббәт тә, нәфрәт тә бергә яши. Геройларны шушы рәвешле катлаулы хис-тойгылар эчендә сурәтләү ягыннан XX йөз башы татар әдәбиятында Г.Ибраһимов зур уңышка ирешә. Ул романтик планда да, реалистик планда да экспрессионизм алымнарын оста файдаланып эш итә. Бу аның җитди һәм көчле, киң кырлы язучы булуы хакында сөйли.

*2008.*

# ӘДӘБИЯТТА ӘДӘБИ-ТЕКСТОЛОГИК АНАЛИЗ АЛЫМЫ НИГЕЗЛӘРЕ

Борынгы әдәби ядкәрләрне барлаганда, аларга бәяләмә биргәндә әдәби-текстологик анализ алымыннан башка эш итү хаталы фикерләмәләргә, фәнни булмаган нәтиҗәләргә этәрә. Шунлыктан бу төр анализ алымын гыйльми эзләнүләрдә файдалану зарури икәнлеген ассызыкламый мөмкин түгел. Әдәби-текстологик анализ алымын борынгы ядкәрләрне анализлауда гына куллану дөрес икән дигән хаталы фикергә дә килергә ярамый. Ул һәртөрле әдәби текстларны анализлау өчен кулай, кирәкле һәм таләп ителүче анализ юлы буларак та кабул ителергә тиешле.

Инде күптәннән, әдәби текстларны төшенү кирәклеге кешелек тарафыннан аңлана башлаганнан бирле диярлек кулланылучы бу анализ алымы фәндә файдаланылса да, аның отышлы һәм каршылыклы яклары барланганы, бәяләнгәне юк, диярлек. Моның сәбәбен бары тик әдәби-текстологик анализны кулланып эш итүне заман таләпләреннән ерак, урта гасырчылык дип күзаллауда күрергә мөмкин. Әмма соңгы елларда еш телгә алына торган герменевтика юнәлеше бу фикерне тулысынча диярлек инкарь итә. Шуның белән бергә, күп очракларда, моны практик тәҗрибәләрнең әлегә җитенкерәмәвеннән дип белергә кирәк. Герменевтиканы хаталы аңлау һәм аңлату да күзәтелә.

Әдәби-текстологик анализ алымын текстология гыйлеме белән бердәй итеп карау очраклары гыйльми һәм гамәли текстология гыйлеме өлкәләрен белеп бетермәүдән килә. Һәрхәлдә әдәби-текстологик анализ методы текстология фәне белән ныклы бәйләнештә тора, әмма аның аерым һәм төп өлкәсе булып санала алмый, бәлки әдәбият белеменә карый. Моның сәбәбе әдәби текстларны өйрәнүгә һәм аларны аңлатырга омтылышка барып тоташа. Әдәби текстологик анализ методлары текстология гыйлеменнән үсеп чыга, шуның аркасында аны гыйльми текстология өлкәсенең фәнни

алымнары белән бутап күзалларга да мөмкин. Һәрхәлдә әдәби-текстологик анализ алымы, тулы килеш булмаса да, татар әдәбият гыйлеме фәнендә туктаусыз кулланыла. Башка төр әдәби анализ методларында да аның кайбер якларын файдаланалар. Бу, үз чиратында, фикер буталчыклыгына китерә. Шушы сәбәпле әдәби-текстологик анализ алымы нигезләрен билгеләү фән өчен методологик яктан әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе икәнлеген монда ассызыклап үтәргә кирәк.

Әдәби-текстологик анализны, тар мәгънәдә алсак, әдәби текстларны шәрехләү, гомумән, шәрех бирү, аңлату дип тә атап булыр иде. Әмма шәрехләү әдәби текстологик анализның төп максаты һәм нәтиҗәсе түгел. Ә әдәби-текстологик анализдан башка шәрехләүгә килергә ярамый. Димәк, герменевтиканы әдәби-текстологик анализның бер өлкәсе дип карарга мөмкин дип уйларга нигез бар.

Татар әдәбият белеме фәнендә герменевтиканың иң затлы үрнәге буларак Т. Ялчыголның (1768-1838) 1796 нчы елда тәмамлаган “Рисаләи-Газизә” хезмәте кала килә. Аның без, хәтта авторы “Шәрхе “Собател-гаҗизин” дип, ягъни Суфи Аллаһиярның “Гаҗизләргә терәк” әсәренә шәрех буларак атаса да, әдәби-текстологик анализ алымына нигезләнеп башкарылганлыгын белдерә алабыз. Моңа Т.Ялчыгол шәрехләүне киң планда аңлау ярдәмендә ирешкән.

Инде әдәби-текстологик анализ алымының нигезләрен барлап, аларга тукталып үтик.

I

Әдәби-текстологик анализ алымы әдәби әсәрне аңлатуга корыла. Шәрехтә, мәсәлән, һәр сүзнең мәгънәсе әһәмиятле. Хәзерге текстологик хезмәтләрдә аңлашылмаучы сүзләргә ас төшермә сүзлекчәләр бирелә. Бу юлдан аермалы буларак, әдәби-текстологик анализ алымы әдәби әсәрнең эчтәлеген ачыклый һәм аңлата. Икенче төрле без аны, гадиләштереп әйткәндә, эчтәлек сөйләүдән гыйбарәт дип билгеләр идек. Чәчмә әсәрләрнең эчтәлеге, драма жанрларыныкы кебек үк, сөйләп бирелә ала. Шигъриятнең эпик формаларында язылган

әсәрләрнең дә эчтәлеген сөйләү һәм аңлату авырлык тудырмый. Әмма лирик поэзия белән эш башкачарак тора. Аның эчтәлеге гади сөйләмгә буйсынмый. Бу мәсьәләне чишү өчен әдәби-текстологик анализ алымы шигырьнең образ һәм символлары бергәлегенә игътибар юнәлтә, аларны барлый, ачыклый, аңлата. Асылда — берләштерә. “Яшерен мәгънә” буларак символ шактый катлаулы эчтәлеккә ия була. Аны дөрес итеп бары тик “культурология тәртибе” (“культурологический ряд”) нигезендә генә ачыкларга мөмкин. Әмма хәзерге шагыйрьләр күпчелек очракта бу “тәртип”не “белмиләр”, яки аны инкарь итеп, үз талантлары кушканча “ирекле мәгънә” салынган символлар кулланалар. Мондый шигырьләр анализланганда галимнән шактый сак булу таләп ителә. Андый символларның мәгънәсен ачыклауның үз методикасы бар.

Мисалга “таң” сүзе белән бәйле символны алып карыйк. Суфичылык әдәбиятында ул Ахирәт көнен аңлата. Ә инде XX йөз башыннан бу символ “кискен үзгәреш” кичерә. Монда европа әдәбиятларының тәэсирен игътибарга алмый мөмкин түгел. “Таң” сүзе, символ буларак, революцион яңарыш, күтәрелешне аңлата башлый. Бүгенге көн шигърияетендә ул “асыл”, “хакыйкать” мәгънәләрен дә йөртә. Моны суфичылыкка хас мәгънәсенә үзгәртелеп кайтартылуы диярәк аңлатырга мөмкин.

Шулай итеп, текстны аңлату тарихилык принцибын таләп итә, шунлыктан әдәби-текстологик анализ алымы әсәрнең эчтәлеген тарихилык принцибыннан читләштереп аңлата алмый.

Әдәби текстны аңлау һәм аңлату иң җиңел ысулга, ягъни “эчтәлек сөйләүгә” генә кайтып кала кебек тоелса да, әдәби-текстологик анализ алымы бу юлында катлаулы мәсьәләләргә очрый. Аларны гомум методик нигездә хәл итү юнәлешен тота.

Шулай итеп, әдәби әсәрнең эчтәлеген ачыклау гади яки катлаулы эш булырга мөмкин. Бу әсәрнең үзенә бәйле. Гади әсәрнең эчтәлеген аңлату җиңел булса да, катлаулы әсәрләр аңлау өчен авыр булалар, аларның текстына төшенү киң

белемнәрне таләп итә. Гади әсәрне аңлатканда ялгышлар булган кебек, катлаулы әсәрне аңлатканда алар күбрәк очрыйлар. Андый катлаулы “урыннар” шәрехләүне таләп итәләр.

Әдәби-текстологик анализ алымы белән эш иткәндә туктаусыз куела торган сораулар текст белән бәйле була: сүзләр дөрес аңлашыламы, аларга автор нинди мәгънәләр салырга мөмкин? Хикмәт — әсәрнең мәгънәсен аңлау-аңламауда. Әгәр дә әдәби әсәрнең мәгънәсенә төшенәбез икән, аның эчтәлеген ачыкладык дигән сүз.

## II

Текстология фәненең төп нәтиҗәләре әдәби әсәрнең авторын, язылу датасын һәм тарихын ачыклауга бәйле. Әмма әдәби-текстологик анализ алымы өчен әсәрнең, язылу тарихыннан бигрәк, язылу сәбәпләре аерым әһәмияткә ия. Дөрес, әсәрнең язылу тарихы белән язылу сәбәпләре үзара бәйләнештә булалар. Әдәби-текстологик анализ бирелгәндә әсәрнең язылу тарихы исәпкә алына, шулай да төп игътибар язылу сәбәпләренә юнәлтелә, чөнки әсәрнең язылу сәбәбе яки сәбәпләре аның текстын аңлау һәм аңлату өчен әһәмиятле булып тора. Моның өчен әсәр язылган чорны, тарихи вакыйгаларны, авторның аларга бәйләнешен яки мөнәсәбәтен белү таләп ителә. Бу белем башкаларга бары тик сөйләп бирү юлы белән генә тапшырыла ала.

Әдәби әсәргә анализ ул — шул әсәр текстының эчтәлеген ачыклау һәм билгеләүдән гыйбарәт дип белсәк, әсәрнең язылу сәбәбе яки сәбәпләре әдәби-текстологик анализ алымы өчен эчтәлекнең масштабын билгеләгәндә кирәк. Ә аны ачыклау исә әсәрнең тарихи әһәмиятен күрсәтә.

Мисалга Г.Тукайның “Китмибез!” (1907) шигырен алырга мөмкин. Язылу сәбәпләре “ачыкланмау” аркасында бу әсәр 1950-1970 нче еллар әдәбият фәнендә пан-төркичелеккә каршы, татар халкын Төркиягә китәргә чакырган татар байларына җавап буларак язылган дип аңлатыла иде. Мәктәп дәреслекләрендә дә шундый фикер җәелдерелде. Әмма бу шигырьнең бүтән төрле тарихи вакыйгаларга барып

тоташканлыгы ачыкланылгач, әсәр бөтенләй башка эчтәлектә “ачылып” китте. 1906 нчы елның 31 нче март император фәрманы нигезендә татарча укытуны бетерү белән турыдан-туры бәйләнеше барлыгы раслангач, әсәрнең урыс карагруһларына каршы язылганлыгы да билгеле булды. Г.Тукайның бу шигыре белән милли телне, милли телдә укытуны яклап чыкканлыгы аңлашылгач, әсәрнең киң масштаблы икәнлеге дә беленде.

Бу мисал әдәби әсәрнең язылу сәбәбе аның асыл эчтәлеген ачыклау өчен аерым әһәмияткә ия булуын төшенергә ярдәм итә. Әдәби-текстологик анализ юлы, шулай итеп, текстология гыйлеме нәтиҗәләрен әдәби әсәрне аңлатуга мобилизацияли һәм шуның белән башка төр әдәби анализ методларыннан аерылып тора.

III

Әдәби-текстологик анализ алымы әдәби әсәрнең эчтәлегеннән, ягъни текст концепциясеннән автор концепциясен, ягъни автор алга сөргән фикерне, бер-берсеннән аерым куеп тикшерә, аларның охшаш булуларын яки каршылыкка килүләрен ачыклый. Бу аңа әдәби әсәрнең эчтәлегенә ирешү өчен кирәк.

Билгеле, күп кенә әсәрләрдә автор концепциясе әдәби әсәрнең үз эченә “яшерелгән” була. Әмма кайбер авторлар, бигрәк тә борынгы һәм урта гасырларның әдипләре, әсәрләренең колофонында (ягъни башлам һәм тәмамлау өлешләрендә) үз концепцияләрен белдерүне мәгъкуль күргәннәр. Шул ук вакытта әсәрнең эчендә дә “мөнәҗәтләр” рәвешендә (бигрәк тә эпик, киң планлы әсәрләрдә бу шулай) автор концепциясе бирелергә мөмкинлек булган.

Әдәби-текстологик анализ алымы белән эш иткән вакытта авторның үз концепциясе чагылган кисәкләр төп тексттан аерып алына һәм берсе икенчесенә чагыштырма планда анализланалар. Әгәр дә андый “үзеннән-үзе” аерымланучы “автор сүзе”, “лирик чигенеше”, “автор белдерүе” юк икән, ул вакытта әсәр тарафыннан калку итеп алга сөрелгән фикерләр автор концепциясе буларак исәпкә алына, әсәрнең

анализыннан чыккан фикер исә әсәрнең үзенең эчтәлеге сыйфатында тикшерелә. Монда әдәби әсәргә тарихилык принцибы белән “якын” килергә кирәк. Тарихилык принцибы автор концепциясен ачарга ярдәм итә, язучының ни әйтергә теләгәнлеген ачыклау көченә ия.

Мисалга Т.Миңнуллинның “Әлдермештән Әлмәндәр” моңсу комедиясен алырга мөмкин. Әсәр Әҗәл фәрештәсе белән Әлмәндәр карт арасындагы “конфликтка” корылган. Әлмәндәр карт эш сөя (үзе авылда яши, ә бакчасында дача төзеп маташа – бу мөгаен көлке өчен шулай уйлап чыгарылгандыр?), Хәмдебануга өйләнмәкче, ачы бал эчә, гарип-горабаны сөйми һәм башкалар. Автор концепциясе буенча, Әлмәндәр шушы сыйфатлары аркасында Әҗәлдән өстен, кеше шундый булырга тиеш. Әмма текст эчтәлегеннән Әлмәндәр хәйләкәр, ялганчы, эчүне һәм зинаны да читкә куймаучы буларак аңлашыла. Бу каршылык көлке тудыру өчен эшләнелгән, әлбәттә. Укучының Әлмәндәрне “ил карты” дип кабул итүе исә идеянең автор концепциясенә салынып бирүе аркасында барлыкка килә.

Монда автор концепциясе укучыга үзенчә тәэсир итә, фикер тудыруда текст концепциясе әсәрнең идеясен бирә. Бер текст, шулай итеп, ике катламнан торырга мөмкин. Бу катламнар берничә дә була алалар, андый күренешне әдәбият белеме фәнендә “полифония күренеше” дип, музыкаль термин белән атыйлар. Әдәби текстологик анализ вакытында шушы катламнар ачыкланылып, аерым-аерым анализлана, шул юл белән әдәби әсәрнең эчтәлеге ачыла.

Әдәби әсәрне анализлаганда автор концепциясенә иярү субъектив фикерләүләргә, субъектив нәтиҗәләргә этәрә. Объектив бәя бирү өчен әсәр, ягъни текст концепциясен автор концепциясеннән аера белергә, аларны аерым-аерым тикшерергә, чагыштырырга, бер төрле яки аермалы булуларын ачыкларга кирәк.

Автор концепциясен субъектив фикергә генә кайтарып калдырырга, әһәмияте юк дип белдерергә ярамый. Ул, асылда, хәтта текстның язылу сәбәбен аңлау һәм төшенү өчен дә төп дәлил булып тора.

Шулай итеп, әдәби-текстологик анализ ул әдәби әсәрнең язылу сәбәбен ачыклаудан, әдәби әсәргә герменевтик анализ ясаудан, ягъни текстка шәрех бирүдән һәм әдәби текстны берничә катламда, ягъни автор концепциясе һәм текст концепциясе юнәлешләрендә тикшерүдән, аларны чагыштырып бәяләүдән гыйбарәт. Бу анализ юлы әдәби текстны объектив фикер нигезе итеп карый, шуның ярдәмендә хакыйкатьне ачыклауга ирешә. Аның максаты да шушыңа, ягъни әдәби әсәрнең эчтәлеген объектив планда аңлау-аңлатуга юнәлдерелгән.

***Мисал*** итеп Һ.Такташның "Нәни разбойник" әсәрен алып тикшерергә мөмкин. Галим һәм язучы М.Мәһдиев бу әсәрнең 1990 нчы елларда ук мәктәптә укытылырга лаеклы түгеллеген, балаларга тәрбия бирү урынына, аларны бозуын берничә кат аңлатып язып та чыкты. Әмма күпләр аның белән килешергә теләмәделәр. Ике якның да дәлилләре ышандырырлык анализга корылмау да моңа сәбәпче булды. Менә шуңа күрә дә Һ.Такташның бу әсәренә объектив фәнни бәяләмә бирү зарурлыгы хәзерге көндә дә актуаль булып кала килә. Әдәби-текстологик анализ алымы бу мәсьәләне чишүдә дөрес юл була ала.

I. *"Нәни разбойник"ның язылу сәбәпләрен ачыклыйбыз.*

1. Һ.Такташ бу шигырен Казанда 1925 нче елның 18 нче февралендә иҗат иткән. Шагыйрь бу әсәренең язылу сәбәпләрен үзе болай дип аңлата: "Нәни разбойник" шигыренең бу юллары меңнәрнең башына шул тәрбиясез яшьлеген исенә төшергәндер. Казлар кыйнап үскән меңнәрчә кешеләр хәзер партия сафында — бөек көрәшнең солдатлары, шуларның берсе Такташ — хәзерге көндә "назлы, мактаулы" шагыйрь..." (*Карагыз:* Такташ Һади. Әсәрләр өч томда.— Т.I. Шигырьләр һәм поэмалар.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1980.— Б.474. "Искәрмә һәм аңлатмалар" бүлеге.).

Димәк, "Нәни разбойник"ның язылу сәбәбе ачык, ул коммунистларга үзләренең электә кем булуларын исләренә төшерер өчен язылган.

2. Авторның субъектив фикере “элек кем идек тә хәзер кем булдык” дигән гыйбарәгә сыеп бетә. Элек “ата казлар кыйнап үскән” нәни разбойниклар инде җитлеккәннәр, “салкын тайгада яз ясаячаклар”, “ачулансалар, айга да шлем киертәчәкләр”, ягъни, менә нинди булдыклы кешеләр, алар дөньяны үзгәртергә алынганнар. Аларга юлны Ленин үзе күрсәткән.

II. *Әсәрнең эчтәлеген ачыклау, аңа шәрех бирү, аны аңлату этабы. Монда һәр символ, образ, әсәр вакыйгасы сөйләнелергә, шәрехләнергә тиешле.*

“Нәни разбойник”ка автор эпиграф итеп үз әнисенә рәхмәт шигырен биргән. Асылда эпиграф ул әсәрнең темасын ачарга ярдәм итәргә тиеш. Димәк, тема белән турыдан-туры бәйләнештә тора.

Эпиграфта шагыйрь әнисенә үзен тудыруы һәм “төннәр буе йокламыйча”, “җырлый-җырлый багуы” өчен рәхмәт әйтә. Әмма “авыр кара тормышында әнкәсенә ярдәмче була алмавын” искәртә. Ул аңа ярдәме тисенгә түгел, бәлки “авыр көрәш һәм бөек еллар өчен” туган икән. Димәк, Һ.Такташ, “Нәни разбойник” дигәнендә, бөек эшләр кылырга тиешле көрәшченең балачагын күздә тота булып чыга.

*Әсәрнең эчтәлеге.* Лирик герой үзенең усал булганлыгын искәртә һәм башкаларга күрсәткән яманлыкларын саный башлый. Ул, гөнаһ дип тә белмичә, “зәңгәр төндә күрше карчыгының ак әтәчен урлаган”. Караклык, әлбәттә, зур гөнаһ. Монда “зәңгәр төн” һәм “ак әтәч” символик мәгънә төсмерендә килсәләр дә, асылда андый мәгънәгә ия түгелләр. “Күрше карчыгы” исә үзе дә усал икән, ул лирик геройны: “Денеңнән яз, явыз, урыс!”— дип каргый.

“Ден” — борынгы төрки сүз. Ул хәзерге телебездә “тын” формасында кулланыла, борынгыларда “җан”, “рух” мәгънәләрендә булган. Гарәп сүзе “рух” һәм фарсы сүзе “җан” кулланылышта активлашкач, җанның билгесе булган “тын” мәгънәсендә генә калган. Әмма ислам дине һәм мәдәнияте йогынтысыннан читтә калган төрки телләрдә ул бүген дә

“җан” мәгънәсендә йөри. Татар әдәби телендә дә борынгырак гыйбарәләрдә сакланып калган.

“Явыз” һәм “урыс” сүзләре тиңдәш кисәкләр формасында килгәннәр. Гыйбарәдә “явыз” белән “урыс” бергә килә. Алар “разбойник” сүзе белән уртак эчтәлеккә ия. Шул рәвешле “явыз”, “урыс”, “разбойник” сүзләре шигырь текстында үзара тәңгәлләшәләр.

Алга таба шигъри сурәт бирелә, аны лирик чигенеш дип тә билгеләргә була. Монда Һ.Такташның хис шагыйре икәнлеге ачык сиземләнә: “Кышкы төннең салкын күкрәгеннән Чаналар да шаулап үттеләр...” Шул “чаналарда” лирик геройны “еллар бик еракка алып китәләр”. Елларның алып китүе, әтәч пешергән учакларның әллә кайчан сүнүе күп вакытларның үткәнлеген тоярга ярдәм итә.

Лирик герой тагын үз усаллыкларын исенә төшерә. Ул карчык-корчыкларга бик күп бәла-казалар китергән, бакчасына кергән “үрдәкләрен таяк белән кыйнап үтергән”. Бөтен усаллыкны аннан күргән авыл халкы аны “разбойник” дип атаган.

Тексттагы хәбәрләр лирик геройның чыннан да “разбойник” булуына ышандыра. Шигырьнең дәвамында тагын гомер узуы искәртелә. Лирик герой кабат усаллыклары хакында сөйли. Бу юлы аның “разбойник”лыктан баш тартмавы аңлашыла бара, ул туган авылындагы “муллаларны кыйнап үтәргә” нияте барлыгын әйтә, шуны дәгъва кыла. Һәрхәлдә заманасы өчен муллаларны “кыйнау” “дөрес гамәл” буларак күзалланган. Илдәге социализм төзү дәвере мондый “геройлыклар” белән тулы. “Муллаларны кыйнау” лирик геройның сыйнфый көрәшче булып китүен искәртергә тиеш исә дә, автор аңа башка төсмер дә бирә: “Сагынып сөйләр өчен ядкәр итеп” кыйнамакчы икән ул. Хикмәт бары тик хулиганлыкка гына кайтарылып калдырыла.

Алга таба шагыйрь тагын да еллар үтүен тәкрарлауга кайта, бу юлы гомумиләштерү ясап, үзенә алмашка килүче яшь коммунарларның әле дә ата казларны кыйнап үсүен белдерә. Монда “ата казлар кыйнау” символ мәгънәсендә түгел. Димәк, тексттан шул аңлашыла, коммунар булып үсү өчен ата

казларны кыйнарга кирәк икән. Көлкеле сурәт итеп күзаллаганда, калку куелган бу фикер әсәрнең эчтәлеге белән бергә ачылыр иде. Әмма монда ул авторның очраклы әйтелгән фикере рәвешендә кала.

Усаллыгы аркасында лирик герой “авылга сыймаган”, “тилергән хисләр җырчысы булган”, “сезгә килгән”. Монда шагыйрь “сезгә” дип читкә китүен күздә тота.

“Давыл сүнәр”, ди ул, революцион үзгәртелешләрне давыл эпитеты ярдәмендә биреп. Үзе үлсә, алмашка аның улы калачак һәм ул “соңгы көрәштә солдат булыр”. Менә шунда әсәргә солдат образы килеп керә, ә ул — шлем киеп йөри. Әгәр дә алга китеп, “шлем киертербез Айга да” дигән сүзләренә игътибар итсәк, аны да солдат итәчәкләре хакында сүз барганлыгы аңлашыла башлый. Шлемлы солдат, һәрхәлдә, кызылармеец инде ул, Советлар иле өчен көрәшүче, аның сагында торучы каһарман, Гражданнар сугышы герое.

Еллар көрәш чиген үтәрләр,
Яшьләр тимер булып үсәрләр,
Ата казлар кыйнап үскән яшьләр
Буржуйларны тотып кисәрләр...

Димәк, тимер булып үсәр өчен “ата казлар кыйнап үсәргә” кирәк икән. Шул вакытта алар буржуйларны тотып кисәчәк буын булырлар.

Монда шагыйрь үз фикер концепциясен өстен чыгару өчен махсус кабатлана. Әмма текстның үз фикри концепнциясе инде ныгып өлгергән, балансны сакларга кирәк. Шуның өчен автор көтелмәгән чигенеш ясарга мәҗбүр. Моны аның үз фикерен укучыга көчләп тагасы килмәве белән генә аңлатып була.

Көтелмәгән чигенеш маяклы кышкы юлдан чанасын печән белән күмгән юлчы килүен сурәтләү белән бәйле. Ул юлчы Мәккә каласын тупка тоттырган Англиянең чит илләр министры Остин Чемберлинны (1863–1937) сүгенеп ачулана. Маяклы юл ул элекләрне кышкы бураннарда адашмас өчен юл буйлап кадап чыгылган агач ботакларыннан гыйбарәт булган. “Сатыйм анасын” сүзтезмәсе татар халкында сүгенү өчен кулланылган. Монда изгелек, ягъни Мәккә каласына хөрмәтле мөнәсәбәт һәм усаллык, ягъни сүгенү аша бирелгән

хулиганлык бергә бәйләнештә килә. Моңа кадәр эчтәлектә үстерелә килгән текст концепциясендәге ике тема — яманлык белән яхшылык мәсьәләсе монда бер юнәлешкә җыела. Әсәргә дин белән бәйләнешле фикер килеп керә.

Шагыйрь аны тема итеп үстерә башлый. Лирик герой үзенең динсез булганлыгын исенә ала, шуңа күрә аннан "эткәсе кулын ташлый", ягъни аңардан кулын селти, ваз кичә, "бу имгәктән кеше чыкмас, Иблис булыр", ди. Иблис, икенче төрле — Шайтан, кешеләрне аздыручы явызлык иясе, кешелек дошманы. Ул Аллаһы әмереннән чыкканы өчен Иблис аталган, башбаштаклык, гыйсьянчылык, мин-минлек символы.

Шигырьнең бу өлешендә юлчы белән лирик герой каршы куелалар. Аның берсе — усаллык иясе, икенчесе — усаллыкны усаллык белән инкарь итәргә теләүче, ачуланучы.

Текстта ике фикер концепциясе туктаусыз үстерелә: аларның беренчесе усаллык иясе хакында, икенчесе аны моның өчен ачуланулар турында. Ә еллар һаман үтә торалар. Шагыйрь әсәренә мөмкин кадәр полифоник яңгыраш бирергә омтыла, фикер сызыкларын саклаган хәлдә, аларны эчтәлектә тирәнәйтә. Әсәрнең төзелеш үзенчәлеге, корылмасының нигезе шуңардан гыйбарәт. Мондый алым татар әдәбиятында Һ.Такташка кадәр очрамый.

Еллар уза, ата казлар кыйнап, шалкан урлап үскән лирик герой шагыйрь булып җитлегә. Ул этисе алдында мактанырга тели. "Юлдан язарына" Ленин үзе "юл күрсәткән" һәм кулына "үткен каләм" биргән. Монда "үткен каләм" күчерелмә мәгънәдә килә, ул шагыйрьнең сүз иреге алуы турында сөйли торган берәмлек.

Автор тагын вакыт узуын сурәт аша белдерә, кичәге февральне кар ашаучы нечкә билле март җиле алыштыра. Майга да ерак калмаячак, салкын тайгада яз ясаячаклар әле. "Җир безнеке булыр" дигәнендә әлбәттә бөтен дөньяда революцияне җәелдерү хыялы хакында сүз барганлыгын аңлавы кыен түгел. Әгәр "ачулансак", ди ул, "шлем киертербез Айга да". Бәлки шушы рәвешле автор хәтта галәмнең "разбойник"лар кулында булачагын әйтергә телидер?

Һәрхәлдә сүз Айны да кызылармееӊ “ясау” мөмкинлеге хакында бара, тик моның өчен “ачу килү” генә кирәк, имеш.

Шигырь сагынып сөйләр өчен авыл мулласын кыйнап үтәргә исәбе барлыгы, лирик геройның күрше карчыгына кисәтеп куюы, инде бер тапкыр әйтелгән фикеренең кабат искәртелүе белән тәмамлана.

Мулланың гаебе нидә икән дигән сорау тумый калмый, билгеле. Монда автор мөгаен муллаларның дини тәгълиматны алга сөрүләрен түгел, бәлки хәрәм-хәләл, гөнаһ-савап кебек этик кагыйдәләрне билгеләүчеләр һәм саклаучылар булуларын истә тоткандыр? Һәрхәлдә замана шаукымы да чагылмый калмаган, анысы.

Шигырь эчтәлегеннән шул аңлашыла: Һ.Такташ “разбойник”ны афәрин кеше итеп сурәтли, ул киләчәк тормыш өчен көрәшүче икән.

III. А*втор концепциясеннән текст концепциясен аеру һәм аларны чагыштыру*.

Әсәргә шәрех биргәндә үк концепцияләргә ачыклык кертелеп барылды, чөнки мәсьәләне тикшергәндә кабат шул ук эчтәлеккә мөрәҗәгать итәргә һәм аны сөйләргә, аннан дәлилләр китерергә мәҗбүр булыр идек. Шунлыктан анализның бу пунктында гомуми фикерләмәләр белән эш итәргә мөмкинлек туа.

Нәрсә соң ул *текст концепциясе* дигәндә, аны күпләр катлаулы итеп аңлата һәм аңлатмаларда буталчыклык тудыралар. *Текст концепциясе* әсәрнең кем турында, нәрсә хакында барганлыгына бәйле, аның эчтәлеге темада чагылыш таба, әмма ул теманы алыштырмый. Шулай итеп, әдәби әсәрнең *текст концециясен* тема белән бәйләнештә дип белдерә алабыз һәм аны темадан чыгарырга тиешбез.

*Автор концепциясенә* килгәндә, ул әдәби әсәрнең идеясенә якын тора, аның белән бәйләнештә була. Идея, шулай итеп, *автор концепциясенең* әдәби әсәрдә чагылышы ул, ягъни *автор концепциясе* әдәби әсәрнең идеясе өчен хезмәт итә һәм аны ачыклауга юнәлдерелә.

“Нәни разбойник”та мондый фикер алга сөрелә: элекке “разбойник”ларга Ленин юл күрсәткән һәм алар “юлга кергәннәр”, инде “салкын тайгада яз ясаячаклар”, “Айга да шлем киертәчәкләр”, әгәр ачулары килсә, әмма “ядкәр өчен” авылларындагы муллаларны кыйнап китәселәре бар. Димәк, “Нәни разбойник” шигыре кичәге “разбойник”ның бүген “коммунар”, “партия солдаты” булуы турында. *Текст концепциясе* тема белән бәйле дип карасак, димәк ул “разбойник”ны сурәтләүдән, аның чыннан да разбойник булуын раслаудан гыйбарәт.

*Автор концепциясе* исә әсәрнең идеясенә бәйле, дидек. “Нәни разбойник”, димәк, *автор концепциясе* буенча караганда, көрәшче-коммунарның, “партия солдатының” яшьлеге ул, ягъни кечкенәдән “разбойник” булып ныгып, “гөнаһ-фәлән дип уйлап тормыйча” үскәндә генә синдә көрәшче рухы яши.

Ике концепция дә үзара туры килгән төсле, әмма аерма да бар, ул нюанслар дәрәҗәсендә: *текст концепциясе* “разбойник”ны акламый, *автор концепциясе* аны олылый, аны яңа заман кешесе итеп күрсәтә. Әсәрдә сурәтләнелгән детальләр, искә алынган фактлар *текст концепциясенә* карыйлар, алар “нәни разбойник”ның чыннан да гөнаһ иясе булуын раслыйлар. Әмма *автор концепциясе* “разбойник”ны аклауга юнәлдерелгән, моның өчен шагыйрь заманага хас көрәш рухын алга сөрә. Идея темадан өстен чыгарыла, ягъни *текст концепциясе* исә *автор концепциясенә* буйсындырыла: көрәш рухы кичәге “разбойник”лардан үскән бүгенге коммунарда яши икән! Юкса *текст концепциясеннән* бөтенләй башка фикер аңлашылыр иде: дөньяның алга барышы “разбойник”лар кулында мәгънәсендә.

Автор концепциясе белән текст концепциясе арасында нюанслар дәрәҗәсендә булса да туры килмәүчелек иртәме-соңмы әсәр тирәсендә төрле бәхәсләр тудыра башлый. Әмма аларның туры килүе әсәрне талантлы итә, билгеле.

Әдәби-текстологик анализда иң авыры — өченче пункты. Беренче икесендә фикерләүнең таяну нокталары конкрет, ачык

күренеп торалар. Өченчесендә мәсьәлә шактый катлаулана, әсәрне тикшерүчедән аналитик фикерләү осталыгы таләп ителә башлый. Әдәби әсәрләрне анализлау эше белән даими шөгыльләнгәндә әлбәттә мантыйкый фикерләү дәрәҗәсе дә арта бара.

Монда шуны киңәш итәргә кирәк, текст концепциясен ачыклау өчен мөмкин кадәр әдәби әсәрдә алга сөрелгән идеядән читкә китәргә, вакыйгаларга, каһарманнарның эш-гамәлләренә гомумкешелек принципларыннан чыгып бәя бирергә, теманы ачыклый белергә өйрәнергә кирәк. Автор фикеренә генә ияреп йөрү ул — аңда томаналык кына тудыруга сәләтле.

Без күпчелек очракта авторны төшенергә тырышабыз, шуның белән әдәби әсәрне, текстны аңларга омтылуыбызны чиклибез. Дөрес, текстны автор тудыра һәм аны үз фикер юнәлешенә мөмкин кадәр буйсындырырга тели, әмма ул сурәтләгән материал автор фикерен куәтләр өчен хезмәт итмәскә тә мөмкин. Бигрәк тә күчерелмә мәгънәдә сөйләргә мәҗбүр булганда, төрле сәяси һәм иҗтимагый кысулар дәверендә авторлар әсәрнең идеясен үз концепцияләренә түгел, текст концепциясендә чагылдыру юлына баралар. Шуның өчен дә автор концепциясе белән текст концепциясе мәсьәләсен читкә кагарга киңәш итмәс идек.

**Алда аңлатылганнарга өстәмә рәвештә тагын да берничә мисалны карап үтәргә мөмкин.**

1) *Г.Тукайның* ***“Шүрәле”*** *экият-поэмасына әдәби-текстологик анализ нәтиҗәләре:*

Бу экият-поэмасы шагыйрьнең “3 нче дәфтәр”ендә (1907) беренче тапкыр басылып чыккан. Әсәрнең ахырында автор аны “хикәя” дип атый, А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтовларның үрнәгендә “авыл җирендә сөйләнгән хыялый хикәяләрне язуларына” ияреп иҗат итүен белдерә. Алга таба татарлардан да оста рәссамнар чыгып, Шүрәленең “кәкре борынын, озын бармак, мөгезле башларын һәм дә кулы кысуларын”, урманны сурәтләп бирәчәкләренә өмете барын яза, мондый авыл

хикәяләрен халыкның үзенә кабат кайтарып бирүнең бары тик файда гына икәнлеген аңлатып уза. Шушы язмасы ахырына “Г.Т.” имзасын куя.

Әсәр биш бүлекчәгә бүленгән. Эчтәлегеннән чыгып караганда, ул ике өлештән, ягъни лирик һәм эпик кисәкләрдән гыйбарәт. Лирик өлеше беренче, икенче, өченче бүлекчәләрдә бирелгән. Беренче бүлектә Кырлай авылы турында языла, Г.Тукай Кырлай сүзенә көй өчен “тавыклары җырлай” тезмәсенең рифмалашып килүен, Кырлай халкына шушы сүзләр белән, ягъни “Кырлай — тавыклары җырлай” дип үртәк ясауларын шаянлык белән искәртеп уза, моның белән әсәргә күңелле төсмерләр бирә, шушы авылда бераз яшәп китүен, кыр эшләрендә катнашуларын исенә ала.

Кырлай авылы лирик геройның хәтерендә урманнар эчендә, яшел хәтфә үләнле болыннары белән уелып калгандай аңлашыла. Әмма ул авыл зур түгел икән, кечкенә инеш буена урнашкан, һава торышы да монда уртача, яңгыр да вакытында ява, җил дә вакытында исә, урманы тулы кызыл җиләк, күзне ачып йомганчы аны бер чиләк җыясың, чыршы-наратлары да гаскәр кебек тезелешеп торалар, аларның төпләрендә хәл җыеп, күккә карап лирик геройның ятканнары да булган.

Бу тасвирларны Г.Тукай әкият дөньясын күз алдына китертү максатында шушы рәвешле бирә, әсәре белән укучының күзаллавын чынбарлыктан әкият дөньясына алып китә. Монда шагыйрьнең әдәби иҗат осталыгы да соклану тудыра. Сурәтләрне тагын да көчәйтеп, агачлар, гөлләр, чәчәкләр хакында язып узганда, әдип хәтта “яшелдән чәчәкләр” дип тә тасвирлап ала, гүяки яшел төстәге чәчәкләр дә Кырлай урманында бар икән дигән фикер уяна, моның белән әсәрнең әкиятилеге тагын да арта сыман. Күбәләкләр, Ходайның кошлары, ягъни җәннәт кошлары да тасвирга алынып искәртеп узыла, аларның сайравыннан җаннарның киселүе-хозурлануы хакында языла. Бу күренешләр бульварларны, клубны, танцевальняны (бию урыннарын), цирк, оркестр, театр, концертны алыштыруы хакында фикерләрен биреп, Г.Тукай табигать белән мәдәниятне үзара бәйләнештә икәнлеген, берсе икенчесен алыштырырга

мөмкинлеген белдереп уза. Урманның чиксезлеге тарихи Чыңгыз хан гаскәрләре белән тиңләштерелеп, эчтәлеккә милли тарихи тойгылар өстәлә. Шагыйрь бу тойгыларны тагын да тирәнәйтеп, бабайларның батырлыклары, дәүләтләре, дәрәҗәле исемнәре "кылт итеп искә төшәдер" дип искәртеп уза да, үз чорына укучының уйларын кире кайтарып, нигә без хәзер "болай соң?" дип аһ та орып, милли аңны уятып ала. Шуның белән беренче бүлек тәмамлана.

Икенче бүлектә көз һәм кыш көннәрен, чибәр кызларны язуга күчүен белдереп, әмма җыен, сабан туйларын уйлары еракка китмәсен өчен язмаска иткәнен әйтеп уза да, сүз башының, ягъни сөйләргә җыенганының Шүрәле хакында булуын искәртә. Шагыйрь шушы рәвешле укучының хис-тойгыларын җиңелчә генә үртәп-көчәйтеп ала һәм шулай өченче бүлеккә күчә.

Бу бүлектә Кырлай урманын ул "кап-кара урман" дип атый, анда аю, бүре, төлке, куян, поши һ.б. төрле киек-җанварлар булуын, аларны аучыларның очратуларын искәрткәч, җен-пәри, албасты, убыр, шүрәлеләрнең төрлесе барлыгын да белдереп, укучысын әкият дөньясына шагыйрь тулысынча алып кереп китә, реальлек һәм шагыйранәлек арасында хисләре куерган укучы әкияткә ышаныр хәлгә җиткерелә. Мифик-әкияти җан ияләренең дә булу-барлыгының сәбәпләрен шагыйрь урманнарның калынлыгына, күкләрнең очсыз-кырыйсыз булуына бәйләп әйтеп уза.

Шушылар белән "Шүрәле" әсәренең лирик өлеше тәмамлана. Моннан соң, искәртелгәнчә, дүртенче бүлектән эпик кисәк башланып китә. Анда да шагыйрь вакыйгаларны сөйләүгә тиз генә күчми, ике шигъри юлда укучының дикъкатен сынап ала, "аз гына җырлыйм әле, көйлим әле" дип куя. Бу рәвешле "күчешләр" бирүе әкиятчеләрнең әкият сөйләү манерасын да кабатлый, шулай укучының күңел күзе каршысына авылдагы әкият сөйләүче әби-бабайларны китереп бастырган сыман итә.

Эпик вакыйгалар матур айлы кичтә Кырлай авылының бер егете урманга утынга ат җигеп ялгызы китү хәбәре белән башлана. Ул бик тиз барып җитә. Шагыйрь инде укучының

күңелен ялыктырмый. Утын кисүне дә тиз-тиз башкару рәвешендә тасвирлый һәм, шиккә салып, җәйге төннең бераз салкынлыгы, урманда тып-тыныч булуы язылa. Утынчының балта тавышыннан гайре авазлар монда юк. Эшеннән егет туктамый. Әмма күңелгә салынган шик алда нәрсәдер буласын искәртә. Автор, курыкмаска өндәгәндәй, шик-шөбһәләрдән гүяки арындырырга теләп, егетнең “балтасы кулда” булуын белдереп ала да, шунда ук бер ямьсез-ят тавыш ишетелеп, нәрсәнеңдер кычкыруыннан егетнең, сискәнеп, аяк үрә катып калуын әйтеп ала.

Шүрәле “кот очарлык, бик килешсез”, “бармак кебек бөгелгән кәкре борынлы”, аяк-куллары ботак-тармак кебек рәвешле, эчкә баткан ялтыравык күзле, ялангач, нәзек, әмма кеше сыман гәүдәле, бармаклары исә төз һәм ярты аршын озынлыгында итеп Г.Тукай тарафыннан сурәтләнелә. Шуның белән дүртенче бүлек тәмамлана.

Бишенче бүлектә вакыйгаларның төп өлеше бирелә. Шүрәле белән бик озак карашып торгач, егет: “Сиңа миннән ни кирәк?”— дип сорый. Ә Шүрәле аны шикләнмәскә өнди. Карак та, юл кисүче (юлбасар) ише дә булмавын, әмма бик үк тугыры да түгел икәнлеген белдерә. Егетне очратуына бик сөенүен, кешеләрне кытыклар өчен бармаклары яратылуын, көлдереп үтерүен яшерми әйтә дә, егетне кытыклы уйнарга чакыра.

Ә егет шунда ук аңа ризалыгын бирә, әмма бер шарты бар икән Шүрәлегә. Кисек агачны арбага күтәреп салышырга булышуын сорый. Бүрәнәне, күтәреп салу өчен авыр булганга, егет урталай яра башлап, аның бер башына чөй каккан икән. Шүрәлегә бармагын ул шул ярыкка тыгарга куша. Аны шунда хәтта “урман сарыгы” дип тә атый, ягъни Шүрәленең аңсыз-акылсыз булуын искәрүен сиздереп ала.

Егетнең сүзенә Шүрәле күнә, эре-эре атлап барып, бармагын “авызын ачкан” бүрәнә ярыгына китереп тыга. Шагыйрь шунда егетнең хәйләкәр икәнлеген укучысына искәртә дә, аның агач ярыгына кыстырылган чөйне балта белән бәреп чыгара башлавын яза. Бу урында Г.Тукай әсәрдә вакыйгалар барышын акрынайта. Егет балта белән суга тора,

Шүрәле кузгалмыйча көтә. Менә чөй чыгып оча. Шүрәленең бармаклары кысылып кала. Ул әрнеп кычкырып җибәрә. Ычкынмакчы итә, сызлана, башка Шүрәлеләрне ярдәмгә чакыра. Изгегә сабышып, тәүбә итеп, егетнең кызгануын, бу бәладән коткаруын үтенә, нәселенә-улына тимәячәген әйтә. Ул хәтта башкалардан да кимсеттермәячәк икән аларны, урманда ирекле йөрергә дә ирек бирәчәк, имеш. Шулай тартыла, йолкына, акылыннан шаша. Ә егет өенә китәргә маташа. Ул ат башыннан тоткан, Шүрәленең үкерүләрен асылда ишетми дә.

Егетне Шүрәле мәрхәмәтсез дип атый, үз дусларына белдерер өчен аның исемен сорый. Егет Былтыр исемле икәнлеген әйтә, егетлек иясе кеше булуын "бу егет абзаң булыр бу" дигән сүзләр белән төшендереп бирә.

Шүрәле һаман да ычкыныр өчен тырыша, котылса, егеткә берәр зыян салырга итә һәм: «Кысты, харап итте явыз "Былтыр" мине!..» — дип кычкыра бирә.

Иртәгесен, башка шүрәлеләр җыелып, шушы сүзләренә җавапта бу Шүрәлене хурлап, хаталы аңлауларын яшермичә, былтыр кысканга быел кычкырма, диләр. Әсәр шуның белән тәмамлана. Анда егетнең батырлыгы, Шүрәле кебек җан ияләренең ахмаклыгы, беркатлы булулары тасвирлана.

Г.Тукай "Шүрәле" экият-поэмасын халык экиятенә нигезләнеп язганын вакыйгаларны сурәтләү барышында төрле формаларда искәртә. Г.Тукайныкы кебек үк эчтәлектәге халык экиятенең тәүге әдәби варианты беренче тапкыр Т.Яхинның "Дәфгыль-кәсәл минәс-сабийавә сабийати, ягъни яшь ир балалардан һәм яшь кыз балалардан ялкаулыкны җибәрә торган хикәяләр" (1900) хрестоматиясендә дөнья күрә. Ул анда чәчмә формада бирелгән, шулай да Г.Тукайдагыча "хикәя" исеме астында урнаштырылган.

Г.Тукай үзенең "Шүрәле" әсәрен, истәлекләргә караганда, Уральски шәһәре янындагы Урал елгасының тармагы булган Чаган буенда җәен 1907 нче елда ял иткән вакытында язган. Әсәр 63 куплет-бәеттән гыйбарәт. Тезмәләр янәшә рифмалы, рәмәл үлчәмендә төзелгәннәр. Кыйсса калыбында язылган әсәрләренең берсе. Тасвирларының экияти булуы белән аерылып тора.

Г.Тукайның “Шүрәле”се әкият-поэма жанрына карый. Кайбер галимнәр аңарда баллада жанрының да үзенчәлекләрен табалар. Әмма “Шүрәле”дә балладаларга хас булган метрик алымнар һәм рифма үзенчәлекләре, эчтәлектә ачык чагылган легендарлык мотивы юк, ягъни анда баллада корылырга тиешле поэтик үзенчәлекләр кабатланмый.

2) *Г.Тукайның* ***“Су анасы”*** *әкият-поэмасына әдәби-текстологик анализ нәтиҗәләре:*

Әсәр беренче тапкыр “Җуаныч” исемле балалар өчен чыгарылган җыентыкта (“Сабах” көтепханәсе, И.Н.Харитонов матбагасы. Мәктәп мөкяфәтеннән беренче китап.— Казан, 1908) басылган, тексты шуннан алынып, Г.Тукайның җыентыкларына һәм күптомлыкларына кертелгән. Эчтәлеге буенча әсәрдән балладага хас үзенчәлекләр табарга мөмкин булса да, формасы һәм вакыйгаларның бирелеше белән шигъри формада язылган әкият, ягъни әкият-поэма икәнлеге аңлашыла. Г.Тукайның 1907 нче елда язылган “Шүрәле” әкият-поэмасы кебек үк балалар өчен татар халык иҗатына нигезләнеп иҗат иткән иң яхшы әсәрләреннән берсе. Вакыйгаларның бирелешендә һәм чишелешендә әкияти формалар өстенлек итә, әдәп һәм әхлак тәрбияләүдә әһәмияте зур, кеше әйберенә сораусыз кагылырга ярамауны өйрәтә.

Су анасы татар халык иҗатының мифологик образларыннан берсе. Ул, күзаллаулардан билгеле булганча, асылда суда яши, Әстерхан татарлары ышануы буенча, хәтта иске мунчада да һәм су тегермәнендә дә, хәтта борынгы зиратларда да очрарга мөмкин икән, ир затындагылары *Су атасы, Су бабасы* кебек исемнәр белән атала, нәселе ир һәм хатын җенесеннән үрчи. Үзе кеше сыманрак, әмма борын сөяге юк, бер борын тишеге генә бар. Тәне вак канат сыман йомшак йон белән капланган. Аяклары артка таба карап торалар. Күкрәкләре зур һәм җиргә кадәр салынып төшкәннәр. Аларны җилкәсенә ташласа, артыннан ат белән дә куып тоту мөмкин түгел. Кешеләрне суга батырып үтерә.

Чәчләре озын һәм килбәтсез. Аларны алтын тарагы белән тарый. Әгәр дә аның чәч бөртеге синдә булса, зыян итә алмый,

курка. Г.Тукай да аны тузгыган чәчле һәм куркыныч хатын дип яза. Су анасын Әстерхан татарлары, күпчелек очракта, *албаслы* дип атыйлар, ә Орунбург һәм Себер татарлары, Казан татарлары кебек үк, *Су анасы* дип беләләр, һәртөрле су да, хәтта җыелып торганы да Су анасыз булмый, имеш. Аның чәчләре озын, ә күкрәкләре тезләренә кадәр, диләр.

Казан татарларының ышанулары буенча, Су анасы яр кырына еш чыгып утыра һәм озын чәчләрен тарый. Кулында алтын тарагы бар. Чәч толымнары — кара, озын, үзе буе. Тәне — ямьсез, кызгылтрак. Башы — зур һәм озынча. Күзләре — кара, шар кебек кабарынкы. Күкрәкләре — киң һәм зурлар. Су астында пыяла сарайда яши, имеш. Яхшылыклы кешеләргә карата яхшы мөнәсәбәттә, начар кешеләрне сөйми. Өлкәннәрне, бигрәк тә балаларны су кергәннәрендә, яисә су алырга төшкәч, суга батырып үтерә. Терлек-туарны, кош-кортны, эт һәм песи ишене су эчкән вакытында суга суырып ала. Г.Тукай сурәтләгәнчә, Су анасы алтын тарагын чәч тараган урынында онытып калдыручан икән. Әгәр дә кешеләргә ачуы килсә, ул корылык һәм зәхмәт юллап, аларны харап итә. Табул (Тобул, Тубыл) татарларында Су анасы һәммә төрле Су пәриләренең, яман көчләрнең башлыгы, имеш. Күп якларда аны карчыклар кыяфәтендә, агарган озын чәчле дип тә күзаллаганнар. Аның төп атрибутларыннан дип яки алтын тарак, яки алтын чиләкләр санала. Әкият вакыйгалары Су анасының аларны онытып калдыруы, яисә урлатуы белән башланып китә.

Г.Тукай исә үз әкиятен *“Бер авыл малае авызыннан”* дип, аның теленнән сөйләнүче вакыйга итеп язган. Ул малай эссе җәй көнендә сәгать ярымлап бик озак су керә һәм, күңеленә курку төшеп, тиз генә йөгереп чыга да киенә башлый, шунда басмада Су анасын күреп ала. Ул чәчен тарап утыра. Эше беткәч, суга төшеп китә, юк була. Басмада онытып калдырган алтын тарагын бу малай урлап кача, артыннан куып килгән Су анасын этләр куркытып кире боралар. Малай таракны әнисенә кайтарып бирә, әмма төнлә Су анасы килә, тәрәзә шакып, таракны кайтаруын сорый. “Бая көндез алып качты углың — карак!”— дип белдерә. Таракны тышка ыргытып кына аның

бәласеннән котылалар. Әмма малайга бу вакыйга гомерлек сабак була. Г.Тукай аның сүзләрен болай дип китерә: “Мин дә шуннан бирле андый эшкә кыймый башладым, “Йә иясе юк!”— дип, әйберләргә тими башладым”. Димәк, бу малай һәммә әйбернең иясе булуына шулай инана, иясез һични юклыгын төшенә. Әсәрдә уздырылган төп фикер дә шушыннан гыйбарәт.

*Октябрь, 2005.*

## ШИГЪРИ ӘСӘРГӘ АНАЛИЗ ЯСАУ ТӘРТИБЕ
### *(Схематик бәян)*

1. Иң тәүдә әсәрнең язылу вакыты билгеләнә, чөнки хис-тойгылар тормыш вакыйгалары белән бәйле туалар, бусы — мәсьәләнең бер ягы, ә икенче яктан — мәңгелек дип исәпләнелгән хис-тойгылар, мәсәлән, мәхәббәт хисе, вакыт чикләренә бәйсез яшәвенә карамастан, әсәрнең лирик герое билгеле бер дәвернең төсмерләрен үзендә йөртү сәбәпле, барыбер дә аерым бер чорның эчтәлеген үзләрендә саклыйлар. Шигырьнең язылу вакытын белү, димәк, аның эчтәлегенә төшенергә дә юл ача.

Монда тормыш фактының тәэсире мәсьәләсе ачыкланыла. Авторның көндәлеге, хатлары, дусларының хәбәрләре һ.б. шушындый тарихи вакыйгалар өйрәнелә. Болар мөмкин кадәр сорау калдырылмый аңлатылырга, ачыкланылырга тиешле. Әгәр моны эшләү мөмкин түгел икән (әйтик, документлар сакланмаган), ул вакытта эчтәлекнең конкрет төшүне кыенлаша. Дөрес, әсәргә бәйле документаль материалны ачыклау белән асылда текстология фәне шөгыльләнә. Әдәбият белеме фәнендә исә бу фактлар әсәр белән бәйлелектә бәян итеп бирелә, шигырьнең эчтәлеген ачу өчен файдаланыла.

2. Шигырьнең темасы *(нәрсә хакында)* булуы, проблемасы ачыклана. Тема ул — практик тормыштагы аерым фактның

әдәби әсәрдә үзенчәлекле яктыртылуы, проблема ул шушы факт эчендә туган яшәеш мәсьәләсенең чишелеш юлына чыгуы.

3. Образлар системасы билгеләнелә:
– төп образлар,
– ярдәмче образлар.

Аларның үзара бәйләнешен ачыклау сорала.

4. Әсәрнең төзелеш-композициясе, сюжеты, фабуласы ачыклана. Шигъри әсәрдә сюжет сирәк очрый торган күренеш һәм бервакытта да тулы булмый.
- Аерым өлешләрнең үзара мәгънәви бәйләнеше,
- микроэлементлар һәм аларның бәйләнеше,
- әсәрнең адресаты,
- тойгылар үстерелеше,
- лирик мотивлар бәрелеше тикшерелә.

5. *(Алга таба анализлар поэтика мәсьәләләренә карый).* Лексика-тел үзенчәлекләре билгеләнә:
- рифмалары,
- верлибр яки ак шигырь икән, шигъри фикернең бирелеш үзенчәлекләре өйрәнелә.

6. Шигърилек сыйфатлары бәяләнә:
- шигъри яңгыраш һәм тойгы-кичерешләрнең бәйләнеше — *фоника,*
- үлчәме, ритмикасы,
- сүзләр интонациясе тикшерелә.

7. 1)Троплар *(ягъни, сүзләрне һәм тәгъбирләрне күчерелмә мәгънәдә куллану, охшаш булган ике күренешкә нигезләнеп, берсе урынына икенчесе әйтелү, шуның белән бәйле кирәкле үзенчәлекне ачык характерлау)* өйрәнелә:
– метафоралар ***(гади метафора** – бөдрә болыт, тимер йөрәк; **катлаулы метафора** – бер төрле предметны күптөрле сыйфат күчермәләрендә бирү);*

– эпитетлар *(бер сыйфатны предметның үзе белән алыштыру (усал кеше — кансыз йөрәк — кансыз);*
– метонимия *(өч тәлинкә аш ашадым — өч тәлинкә ашадым, Тукайны укыдым)*
– синекдоха *(Рәсәй урынына Мәскәү дип белдерү);*
– аллегория *(ак күгәрчен — тынычлык аллегориясе);*
– ирония *(капма-каршы мәгънә бирү, ягъни дошманыңа **сөеклем** дип дәшү);*
– гипербола *(көрәктән зур кул);*
– перифраз *(предмет урынына, үзен атамыйча гына әйләндерәсен сөйләп бирү);*

2) Фигуралар өйрәнелә.

8. Төп әдәби чара *(прием)* тикшерелә:
– контрастлык *яки*
– чагыштыру *яки*
– параллельлек.

9. Укучыда әсәр тудырган тойгылар бәян ителә. Монда сүз әсәрнең идеясе хакында бара.

10. Жанр табигате ачыкланыла:
– *җыр* (табигатьләре белән катлаулы хисләрне гадиләштереп сурәтләүгә корыла),
– *мәдхия (ода),* (аерым бер шәхескә дан җырлауга багышлана, әмма ялагайлыкка корылмый; кешенең эш-гамәлләрен тулы килеш күрсәтергә омтылып языла, шунлыктан күләме белән озын да булырга мөмкин; андыйлары лиро-эпик әсәр төренә карый),
– *элегия* (кайгылы һәм моңлы шигъри әсәр),
– *мадригал* (мәзәккә һәм мәхәббәткә корылган җыр),
– *станс* (шагыйрьнең хис-тойгылы уйлануларына корылган шигырь),
– *эклога* (авыл темасына язылган шигырь),
– *эпиграмма* ( берәр кеше хакындагы ироник яки сатирик шигырь),

– *эпитафия (мәрсия)* (берәр кешенең үлеме уңаеннан язылган шигырь; лирик геройның тормышын тулы чагылдырырга омтылып язылганда күләме белән шактый зур да булырга мөмкин; андыйларын лиро-эпик әсәр буларак тикшерү хәерле),
– *газәл* (ун-унике куплетлы, беренче куплетка юлара рифмалы, Аллаһы тәгаләгә багышланган мәхәббәтне сурәтләүче шигырь),
– *мәснәви* (парлы рифмалы мәхәббәт шигыре),
– *касыйдә* (күләме белән *газәлдән* зуррак яки кечерәк булырга мөмкин, әмма рифмалашу тәртибе шундый ук; Мөхәммәд пәйгамбәргә аталган мәхәббәт шигыре),
– *кыйтга* (дүрт яки унике куплетлы фәлсәфи эчтәлектәге шигъри әсәр),
– *фәрд* (конкрет уй-фикерне тасвирлаучы рифмалы шигъри икеюллык),
– *хәфи* (төгәлләнгән уй-фикерне белдерүче берьюллык шигырь),
– *робагый (тарана)* (тоташ яки янәшә-әйләнмә рифмалы, һәр шигъри юлы уникешәр иҗекле, нечкә уй-тойгыларны чагылдырган һәм төгәлләнгән эчтәлектәге дүрт юллы шигырь),
– *тойуг* (робагый кебек, әмма рифмасы омоним сүзләрдән тора)

һ.б.

11. Әсәрнең идеясе туу үзенчәлеге ачыкланыла *(идея вакыйга сөйләнелү аша, образлар системасы ярдәмендә һ.б. юллар белән бирелгән булырга мөмкин)*.

12. Әсәрдән идеясе мөмкин кадәр тулы чагылыш тапкан урын табыла *(төп фикер фокусы, авторның әйтергә теләгәне)*. Фикерләрнең берничә булуы, үстерелеше, каршылыгы һ.б. ачыклана. Кайсы төп булуы билгеләнә. Фокус, ягъни фикерләрнең төбәлгән ноктасы табыла. Берничә фикердән чыккан идея һәм аның урыны күзәтелә.

13. Гомуми нәтиҗәләр ясалып, бәяләмә бирелә һәм билгеләмәгә киленә.

14. Шигырьдә шагыйрь лирик геройның хис-тойгыларын тасвирлый. Шуңа күрә шигырь аерым хис берәмлекләренә таркатыла. Аларның үзара бәйле булулары ачыкланыла. Шигъри бөтенлекне хасил итүче хис көчеше (үстерелеше) билгеләнелә. Шул рәвешле шигырьнең идея-эчтәлеге билгеләнә.

Шушы эшләр башкарылып, шигырьгә тулы анализ ясала. Аның нәтиҗәләре мантыйклы рәвештә сөйләп бирелә яки аңлатып языла. Әдәбият белеме бәян итү ярдәмендә анализ ясаучы фәннәргә керә.

*1999.*

Э Ч Т Ә Л Е К

XIX йөз татар әдәбияты үзенчәлекләре: Эчтәлек һәм тәртипләштерү........................................................................................3

Татар әдәбияты тарихын өйрәнүнең төп мәсьәләләре...........................10

“Тотса мәскәүләр якаң...” ......................................................................16

XIX йөз татар шагыйре Һибатулла Салиховның “Дөррел-Кәлам” поэмасы һәм Кәлам гыйльме...................................................................25

“Дөррел-кәлам” китабы һәм аның авторлыгы мәсьәләсе......................38

К.Насыйри һәм татар фольклористикасы нигезләре..............................43

М.Акмулла иҗатының тарихи әһәмияте, әсәрләренә текстологик анализ.........................................................................................................95

Акмулланың әдәби мәктәбе ................................................................113

Г.Тукай иҗатының асыл хикмәтләре...................................................119

Г.Тукай “Бердәмлек һәм тәрәккыять комитеты”нда............................132

“Г.Тукай журнализмы”.........................................................................137

Мәҗит Гафури шигърияте....................................................................142

Г.Ибраһимов – экспрессионист әдип...................................................148

Әдәбияттa әдәби-текстологик анализ алымы нигезләре......................211

Шигъри әсәргә анализ ясау тәртибе *(Схематик бәян)*..........................231

**Литературно-критическое научное издание**

***Яхин Фарит Закизянович***

**Читая литературу: Научные исследования**

Казань: Издательство «Слово», 2014
(На татарском языке)

*Редактор* Павличенкова З.Ф.
*Корректор* Мухамедьярова З.Т.
*Технический редактор и дизайнер* Салимуллин Т.Р.

*Подписана к печати* 12.05.2014.
*Объем* 10,72 авторских листов. 236 с.
*Тираж* 500 экз.

Типография “Джайб”, г.Казань.
Тел.:8 987 2963592